КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№5 (132)
30 гыйнвар
1998 ел

5 елның июленнән башлап чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 **Рәшит ЯГЪФӘРОВ.** Урыс телле мәктәптә татар классын ачу – чиркәүгә кереп намаз уку кебек бер шөгыльдер, андый юл белән мөстәкыйль милли мәгариф системасын оештырып булмаячак.

5 **Мансур ХӘСӘНОВ.** Шиһабетдин Мәрҗанигә карап, сөбханалла, татарда нинди генә олы затлар, тарихи шәхесләр булмаган, дип, горурлык хисләре белән үткәннәргә карап уйланасың, шөкрана кыласың.

13 **Гаяз ИСХАКЫЙ.** Иҗади эш, мәдәни эш... бер сыйныфның көче белән генә эшләнми... Кулыңда ни бар, күкрәгеңдә нинди көч бар: китер милләт мәйданына.

15 **Тәлгат БАРЫЙ.** Али Акышның эрудициясе таң калдыра, фикерләве тирән вә үзенчәлекле, аның белән аралашу ләззәт, җан рәхәте бирә.

Ата-бабаның кулыннан килгән эш, Җирнең үз хуҗасы булырга тиеш...

Мөхәррир мөнбәре

Заманыбызның сәер күренешедер инде: бездә хәзер һәртөрле банкларда, салым оешмаларында, акча җыюга бәйле бүтән учреждениеләрдә эшләүчеләр бик күпкә әйбәтрәк яшиләр. Үлә-бетә күмер чабучылар ярты-шар ел акча күрмичә, баракларда яшәп интеккәндә, андыйлар мул итеп хезмәт хакы алалар, зиннәтле офислар, үзләре өчен мәһабәт йортлар төзетәләр, ял йортларына, чит илләргә йөриләр. Кыскасы, акча бездә бер букча, ефәк бездә мунчала, дигәндәй, кыланып күрсәтәләр. Әлбәттә, халыкның күпчелеген акчасызлык әзәрлекләмәсә, болар күзгә дә күренмәс иде. Матур яшәргә һәркем хокуклы. Тик шунысы аңлашылмый бетми: халыктан җыелган хәләл акчаны алар үзләренеке итеп аңлыйлар бугай...

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

Мин әйттем

Рәшит ЯГЪФӘРОВ

Милли мәктәп милләтпәрвәр тәрбиялиме?

Татар милли хәрәкәте көчәеп киткән 1989 елдан башлап татар милли мәгариф системасын аякка бастыру, республикада татар балаларының ана телләрендә укуы өчен шартлар тудырыла башлады. Иң мөһиме – халыкта "ана телендә укып та югары һөнәри белемгә ирешеп була икән" дигән хакыйкатькә инана башлау сиземләнде. Татар мәгърифәтчеләре өчен зур җиңү булса да, әле бу казаныш милләтебезне башка халыклар тарафыннан йотылудан гарантияли алырлык дәрәҗәдә түгел. Татар милләте приоритетлы дәрәҗәдә булган Татарстан дәүләтен торгызу, татарны югары цивилизациягә ирешкән милләтләр белән тигез дәрәҗәдә хис итәрлек менталитет булдыру өчен бу әле бик аз. Мөстәкыйль дәүләт төзергә омтылган халык өчен ул гына җитми. Аның өчен халыкның милли идеясен тормышка ашыруны максат итеп куйган үз милли мәгариф системасын тулысынча торгызу шарт булып тора. Әйтик, хәзерге вакытта Русиянең урыс милли идеясенә нигезләнеп төзелгән мәгариф һәм тәрбия системасы кысаларында, барлык татар балалары үз телләрендә укыган очракта да, милләтебезнең яшь буыны мөстәкыйль дәүләтен төзүче булып үсә аламы? Юк, әлбәттә. Башка халыкның идеясенә нигезләнгән милли система ул халыкка күпмедер вакытлар җан саклау өчен генә ярдәм итә ала, аны мәңгелек итә алмый. Шуның өчен республикада "Татарстан халыкларының телләре турында"гы Законны тормышка ашыруны да без соңгы максат итеп куя алмыйбыз. Бу Закон, билгеле булганча, нигездә милләтләрнең үз һәм күршеләренең телләрен белүне генә күз алдында тота. Ә милләтнең милләт буларак сакланып калуын һәм үсешен бары тик милли мәгариф системасы, ягъни халыкның милли идеясен тормышка ашыруны максат итеп куйган белем һәм тәрбия системасы гына тулысынча гарантияли ала.

Бу нәүбәттән, без хәзер нинди стадиядә торабыз? Милли мәгариф системабызны төзү эше ни дәрәҗәдә?

Билгеле булганча, моннан биш ел элек татар мәгърифәтчеләре тарафыннан "Татар милли мәгарифен үстерү" концепциясе эшләнеп, Татарстан Мәгариф министрлыгы коллегиясе тарафыннан кабул ителгән иде. Ул концепция татарның үз милли мәгариф системасын барлыкка китерүне күз алдында тотты.

Әйтергә кирәк, милли мәгариф системасын тудыруның иң төп принцибы – татар мәгарифен бөтен яктан да (хәтта дәүләт тарафыннан тәэмин ителешне дә кертеп) мөстәкыйль итү, милләт идеясенә нигезләнгән система итү. Әмма хәзерге чорда бу максатны тормышка ашыру өчен һәм сәяси, һәм икътисади, һәм идеологик яктан да тулы шартлар юк. Татарстан мәгарифе Русия мәгариф системасының аерылгысыз бер кисәге хәлендә. Укыту, белем һәм тәрбия бирүнең эчтәлеген, стандартларын билгеләү нигездә Русия кулында. Ике арадагы килешү буенча, Татарстандагы югары уку йортлары тулысы белән Русия мәгарифе карамагында. Татарстан укыту-тәрбия процессына Русия өлкәләре күләмендә региональ компонент кертергә генә вәкаләтле. Дөресен әйткәндә, элегрәк "Татар мәгарифен үстерү концепциясе" кебек документларда да татарның үз мөстәкыйль мәгариф системасын булдыруны анык итеп күрсәтергә мөмкин булмаган иде. Аңлашыла ки, концепция закон кысаларында хәрәкәт итүне күз алдында тота. Ә Русия законнарында, белгәнебезчә, андый иреклелеккә юл куелмый. Соңыннан үзебезнең, Татарстанның "Мәгариф турында"гы Закон проектын эшләгәндә һәм Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгәндә без аңа татар мәгарифенең мөстәкыйльлеге принцибын кертергә омтылышлар ясадык һәм анда "Татар мәгарифе учреждениеләре татар мәгарифен үстерү концепциясе нигезендә эшлиләр" дигән маддә кертүгә ирешелде. Хәзер ул концепциянең яңартылган вариантын эшләү процессы бара, һәм аңа татарның мөстәкыйль мәгариф системасын оештыру механизмын салу һәм, ул кабул ителгәч, әлеге мөстәкыйль системаны барлыкка китерергә керешү мөмкинлеге бар.

Әйтергә кирәк, әле "Татар мәгарифен үстерү концепциясе"нең беренче кабул ителгән варианты буенча хәрәкәт итү елларында да милли мәгарифебезне мөстәкыйльләштерү буенча ярыйсы гына эшләр эшләнде. Әйтик, шәһәрләрдә татар телендә эшләүче мәктәпләр ачылды. Барлык республика мәктәпләрендә диярлек, шулай ук мәгариф бүлекләрендә милли мәсьәләләр буенча урынбасарлар булдырылды. Әмма соңгы елларда мөстәкыйль татар телендә эшләүче мәктәпләр ачу юнәлешендәге эш сүлпәнләнә башлады дисәк тә була. Күп кенә җирләрдә урыс телле мәктәпләр янында татар класслары ачу төп юнәлешкә әйләнеп бара. Бу, беренче карашка, татар балаларын үз телләрендә укытуны "колачлау" ягыннан уңай процесс булса да, укыту биналары җитмәгәннән генә эшләнгән вакытлы күренеш, аның перспективасы юк. Урыс телле мәктәптә татар классын ачу, ул – чиркәүгә кереп намаз уку кебек кенә бер шөгыльдер, һәм андый юл белән беркайчан да милли мохит, мөстәкыйль милли мәгариф системасын оештырып булмаячак. Шуның өчен бу юлдан мөмкин булганча баш тарту мәслихәт.

Билгеле ки, яшәп килүче Русиячә мәгариф системасында идарә итү, методик тәэминат өлкәләрендә татар мәгарифен мөстәкыйльләштерү каралмаган. Татар мәгарифе Русия системасының "өйдәше" дәрәҗәсендә генә. Татар мәктәпләре, балалар бакчалары, урыс мәктәп һәм бакчаларындагы класс һәм төркемнәр, үз эчләрендә татар телендә эшләргә мөмкинлекләре булса да, җитәкчелек итү сфераларында бернинди дә мөстәкыйльлеккә юл куелмый. Әйтик, аларның барысында да исәп-хисапны урыс телендә тоту мәҗбүри куелган, укытучыларны аттестацияләү эшләрендә дә "интернационализм" принцибы алга чыга. Нәтиҗәдә, еш кына татар мәктәпләренең, укытучыларның эшен урыс укытучыларыннан торган комиссияләрнең тикшерүенә юл куела. Шунлыктан мондый тикшерү, аттестацияләр еш кына җәнҗалларга сәбәпче була. Төрле конкурслар, ярышлар, смотрлар уздыруда да кайчак миллилек искә алынмаганлыктан, шул нигездә ризасызлыклар, гаепләүләр, ызгышлар туа. Кыскасы, татар милли мәгариф системасының аерым чалымнары инде күренә башлады һәм ул хәзерге вакытта яшәп килүче унитар Русия мәгариф системасы белән каршылыкка керә. Икенче төрле әйткәндә, бу гомум "интернациональ" система эчендә татар һәм урыс (Русия дисәк тә ярый) милли мәгарифләре бер-берсенә комачаулык итә башлады. Татар милли мәгарифенең үсү һәм ныгуы белән бәйләнешле рәвештә бу каршылыкларның көчәюе дә закончалыклы һәм табигый булачак. Бу каршылыкларның зураюын булдырмый калуның бердәнбер юлы – Русия мәгариф системасының диктатыннан котылу һәм мөстәкыйль дәүләткә хас үз мәгариф системасын булдыру. Аның төп принцибы итеп, Русиянекеннән аермалы буларак, һәрбер халыкның санына нисбәтле рәвештә мөстәкыйль мәгариф системаларын аякка бастыру алынырга тиеш.

Куанычлы ки, мөстәкыйль милли мәгарифебезнең беренче яралгылары инде пәйда булды, һәм ул Русиянең унитар системасына карата үзенең мөнәсәбәтен белдереп "аваз да сала" башлады. Хәзер аның үсеп китүе өчен юридик нигезләмәләр төзүне, Русия белән шартнамә һәм килешүләрнең эчтәлеген үзгәртү юлы белән Татарстан карамагына белем бирү стандартларын билгеләү кебек зур вәкаләтләрне алуны максат итеп куярга тиешбез. Аннан инде укыту һәм тәрбиянең эчтәлеген "татар идеясе" һәм Татарстан дәүләте мәнфәгатьләренә туры китереп үзгәртеп кору бурычы күз алдына килеп баса. Шуларны эшли алсак, татарның һәм Татарстанның киләчәге ышанычлы булыр.

Җыеп әйткәндә, татар телендә эшләүче мәктәп системасын гына түгел, ә татар телендә эшләгән һәм үз халкының милли идеясен тормышка ашыруга алынган укыту һәм тәрбия системасын гына без "милли мәгариф системасы" дип атыйбыз. Безнең максат – халкыбызның мәңге яшәвенә гарант булырлык әнә шундый система булдыру.

* * *

Бу юнәлештә татар мәгърифәтчеләре тагын бер омтылыш ясарга ниятлиләр. Күптән түгел Бөтентатар "Мәгариф" берләшмәсенең президиум утырышында "Милли мәгариф һәм Татарстанның дәүләтчелеген ныгыту" дигән мәсьәлә тикшерелде. Анда "Мәгариф"челәр татар милли мәктәпләрендә укыту һәм тәрбия бирүнең эчтәлеген дәүләтчелекне ныгыту һәм милли шәхес тәрбияләү күзлегеннән экспертиза ясарга, аның нәтиҗәләрен мәгариф министрлыгына тәкъдим итәргә дигән карарга килделәр. Аның өчен оештыру комитеты да төзелде. Ә "Мәгърифәт" гәзите шушы темага дискуссия оештырырга булды.

Март ахырларында шушы мәсьәләгә багышланган III Татар мәгърифәтчеләре корылтаен уздырырга да ниятлибез. Шуңа кадәр, әйдәгез, дуслар, уйланыйк: милли мәктәпләребез чыннан да дәүләтпәрвәрләр, милләтпәрвәрләр үстерәме? Корылтайда әлеге мөһим сорауга берәгәйле итеп, бөтен мир белән җавап бирик.

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 1 2 3 4 5 6 7

Мөнәсәбәт

Нуль турында кыйсса

"Чир китәр, гадәт калыр", диләр. Бездән авыру китәрме — юкмы, белмәссең. Ә менә гадәтебез тиз генә бетәргә охшамаган. Үзгәртеп корабыз дип сөйләнүебез чын-чынлап гадәткә әйләнеп китте бит, әй! Башта корабыз да, читкәрәк китеп, корганыбызга тамаша кылып торганнан соң: "Барып чыкмаган ла бу", — дип кире сүтеп ташлыйбыз, янә корырга тотынабыз. Монысы нәкъ без теләгәнчә булачак, имеш.

Чит ил халыклары миллионерлар әнә, дип, күрмәкчедән чүлмәкче дигәндәй, безне дә миллионерлар ясадылар баштарак. Кәгазь акчаларның 1 һәм 5 саннары янына дүртәр, бишәр нуль өстәп яздылар да безгә тоттырдылар. Миллионер булудан башлар әйләнгән без мәхлуклар шул акчаларны күтәреп кибетләргә йөгердек. Тик нуль өстәп кенә баеп булмаячагыбызны аңлагач, әлеге агач акчаларга әллә нәрсә сатып алып булмаслыгын, янә алдауларын белгәч, башларны ташка орыр хәлгә килдек. "Дөрес булмаган бу, кире алып ташлыйбыз нульләрне, алардан башка да мул тормышта яшәп булачак", дип ышандырырга булдылар. Нульләрне киредән сызып ташладылар. Билгеле инде үзгәртеп кору җиңел гамәл түгел, күп көч түгүне сорый торган нәрсә ул. Нульләрдән котылдык дип кенә торганда яңадан очраштык бит без алар белән. Фатир өчен түләргә дип яңача счет номеры җибәргәннәр. Шуны күргәч, күзләр дүрт булды. Элеккесе алты саннан гына тора иде, ә монысы аз да түгел, күп тә түгел... егерме саннан тезелеп киткән. Ә шуның җидесе нуль...

Үзгәртеп корырга мачтырлар булуыбызны әйткән идем бит инде. Моңа кадәр фатир өчен түләгәндә лифт тә искә алына иде. "Казгорлифт", соң булса да уң булсын диптер инде, ниһаять, үз эшен үзгәртеп корырга уйлаган. Лифттә йөргән өчен акчаны аерым түлисез, дип, фәрмән җибәргән, үзенең счет номерын да хәбәр иткән. Алар тагын да арттырыбрак җибәргәннәр, егерме сан тезеп чыкканнар. Шуларның унбере нульдән тора. Акчадагы нульләр белән фатир, лифт өчен түләр өчен җибәрелгән һәм банкларда ачылган башка счет номерларындагы нульләрнең ни уртаклыгы бардыр, анысын белмим. Берничә бухгалтерга мөрәҗәгать итеп карасам да әлеге серле саннарны тәгаен генә аңлатып бирә алмадылар. Берсе: кампитрларга бәйле бу, диде. Икенчесе... Ярар, хикмәт анда түгел, хикмәт аларны элеккеге квитанцияләргә сыйдырып булмауда. Чөнки алар аңлаешлы алты санга гына исәп тотып бастырылган иде. Димәк, миллионлаган санда бастырылган шул кәгазьләрне яңадан, ягъни үзгәртеп бастырырга туры киләчәк, димәк, күпме кәгазь, буяу сарыф ителәчәк. Нигә үзгәртеп коруыбыз безнең, ягъни синең белән минем кесәгә гел-гел зыян салып тора икән ул?! Юкса нульләрне сызудан безгә файда гына киләчәк, эшебезне җиңеләйтәчәк дип тукып та торганнар иде. Очыкрые бер булырмы икән соң бу үзгәртеп кору дигән галәмәтнең?!

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

Әдипне олылау

– Әгәр кеше үзе сайлаган юлның хаклыгына инанган булса, аның инанганлыгы, мавыгуы һичшиксез башкаларга күчә. Мин безнең республика Президенты яныннан яшәреп чыктым, – диде татар әдәбияты аксакалы, Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, 23 гыйнварда Кремльдә М.Шәймиев белән очрашканнан соң.

Әңгәмә бер сәгать чамасы барды һәм ул эчкерсезлек, бер-береңә ышану белән сугарылды. Президентның әңгәмәдәше әле университетның II курсы студенты чагында ук чит-ят якларга сөрелә һәм анда узган кырыс елларын хәтта бәхетле еллар дип саный, чөнки "каторганың һәр елы саен мин берәр университет тәмамладым, һәм әлегә кадәр хәтеремдә күп йөзләрчә кешеләрнең исемнәре, язмышлары саклана". Аның характеры шундый – инануларын чыбыркы белән дә, прәннек белән дә үзгәртергә мөмкин түгел.

Вакыт халыкның тарихын язуны, халыкның рухилыгын тергезүне таләп итә, һәм шунысы әһәмиятле, моның өчен мөмкинлек тә бирә. Моңардан файдалана белергә, өндәп кенә калмыйча, конкрет эш эшли белергә дә кирәк. Татар энциклопедиясен бастыру, Колшәриф мәчетен торгызу, балалар бакчасыннан башлап татар телен өйрәнү һәм мәктәпләрдә аны укыту, шул исәптән урыс телен укыту методикасын эшләү, күпмилләтле республикабызга мәхәббәт тәрбияләү – бу юнәлештә җентекле, зур эшнең башлангычы ул.

Минтимер Шәймиев Аяз Гыйләҗевны 70 еллык юбилее белән җылы тәбрик итте һәм аңа иң изге теләкләр теләде. Язучының әле иҗат юлы башланганда ук әйткән: "Ян, минем учагым, ян!" – дигән сүзләре бүгенгә дә ярашлы. Сезнең талант уты озак вакытлар буена сүнмәс, диде Президент.

Әңгәмәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары И.Хәйруллин, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р.Мөхәммәдиев катнашты.

* * *

24 гыйнварда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевка 70 яшь тулуга багышланган Юбилярны Пре- тантаналы кичә булды. мьер-министр Ф.Мөхәммәтшин кайнар тәбрикләде һәм аңа Татарстан Республикасының Мактау грамотасын тапшырды.

Бәйрәм хуҗасын шулай ук Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р.Мөхәммәдиев, Камал театрының баш режиссеры М.Сәлимҗанов, әдипнең Сарман һәм Зәй районнарыннан килгән якташлары исеменнән Зәй районы һәм шәһәре хакиме Р.Хәмәдиев, Казан мэриясе һәм Вахитов районы хакимияте исеменнән С.Мөхәрләмов һ.б. котлады. Ихлас тәбрикләүләргә республика сәнгать осталарының чыгышлары кушылды.

Кичәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары И.Хәйруллин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Харисов, мәгълүмат һәм матбугат министры И.Әхмәтҗанов катнашты.

Көлке җыя яшьләрне

2-7 февраль көннәрендә Казанда, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында БДБ илләре вузларының "Икариада-98" дип исемләнгән студент театрларының VII халыкара фестивале уздырыла. Ошбу бәйрәм А.Райкин истәлегенә багышлана. Мәртәбәле жюрига Мәскәүдән килгән актер һәм композитор, безнең КАИны тәмамлап чыккан Семен Каминский рәислек итә.

"Икариада"ның тарихы сиксәненче елларга барып тоташа. Аны А.Туполев исемендәге Казан авиация институты (хәзерге Казан дәүләт техника университеты) башлап җибәргән иде. Ул чакта илнең шушы мәртәбәле югары уку йорты Советлар Союзының бик күп калаларыннан үзенең "авиатуганнар"ын бәйгегә җыйнап алды.

Бу юлы Казанга бөек комикның улы Константин Райкин да чакырылды. Ул Тинчурин театры сәхнәсендә үзенең моноспектаклен күрсәтмәкче. Җиңүчеләрне саллы-саллы бүләкләр көтә. Аның иң олугы – Казан хакимияте башлыгы тарафыннан булдырылган Гран-при.

Нурлы ат – Нурлат туграсы

Русия Дәүләт Думасы яңа дәүләт билгеләре тирәсендә кызу бәхәсләр алып барганда, әле генә республика дәрәҗәсендәге шәһәр статусын алган Нурлатыбызның гербын берләштерелгән Совет сессиясендә расладылар да куйдылар. Әлеге тугра Нурлат осталары тәкъдиме нигезендә Чаллыда эшләнгән. Димәк, хәзер бу шәһәрнең символы Татарстан Дәүләт флагы җирлегендә көяш нурлары на коенып чапкан ак ат булыр.

Әйткән сүз – аткан ук

Ренат ИБРАҺИМОВ, Татарстанның һәм Русиянең халык артисты:

"...Эстрадага килгәндә, кызганыч ки, Казан әлегә кичәге көн белән яши – бәләкәй төркемнәр, синтезлаштырылган музыка яки баян – боларның барысы да үзешчән клублар дәрәҗәсе".

("АиФ").

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татар әдәбиятын үстерүгә керткән олы хезмәтләре өчен Татарстанның халык язучысы **ГЫЙЛӘҖЕВ Аяз Мирсәет улы** Татарстан Республикасының **Мактау Грамотасы** белән бүләкләнде.

Татар театр сәнгатен үстерүдәге зур уңышлары өчен Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **ТАҖЕТДИНОВ Ринат Арифҗан улы** Татарстан Республикасының **Мактау Грамотасы** белән бүләкләнде.

Татарстан Президенты Указы нигезендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары **АСЫЛГӘРӘЕВ Шәрифҗан Нурлыгәрәй улына** татар милли мәдәниятен үстерүгә керткән шәхси өлеше өчен Татарстан халык депутаты, композитор һәм шагыйрь **ХӨСНЕТДИНОВ Илсур Гайнетдин улына "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

Музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен Казан дәүләт консерваториясенең тынлы уен кораллары кафедрасы профессоры **КАРПУХИН Евгений Ивановичка "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе"** дигән мактаулы исем бирелде.

"Алтын Меркурий" призына лаек

Полиграфия-нәшрият комбинаты (элекке Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты) "Алтын Меркурий" призына лаек булды. Ул "Прогресс хакына партнерлык" дигән халыкара программада катнашкан иде. Бу приз белән Русиядә һәм БДБ илләрендә барысы 28 нәшрият һәм типография бүләкләнгән.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Президенты М.Шәймиев "Маяк" радиосының "Сәяси элемтә" дигән тапшыруында катнашты.

Лениногорски район һәм шәһәр хакимияте башлыгы И.Садриев районның 560 уку алдынгысын мәдәният сараена җыйды һәм шуның алтмышына өч ел рәттән бирелеп килә торган 100әр мең сум күләмендә стипендия өләште.

Зур концерт залында профессор А.Шутиков җитәкчелегендә Дәүләт халык инструментлары оркестры концертлары узды.

Ульяновскида "И.Яковлев һәм милли педагогика проблемалары" дигән гыйльми-гамәли конференциядә Татарстаннан профессор Р.Исламшин, педагогика училищесы директоры М.Гайнетдинов, шул уку йорты хезмәткәрләре Г.Әдһәмова, Г.Гайнетдинова чыгыш ясадылар.

Г.Тукай музеенда Н.Җиһановны искә алу кичәсе узды.

Сынлы сәнгать музеенда Визельләр династиясенә багышланган күргәзмә ачылды.

Күренекле композитор А.Монасыйповның оныгы җиде яшьлек Рөстәм Түбән Новгородта үткән музыка коралларында уйнау бәйгесендә җиңү яулады, беренче урынны алды.

Шагыйрә, җырлар авторы, укытучы Ш.Таһировага 75 яшь тулды, һәм бу тантана Чаллы шәһәренең "Балкыш" мәдәният клубында үтте.

Казанның ясалма күн заводында республикада беренче тапкыр югары сыйфатлы клеенка җитештерелә башлады.

Татарстан Фәннәр академиясе Президиумы 1998 елда академиянең исемле ике премиясен: Ш.Мәрҗани исемендәгесен – гуманитар фәннәр өлкәсендә, ә икенчесе – Х.Мөштәри исемендәгесен математика, механика һәм техник фәннәр өлкәсендәге ачышлар өчен 30 минималь хезмәт хакы күләмендә булдырды.

Сәхифәбездә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Ә.ШАКИРҖАНОВ** фотосы.

Көн саен сәгать яңалык

■ Татарстан Фәннәр академиясендә күренекле татар галиме һәм мәгърифәтчесенең тууына 180 ел тулуга багышлап "Ш.Мәрҗани, мирас һәм заман" дип исемләнгән халыкара гыйльми конференция уздырылды.

■ ***Казан мэры К.Исхаков Санкт-Петербург каласында булып, анда Урыс музее директоры урынбасары, академик В.Мальцев, "Кубрат хан хәзинәләре" дип исемләнгән каталог бастырып чыгарган "Славия" нәшриятының генераль директоры С.Хваль һ.б. белән очрашты, җәмигъ мәчетендә Русиянең Төньяк-Көнбатыш өлеше мөфтие Җ.Пончаев белән сөйләште.***

■ Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында Казанның татар мәктәпләре һәм гимназияләрендә белем алучылар танылган татар шагыйрәсе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнашева белән очраштылар.

■ ***Татарстан Республикасының Санкт-Петербург каласындагы һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллегендә милләтебезнең күренекле мәдәният эшлеклеләре, Русия Федерациясенең атказанган артистлары: җырчы Альберт Әсәдуллин, Мария театры солисты София Ялышева, РФның атказанган мәдәният хезмәткәре Сайра Вельшакова, күренекле җырчы, Париж каласындагы Русия-Франция консерваториясенең мактаулы әгъзасы Диана Яфарова, музыка белгече Наилә Әбүбәкерова, шагыйрә Лилия Насыйбуллина һ.б. белән фикер алышу булды.***

Очрашуның максаты – Питер якларында яшәп яткан олпат затларыбызны татар халкының һәртөрле йола, гореф-гадәтләрен тергезү, динне яңарту, ана телен күтәрү, яшь буынны тәрбияләү кебек күркәм эшкә җәлеп итү.

■ Казанның "Бәхетле балачак" хореография ансамбле Мәскәүдә булган "Хоровод дружбы" дип исемләнгән Икенче халыкара фестивалендә лауреат исеме алып кайтты. 11 илдән килгән осталар катнашкан сәнгать конкурсында Русия Федерациясеннән ике коллектив кына чыгыш ясады. Берсе – Мәскәүнең "Раззадоры" (җитәкчесе – Русия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Ренат Ганиев) һәм Казаннан җөмһүриятнең атказанган мәдәният хезмәткәре Светлана Ишкузина җитәкләгән "Бәхетле балачак" ансамбле. Безнекеләрнең "Бондюг", "Гармун", "Егетләр" биюләре тамашачыны аеруча биһуш итте.

■ ***Казан дәүләт технология университетының өстәмә белем бирү факультетына караган "Ислам белеме" бүлегендә изге Рамазан аенда "Кеше һәм Ислам" дигән лекцияләр курсы булды.***

■ "Казан" милли мәдәният үзәгендә Ленинград блокадасы өзелүгә 54 ел тулуга багышланган җыелыш үткәрелде.

Ленин каласы блокадасында, соңгы исәпләүләр күрсәткәнчә, 1 миллион 900 мең кеше, ә кала өчен барган канкойгыч сугышларда 600 мең совет солдаты һәм диңгезчесе һәлак булган. Тагын 200 мең кеше хәбәрсез югалган.

Казанда Ленинград блокадасында катнашучыларны 1991 елда берләштергән җәмгыятьтә хәзер 500 кеше исәпләнә.

■ ***Татарстан ПЕН-үзәгенең Татарстан Милли китапханәсендә уздырылган быелгы тәүге утырышы кириллицадан латин язуына күчү мәсьәләсен тикшерүгә багышланды. Монда шулай ук "Мәгариф" нәшриятында инглиз телендә "Татар әдәбияты бүген" дигән җыентыкны әзерләү мәсьәләсе дә каралды. Ошбу басма быел сентябрь аенда Финляндия башкаласы Хельсинки шәһәрендә үткәреләчәк Бөтендөнья Язучылар конгрессына бүләк булыр.***

■ Самара өлкәсенең Шенталы станциясе бистәсендә татар якшәмбе мәктәбе ачылды. Алтмышка якын татар баласы, шушында килеп, тел һәм әдәбиятны, Ислам тарихын өйрәнә, гарәпчә уку-язу, шулай ук татар музыкасы нигезләрен үзләштерә. Татар теле һәм әдәбиятын – Румия Шакирова, Ислам тарихын – "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә гыйлем алып чыккан Рәис Садыйков, татар музыкасы нигезләрен Марат Рәсулев укыта.

■ ***Башкалага илтә торган юллардагы милиция контроль пунктының тагын икесендә 1 февральдән башлап медицина пунктлары эшли башлый.***

Җөмһүриятнең Катастрофалар медицинасы үзәгендә бик тиз эш итә торган медицина отряды төзелде. Максаты – юл-транспорт һәлакәте һәм башка төрле бәла-каза килгәндә кешеләргә ярдәм күрсәтү, ДАИ һәм милициянең контроль пунктындагыларга булышлык итү. Бу яктан Чаллы-Казан юлындагы былтыр май аенда ачылган милиция пунктының (аны "Кольцо" дип йөртәләр) эшчәнлеге үзен яхшы яктан гына күрсәтте. Ярты ел эчендә генә дә анда автомобиль һәлакәтендә зыян күреп 60 шофер һәм юлчыга ашыгыч ярдәм күрсәтелде. Табиблар хәле бик авыр булган 22 кешенең тормышын саклап калдылар.

Шушындый ук медицина пунктлары Идел аша салынган күпер янында, "Малиновка" контроль милиция пунктында, шулай ук Зөя елгасы аша салынган күпер янәшәсендә – "Исаково" пунктында ачылачак. Февральнең башында ук инде "Карамай" кемпингы (ул Чаллы трассасының 86 нчы чакрымында) янында да тагын бер пункт эшли башлый.

Алисә Галләмова Президентта кунакта

Президент Минтимер Шәймиев танылган шахмат остасы, Русиянең 1997 елгы чемпионы, дөнья беренчелеге буенча Гронингендә уздырылган дәгъвачылар турнирында җиңеп чыккан Алисә Галләмова белән очрашты. Президент Алисәне җиңүе белән котлады, аның эшләре белән кызыксынды, аңа, оста шахматчылар алмашы әзерләү максатыннан, республикада үз шахмат мәктәбе оештырырга тәкъдим итте.

Алисә Галләмова Президентка үзенең берничә айдан хатын-кызлар арасында дөнья чемпионы исеме өчен барачак турнирда катнашачагын, бу катлаулы көрәштә аның көндәше Кытай шахматчысы Сее Цаюнь булачагын һәм үзенә җитди тренер ярдәме кирәклеген әйтте.

Р.Нәҗметдинов исемендәге республика шахмат мәктәбенә килгәндә, Президент һәм Алисә аңа кампитр классы өчен җиһазлар бүләк итәргә булдылар.

Үзешчән сәнгать – игътибар үзәгендә

Мәркәзебез Казанда татар сәнгатен торгызу һәм үстерү мәсьәләләренә багышланган XVI төбәкара район-авыл мәдәният йортлары директорлары һәм үзешчән сәнгать коллективлары җитәкчеләре семинары дәвам итә.

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәге, Мәдәният хезмәткәрләренең осталыгын үстерү курслары оештырган әлеге җыенга Русиянең Әстерхан, Пермь, Курган, Самара, Ульян һәм башка төбәкләреннән, Башкортстан, Удмуртиядән килгән күп санлы кунаклар җыелды. Алар Татарстан Мәдәният министрлыгының чит өлкәләр белән эшләү тәҗрибәсе белән таныштылар, министрлыкның татар фольклор дәүләт үзәгенең төп белгечләре белән очраштылар, мәдәният йортларына методик ярдәм итү формалары турында тәҗрибә уртаклаштылар.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Зөлфәт Хәкимнең "Күрәзәче" дигән моңсу комедиясенең премьерасы булды. Әсәрне сәхнәгә СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов куйды. Рәссамы – Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Таң Еникеев. Музыка бизәлеше – Татарстанның халык артисты Фуат Әбүбәкеровныкы.

● *Спектакльдән бер күренеш.*

М.ШАКИРҖАНОВ фотосы.

Алдан хәбәр итәбез

● Февральнең 2сендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында ураза тамамлану уңаеннан "Рамазан" дип исемләнгән күркәм бәйрәм үткәрелә. Аны Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оештырган. Бу кичә программасында – халык җырлары, төрле-төрле биюләр, уеннар. Аның музыкаль бизәлеше – композитор Мәсгудә Шәмсетдинованыкы.

● 15-14 февральдә Казанда Ф.И.Шаляпин исемендәге XVII Халыкара опера фестивале уздырыла. Ул атаклы җырчы һәм якташыбызның тууына 125 ел тулуга багышлана.

● 14 февраль көнне Ульян өлкәсенең Димитровград каласында балачактан ук йөри алмас хәлгә килеп гомерен яткан килеш кенә үткәрергә мәҗбүр булган әдип Гакыйль Сәгыйровка 60 яшь тулуга багышланган юбилей тантаналары уздырыла.

Г. Сәгыйров фондына матди өлешен кертү уе белән янган изге күңелле кешеләр өчен Самара каласындагы телефонны хәбәр итәбез: 332410, 332411.

● Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисты Нәҗибә Ихсанованың иҗат кичәсе 21 февральдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үткәреләчәк.

● Тиздән Чиләбе өлкәсендә, башлыча Миасс шәһәрендә, Татарстан Республикасы көннәре үткәрү планлаштырыла.

ФАҖИГА АЯК АСТЫНДА

Су да хәвефле

1997 елда Татарстан суларында барлыгы 281 кеше, шул исәптән,52 бала батып үлде. Аннан элекке елда исә әлеге сан 314кә җитеп, шуның 62 се бала-чага иде.

Һәр елдагыча, һәлак булучыларның күплеге ягыннан Казан белән Әлмәт алда бара.

Ни кызганыч, Татарстан башкаласында коткару хезмәте булдыру да әлләни уңыш китермәде. Былтыр Чаллы коткаручылары һәммәсеннән дә әйбәтрәк эшләде. Шуның нәтиҗәсе буларак, монда судагы фаҗигалар ике мәртәбәгә кимеде.

Үзе нәни, ә зәхмәте фил хәтле

Узган елда Татарстанның 2431 кешесе геморрогик бизгәк (ГЛПС) зәхмәте йоктырды. Мәгълүмдер, әлеге чирне кыр, урман тычканы таратучан. Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, авыручылар саны, 1996 ел белән чагыштырганда, 10,5 тапкырга арткан.

Бер елда тугыз кеше әлеге чирдән үлеп китте. Кимерүчеләрнең әнә шулай күпләп үрчеп китүен белгечләр урманнарның ташландык хәлдә булуы белән бәйли. Мондый җирдә тычкан бөтенләй иркенгә чыга, азына, көннән-көн үрчи.

Башкортстан һәм Удмуртиядән кала, Татарстан әлеге хастадан интегүчеләр саны ягыннан Русиядә өченче урында тора.

Эт тә, мәче дә куркыныч

Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, былтыр барлыгы 13770 кешене эт талаган, мәче тешләгән һәм башка төрле киек-җанвар зыян-зәүрәт салган. Шуларның 123е һәртөрле кыргый җәнлек тарафыннан зыян күргән. 1996 елда исә мондый бичаралар саны 14034 кешегә җиткән булган.

Бу төр зәхмәтнең куркынычы шунда ки, "кече туган"нан котыру авыруы йоктырып харап булу ихтималы зур. Зыян күрүчегә алдан ук тиешле саклану прививкалары ясалмаган булса, кеше үлеп китәргә дә мөмкин. Былтыр белгечләр хайваннар арасында республика буенча барлыгы 49 котыру очрагын теркәде. Әлеге сан, 1996 ел белән чагыштырганда, дүрт мәртәбәгә кимрәк булуга да карамастан, тынычланып калырга һич ярамый. "Кече туган" зыян салган очракта һич кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итү шарт. Котырган эт талап үлү очрагы соңгы тапкыр 1994 елда теркәлгән.

ВАКЫЙГАЛАР, ЯҢАЛЫКЛАР турында хәбәр итү өчен телефон: 32-60-11

Мансур ХӘСӘНОВ,
Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик

Татарның яңарыш Чулпаны

Татарның дистәдән артык гасырларга сузылган, шанлы да, фаҗигале дә, шөһрәтләре белән бергә михнәтләре дә тулып ашкан ифрат бай вә гаять катлаулы тарих битләрен актара башласаң, тау тезмәләренең калку сыртлары шикелле, бер-бер артлы торле дәверләр, дөньяны дер селкеткән вакыйгалар, ил һәм халык язмышлары кузаллана, каһарман һәм фаҗигале шәхесләр, олуг ханнар һәм дәүләт башлыклары, галимнәр вә фикер ияләре, шагыйрьләр һәм философлар Кол Галиләр, Олуг Мөхәммәт, Кол Шәрифләр, Мөхәммәдъяр белән Сөембикәләр, Курсавый һәм Утыз Имәниләр күз алдыннан үтә. һәм XIX гасырның урталарына килеп җиткәч, тарих сәхнәсендә Шиһабетдин Мәрҗани фигурасы калкып чыга.

Монысы инде яңа заман каһарманы, бөтенләй башка югарылыкта торган гыйлемдар. Башына чалма кигән, күтәрелеп карасаң, баш киемең төшәрлек югары, акыллылыгы йөзенә бәреп чыккан, олылыгы вә мәгърур табигате бөтен кыяфәтендә чагылган, хәтта киемнәренә үк күчкән шикелле. Ихтыярсыз рәвештә: сөбханалла, татарда нинди генә олы затлар, тарихи шәхесләр булмаган, дип, горурлык хисләре белән үткәннәргә карап уйланасың, шөкрана кыласың.

Шиһабетдин Мәрҗани – XIX гасырда татарның рухи хәятендә тирән борылыш ясаган, уяну-яңарыш дәверенә – ренессанска юл ачкан титаник шәхес, фикер иясе, милли мәдәният күгендә, бөтен Ислам дөньясында балкып торган олы якты йолдыз. Бөек реформатор, энциклопедист галим, мәшһүр мәгърифәтче. Ул татар ренессансының чулпаныдыр. Без мөселманнарның олы бәйрәме көннәрендә бу бөек татарның 180 еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үтәбез.

1

Мәдәният, фән өлкәсендәге олы талант – мәшһүр шәхесләрнең юбилей бәйрәмнәрен уздырганда аларның туган җирләренә, "очып чыккан" ояларына күз ташлау, генеологиясенә мөрәҗәгать итү, укыган-белем алган урынын хәтердән үткәрү гадәткә кергән. Бу юлы да шулай эшлик: сүзне Мәрҗанинең яшь чакларын, уку елларын искә төшерүдән башлыйк.

Шиһабетдин Мәрҗани – татар мәдәниятенә, Ислам дөньясына данлыклы Казан арты, Арча-Әтнә яклары бүләк иткән олы шәхесләрнең берсе, мөгаен, иң зурысыдыр. Ул Казаннан 40 чакрым-нар җирдә урнашкан Ябынчы авылында укымышлы вә мәдәниятле, шәҗәрәсенең тамырлары ерак тарихка барып тоташкан рухани гаиләдә дөньяга килгән. Белемне башта Ташкичү авылында әтисе Баһаветдин хәзрәт мәдрәсәсендә алган. Замандашлары аның таланты һәм зирәклеге, белемгә хирыслыгы, ихтыяр көче бик яшьтән үк ташып торуын язып калдырганнар. Мәдрәсәдә яшь Шиһабетдинны укыткан хәлфәләрнең берсе болай дигән: "Мин нә кадәр шәкерт укытып,... Шиһабетдин кадәр зиһенле, аның кадәр аңлы шәкертне күрмәдем. Сабакларын бер генә мәртәбә укый да һәммә шәрикъларыннан артык белә. 12-13 яшьлек баланың шул кадәр белүенә гаҗәпләнәм. Әгәр дә хәзрәтнең бу баласы сәламәт кенә үссә, зур галим булыр".

Унҗиде яше тулгач, Шиһабетдин инде әтисе мәдрәсәсендә үзе укыта башлый. Бераз укыту тәҗрибәсе туплагач, Баһаветдин хәзрәт улын, сәүдә кәрванына ияртеп, Бохарага, ул вакытта Русия мөселманнары өчен мәгърифәт учагы саналган җиргә, үзе белем алган мәшһүр мәдрәсәләрнең берсенә укырга җибәрә.

Гәрчә яшь булса да, гадәттән тыш таланты һәм зирәклеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә бик иртә өлгереп җиткән, Урта Азия мәдрәсәләренең дәрәҗәсен тиз аңлап алган, дөньяга, тирә-юньгә тәнкыйть күзе белән карый торган, белеме-акыллылыгы, дөньяга карашларының киң һәм алга, киләчәккә омтылган булуы ягыннан шәкертләрдән генә түгел, мөдәррисләрдән дә күпкә югары торган Мәрҗанине Бохара мәдрәсәләре канәгатьләндерми, әлбәттә. Ул алардагы схоластиканы, катып калганлыкны кабул итми.

Искә төшереп үтик: андагы тәртипләргә каршы беренче кискен һөҗүм укларын Мәрҗанинең якташы Габденнасыйр Курсавый аткан иде. Үзенең "еретик" фикерләре өчен ул Бохара әмире тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән була, тик аннан качып кына котыла. Курсавыйның кулъязмалары белән Бохарада танышкан, аның язмышын яхшы белгән Мәрҗани андагы вазгыятькә, Урта Азия мәдрәсәләренең укыту-тәрбия системасына мөнәсәбәтен ул чакта ачыктан-ачык белдерми, Курсавыйның хатасын кабатламый. Бохара мәдрәсәләренең заман таләпләреннән күпкә артта калганлыгын ул Казанга кайткач кискен тәнкыйть итәчәк. Мәрҗани анда гыйлем эстәүнең мәдрәсәдән тыш башка юлларын эзли. Бохарада, бигрәк тә Сәмәркандта, укымышлы кешеләр, күренекле гыйлем ияләре белән очраша, фикер алыша, мәшһүр китапханәләргә йөри, аларда казына-эзләнә, Ислам тәгълиматына караган чыганаклар, китаплар белән таныша, гарәпчә-фарсыча тәрҗемәләре аша антик әдәбиятның, философиянең классик әсәрләрен укый, борынгы Ислам мәдәниятен өйрәнә. Һәм инде туган иленә кайтканда ул чын-чынлап галим, дин әһеле, педагог һәм мәгариф эшлеклесе булып җитлеккән була.

Мәрҗанинең аннан соңгы бөтен тормышы һәм иҗаты Казан белән бәйләнгән. Биредә ул 1 нче мәчетнең (хәзерге Мәрҗани мәчете) имамы һәм шул ук мәчет каршындагы мәдрәсәдә мөдәррис була. Казанда аның күпкырлы таланты бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән ачыла, киң колачлы фәнни-иҗат эшчәнлеге чын-чынлап чәчәк ата.

2

Аның хакында хезмәтләр шактый күп язылган. Аларда ул олы галим, философ, илаһият белгече, тарихчы һәм мәгърифәтче буларак тикшерелгән, югары бәяләнгән. Әмма, әйтергә кирәк, мондый бәяләр генә Мәрҗани феноменын, бу бөек фигураның татар тарихында, бөтен Ислам дөньясында тоткан зур урынын тулысынча ачып бирмиләр.

Ш.Мәрҗани – барыннан да бигрәк бөек реформатор. Татарның, бөтен Ислам дөньясының фикри хәяте авыр таш белән бастырылып, кешенең мөстәкыйль фикер эшчәнлегенә "Заманы иҗтиһад монкарыйз" дигән тәкълид богаулары салынган бер заманда ул шәхескә фикер иреге, иҗат хокукы таләп итеп чыкты, рухи хәяттә иске, таушалган авторитетларның монополиясен җимерде, мөселман дөньясы өчен иҗтиһат капусын ачты. Ул татарны торгынлык йокысыннан уятучы, уйлау-фикерләү офыгын арттан алга таба, үткәннән киләчәккә борып куючы булды. Аның бөек реформаторлыгының асылы әнә шуннан гыйбарәт. Бу – татарның, бөтен мөселман дөньясының рухи хәятендә инкыйлаб-революция иде. Мәрҗанине Италия ренессансының атасы А.Данте белән чагыштырырга мөмкин. Аның исеме Аурупаның мәшһүр дини реформаторлары Мартин Лютер (1483-1546), Ян Гус (1371-1415) һ.б. белән янәшә торырлык.

Мәрҗанинең бөек каһарманлыгын үз чорында аңлап та, бәяләп тә бетермәделәр. Чөнки ул үзе яшәгән мохиттән, җәмгыятьтән күпкә алга киткән, артык югары күтәрелгән шәхес иде. XIX гасыр уртасында мөселман дөньясында калкып чыккан биек тау башына менү дә, аны аңлау-бәяләү дә җиңел булмагандыр, күрәсең. Әмма бу затның татарның рухи тәрәккыятендәге бөек ролен аннан соң килгән буыннар бик яхшы аңладылар һәм югары бәяләделәр. Г.Ибраһимов, мәсәлән, 1915 елда аның 100 еллык юбилее уңае белән болай дип язган иде:

"Таң алдыннан Чулпан күренә. Чулпан белән бер вакытта җир йөзе тагы ныграк караңгылана.

Мәрҗани – безнең таңыбызның Чулпаныдыр.

Бу матур сүз түгел. Мәрҗани безнең фикри тәкаммел* тарихында нинди мөэссир** икәнен бөтен куәте вә бөтен ачысы белән, тик безнең шикелле егерме яшьләргә кадәр гакыллары бөтен ислам дөньясын каплаган туң вә кара тәгассыб*** астына ябылып, фикерләре сәләф**** сүзләре белән богауланып яткан, соңра азат кылынган вә шул азат кылыну юлында бик авыр изтыйраблар***** кичергән егетләр генә хис итә алачаклардыр".

Шәркыят фәнендә XIX гасыр Ислам реформациясенә нигез салучылар итеп озак еллар мисырлы Җамалетдин Әфгани белән Мөхәммәд Габдәһне атап килделәр. Безнең гасырның икенче яртысында гына мәшһүр галим, танылган ориенталист һәм Исламны өйрәнүче Александр Беннигсен бу мәсьәләгә ачыклык кертте. Ул яңа заман Ислам реформациясенең идеологлары һәм нигезләүчеләре Г.Курсавый белән Ш.Мәрҗани булуын исбатлады. Беннигсен татарларның Русия империясендә колониаль кысаларда бикләнеп, Ислам дөньясыннан аерылган хәлдә яшәве аркасында Мәрҗани идеяләренең үз дәверендә дөньякүләм яңгыраш ала алмавын күрсәтте һәм тарихи дөреслекне торгызу, татар галимнәренең приоритетын кайтару кирәклеген көн тәртибенә куйды.

3

Татар дөньясының бөек реформаторы, фикер инкыйлабчысы-революционер булу белән бергә, Ш.Мәрҗани универсаль галим дә: философ, тарихчы, мөстәшрыйк, илаһият галиме. Филология, археология һәм этнография, медицина һәм фармакология, сәнгать, музыка турында бик мөһим фикерләр әйткән, оригиналь фәнни тикшеренүләр ясаган кеше. Ул Коръәнне тирәнтен һәм этрафлы өйрәнеп, хәдисләрне ныклап анализлап, борынгы Ислам мәдәниятенең бай традицияләрен дәвам иттереп, илаһият тәгълиматы өлкәсендә үз сүзен әйткән, аның ысул-методлары, нигез-назариясе хакында фәлсәфи хезмәтләр калдырган гыйлемдар һәм фикер иясе. Яңа заман Ислам философиясенең күренекле вәкиле. Аның "Нәзурател-хак" (1870), "Мокатдимәте китабы Вәфиятел әслаф...", "Әль-хикмәтел Балига" (1888) исемле хезмәтләрендә дөньяны танып белүнең һәм диалектиканың мөһим мәсьәләләре, иҗтимагый тәрәккыят вә Ислам тәгълиматы, дин вә әхлак, фән белән диннең үзара мөнәсәбәте һ.б.проблемалар тикшерелгән. Хәзерге заман ислам дәүләтләрендәге социаль-сәяси вазгыятьнең үзенчәлекләрен искә алганда, Ислам цивилизациясенең язмышы, киләчәге турында фикер йөрткәндә, Мәрҗани әсәрләрендә күтәрелгән фикер-проблемаларның бүген дә актуальлеге аңлашылыр.

Ш.Мәрҗанинең этрафлы галим булуы тарихка караган хезмәтләрендә аеруча калку чагылды. Күренекле галим, мәдәният эшлеклесе Җамалетдин Вәлиди аны "татар Геродоты" дип атаган иде.

Бу оригиналь, яңгырашы белән матур чагыштыру булса да, мәгънәви яктан, фәнни җәһәттән төгәл түгел. Мәрҗани – яңа заман тарихчысы, татар тарихын тикшерүне ныклы фәнни нигезгә куючы, аның төп принципларын, методологиясен эшләүче. Ул – тарих өлкәсендәге тикшеренүләрне фәнни чыганакларга нигезләүче, татар тарихын өйрәнүчеләрнең фәнни мәктәбенә нигез салучы.

*** Тәкаммел – камиллешү.**
**** Мөэссир – тәэсир, йогынты ясаучы.**
***** Тәгассыб – консерватив.**
****** Сәләф – иске.**
******* Изтыйраб – газаплану.**

(Ахыры 6 нчы биттә).

Русия Президентының тән сакчылары күп булуы мәгълүм. Алар арасында хатын-кызлар да бар, диләр, бу хәбәр дөресме? Мин каратэ белән шөгыльләнәм, ату буенча разряд алдым, инглиз телен беләм. Мин Президентны саклау хезмәтенә эшкә урнаша аламмы?

Оксана, 24 яшь. Казан.

Бу сорауга Федераль караул хезмәте (ФСО) болай җавап бирә: Президентны саклау – җитди хезмәт, шуңа күрә бу хезмәткә урнашу бик кыен. Хәтта ФСБ академиясен тәмамлаган кешеләргә дә элиталы сак подразделениесенә эләгү гарантияләнми. Әлеге хезмәт белән хатын-кызлар да шөгыльләнә, алар – югары квалификацияле һөнәр ияләре. Гомумән, эшкә урнашу мәсьәләсе – ябык тема, бу урынга вакансияләр булмый диярлек.

Мөселманнар ураза аенда авыз ачу, сәхәр вакытын сәгатькә карамыйча да беләләр, диләр. Бу – дөресме?

Г.СӘХАПОВ. Курган.

Чынлап та, беләләр. Ялгышмас өчен алар кара һәм ак җеп алалар. Җепләрне аерып булса (ачык күреп), димәк, авыз ачарга иртәрәк, аерып булмаса – табынга утырып авыз ачар вакыт. Сәхәр ашына утыру да шулай билгеләнә.

Ленин турында беренче нәфис фильм чит ил кино төшерү осталары тарафыннан юлбашчы исән чакта ук төшерелгән дип ишеттем. Дөресме икән?

Мәрьям Д. Әлмәт.

Әйе. Беренче фильм – "The Land of Mustery" ("Серле ил") 1920 елда ук Америка режиссеры Гарольд Шоу тарафыннан эшләнгән. Бу турыда безгә кино тарихчысы Рәшит Янгиров әйтте. Русиядә Ленин турындагы беренче фильмны 1927 елда ("Октябрь") Сергей Эйзенштейн төшергән дип ялгыш фикердә торалар.

Ленин турындагы фильмны төшерү идеясе Англиядә большевизм белән көрәш буенча оештырылган махсус подразделение хезмәткәре Бэзил Томпсон башына килә. Советка каршы фильмны төшерү өчен акча бүлүне дә ул оештыра.

Фильмның кыскача эчтәлеге болай: кулак малае Ленофф һәм ярлы, ләкин чибәр кыз өйләнешергә җыеналар. Шунда патша малае килеп чыга да, Леноффның кәләшен аерып ала. Тәмам түбәнсетелгән һәм ярсыган Ленофф революцион хәрәкәтне җитәкли һәм патша самодержавиесен бәреп төшерә. Илдә канлы террор башлана һәм нәтиҗә күңелсез: Ленофф акылдан шаша. Фильм митинг күренеше белән тәмамлана. Трибунадан Ленофф "Алла юк. Булса мине суксын!" – дип кычкыра. Аллага тел-теш тидергәнне өнәмәгән бер солдат, мылтыктан атып, баш каһарманны үтерә. Фильмның премьерасы 1920 елның 7 июлендә Лондонда була. Фильмны совет илчесе Леонид Красин да карый. Ул фильмны күргәч, хәйран кала һәм, аны күчертеп алып, Мәскәүдә Ленинның үзенә күрсәтергә уйлый. Һәм күрсәтә дә! Ленин фильмда үзен көч-хәл белән таный. Ә танып алгач, эче катып көлә башлый. Монда уйланыр нәрсә бар... Ленин да, фильм герое кебек, үләр алдыннан зиһенен югалта ич.

("А и Ф").

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

Илаһият белеме, тарих һәм фәлсәфә, гуманитар фәннәрнең башка өлкәләренә караган 30дан артык хезмәт калдырган галим.

Табигый ки, Мәрҗани методологиясе совет чоры тарих фәне тарафыннан кабул ителмәде, чөнки ул материалист түгел, идеалист дип саналды. Әмма Мәрҗанинең методологик концепцияләре аңа кадәргә Ислам дөньясындагы тарих фәненең торышы белән чагыштырганда күпкә алга китеш, Ауразия тарихын тикшерүдә җитди казаныш иде. Мәскәү галиме, күренекле ислам тарихчысы профессор А.Сагадеев, мәсәлән, аның мөстәшрыйк галим буларак Аурупа ориенталистларыннан йөз елга алда баруын билгеләп үтә. Бер дә арттырмыйча әйтергә мөмкин, аның 2 томлык "Мөстәфадел әхбар"е, 6 томнан торган "Вәфиятел әслаф, тәхиятел әхлаф", "Галялят аз-заман" исемле фундаменталь хезмәтләре милли тарих фәненең алтын фондын

рында татар ренессансының дистәләгән якты йолдызлары кабынды. Бу яңа буын талант ияләренең фәнни-иҗат, иҗтимагый эшчәнлек өлкәсе, даирәсе төрле-төрле булса да, рухи генеологиясе бер – Шиһабетдин Мәрҗани. Омтылган максатлары уртак – татар дөньясын үзгәртү, туган халкына хезмәт итү, аны азатлыкка алып чыгу, башка халыклар һәм дәүләтләр арасында лаеклы урын алу, милләтне саклау, аның телен һәм мәдәниятен үстерү иде. Аларның бер төркеме Мәрҗанинең илаһият гыйлеме, дини эшчәнлек өлкәсендәге традицияләрен дәвам иттерделәр, үзләренең талантын рухани эшчәнлеккә багышладылар һәм бу өлкәдә шөһрәт казандылар. Алар дин эшлеклеләре, илаһият белгечләре генә түгел, татар тарихын, гомумән, Ислам дөньясын өйрәтүче тарихчылар, философлар, мөстәшрыйклар да иде. Менә алар: Риза Фәхретдин, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди.

Икенчеләре – мәшһүр сәясәтчеләр, татарлар арасында гына түгел, Русиядә, гомумән, төрки дөньяда, ислам

Татарның яңарыш Чулпаны

тәшкил итәләр. Алар Мәҗани артыннан килгән берничә буын татар тарихчылары өчен фәнни мәктәп тә, таяныч та, кыйммәтле чыганак та булып хезмәт иттеләр, киләчәктә дә шулай булып калачаклар.

Ш.Мәрҗанинең тарихчы буларак талант куәте, фәнни-тикшеренү диапазоны барыннан да бигрәк татар тарихын тикшерүгә юнәлдерелде. Ул аны буеннан-буена, борынгы дәверләреннән башлап – Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Русия дәүләте составындагы чорларны да кертеп – XIX гасырга кадәрге чорларына кадәр колачлап ала, әтрафлы һәм тирәнтен тикшерә. Татарның этногенезы һәм этник компонентлары, бер халык, хәзергечә әйткәндә, милләт булып формалашу тойгысы, тел һәм әдәбият тарихына караган башка фәнни мәсьәләләрне күтәрә, алар хакында мөһим фикерләр әйтә.

Мәрҗанинең әдәби мирасында Урта Азия халыкларының, гомумән, төрки кавемнәренең тарихына караган хезмәтләрнең дә зур урын алып торуын әйтергә кирәк. Боларның һәммәсе аның татарларда гына түгел, Русия мөселманнары арасында беренчеләрдән булып гуманитар фәннәргә нигез салучы икәнен раслыйлар.

4

Шиһап Мәрҗани эшчәнлегенең мөһим бер тармагы – аның төп хасиятеннән – реформаторлыгыннан килеп чыга торган һәм фәнни-практик эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән, бергә үрелеп барган мәгариф эшчәнлеге, мәгърифәтчелеге. Бу эшчәнлек ике аспектта – тар һәм киң мәгънәдә каралырга, бәяләнергә тиеш. Ул, бердән, дин әһеле һәм мөдәррис буларак, татар мәдрәсәләрендә хөкем сөргән кадимчелеккә, искергән укыту ысулларына кискен каршы чыга, Казанның иң гали, иң атаклы саналган мәдрәсәсендәге укыту-тәрбия системасына җитди үзгәрешләр кертә. Мәдрәсә шәкертләренә Ислам тәгълиматын, шәригать кануннарын өйрәтү, гарәпчә-фарсыча кадим китапларны ятлату белән чикләнмичә, фән нигезләрен – математика, астрономия, география, биология, гуманитар фәннәрне укытуны кертә, медицина һәм фармакология, әдәбият, сәнгать белеме нигезләре белемнәре белән таныштыра. Мөдәррис буларак, Мәрҗанинең педагогик кредосы гуманлылык, шәхеснең мөстәкыйль фикерләү хокукын тану һәм укыту-тәрбиядә шуңа таянудан, кешенең иҗат эшчәнлегенә, дөньяны танып белү һәм тормышны үзгәртеп кору сәләтенә тирән ышанудан гыйбарәт. Ш.Мәрҗани – яңа заман татар милли педагогикасының юл башында торучы, аны нигезләүче. Педагогика өлкәсе галимнәре, милли мәгариф тарихын өйрәнүчеләр галим эшчәнлегенең бу тармагын бөтен үзенчәлеге, тулылыгы һәм тирәнлеге белән тикшерерләр, бәяләрләр, дип ышанырга кирәк. Бездә әле мәгариф тарихы да, милли педагогиканың бай хәзинәсе дә, "Мөхәммәдия", "Галия", "Хөсәения", Иж-Буби мәдрәсәләре тарихлары да, Г.Баруди, З.Камали, Бубилар кебек мәшһүр укытучыларның педагогик мираслары да тикшерүчеләрен көтә. Ә бит аларның барысы да Ш.Мәрҗани хәзерләгән, эшкәрткән җирлектә, ул чәчкән орлыклардан үсеп чыккан җимешләр иде.

Ш.Мәрҗанинең мәгариф өлкәсендәге тагын бер зур хезмәте – Казандагы татар укытучылар мәктәбен оештыручыларның, аның укыту-тәрбия системасын нигезләүчеләрнең берсе булуы. Бу уку йорты милли мәгариф, мәдәният, азатлык хәрәкәте тарихында зур урын тота. Анда М.Корбангалиев, Г.Исхакый, Х.Ямашев, Г.Колахмәтов, С.Максуди, Ф.Туктаров, Ш.Мөхәммәдъяров, М.Солтангалиев һ.б. күренекле шәхесләр белем алган. Аның укыту-тәрбия, татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү, фән, иҗтимагый тәрәккыят өлкәсендәге бай традицияләрен 1917 елдан соң Казанның көнчыгыш педагогика институты – хәзерге педагогика университеты дәвам иттерде.

Икенче яктан, Мәрҗани – киң мәгънәдә, үзенең җаны, бөтен барлыгы белән мәгърифәтче, XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килгән, бөтен Русия мөселманнары арасында киң таралган, көчле яңгыраш алган, XX гасыр башында илдә җәелгән милли-азатлык хәрәкәтенең олы елгасын барлыкка китергән җәдитчелеккә капка ачкан, юл күрсәткән шәхес. Бу хәрәкәтнең җитәкчесе һәм идеологы, бөтен төрки дөньяның мәшһүр мәгърифәтчесе һәм сәясәтчесе И.Гаспринский Ш.Мәрҗани идеяләрен дәвам иттерүче, гамәлгә куючы булды.

Мәрҗани ачкан иҗтиһат капусыннан XX гасыр башла-

илләрендә танылган идеологлар, фикер ияләре, дәүләт эшлеклеләре И.Гаспринский, Й.Акчура, С.Максуди, З.Вәлиди, М.Солтангалиев. Өченчеләре – Г.Тукай, Дәрдмәнд, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Камал, К.Тинчуриннар. Болары – татар ренессансының мәдәни йолдызлары, хәзерге заман татар мәдәниятенә нигез салучылар.

Дүртенчеләре – тарихчылар, татар халкының бай тарихын, рухи-мәдәни традицияләрен тикшерүчеләр: Х.Г.Габәши, Г.Гобәйдуллин, Һ.Атласи, Җ.Вәлиди, Г.Баттал һ.б. Аларның барысы да Ш.Мәрҗанинең рухи каһарманлыгын югары бәяләделәр, аны үзләренең остазы дип санадылар.

Безнең гасыр башында аларның бөтенесенең дә уртак фикерен белдергән халык шагыйре Г.Тукайга сүз бирик:

... Тулган ай күк балкып чыккан Шиһап хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

– Кемнән алдык дин фикрендә истикъляльне?*
Кем ташытты ошбу бәхет, бу икъбальне?**
Ничек өздек "уйлауда да" коллык җебен? -
"Хәзрәт"тән ул безгә мирас булып калды.

Ф.Әмирхан аны "милли Тәрәккыйпәрвәрлекнең әүвәлге сугышчысы" дип атады һәм "әгәр Мәрҗани бер 50-70 ел соңрак туган булса, "Татарның инкыйлабе фикериясен әйдәп баручыларның берсе булыр, үзенең олы таланты, фәнни хезмәтләре белән исеме Аурупа фән академияләре әгъзалары арасында мөхтәрәм урын алыр иде", дип бәяләде.

1915 елда Ш.Мәрҗанинең 100 еллыгы уңаеннан үткәрелгән юбилей аның тормышын, фәнни-иҗат эшчәнлеген, әдәби мирасын өйрәнүнең югары ноктасы, триумфы иде. 1917 елдан соң аның исеме дә, әдәби мирасы да татарның рухи тормышында актив кулланылыштан читкә этәрелде. Моның төп сәбәбе – Мәрҗани идеяләренең, әдәби мирасының совет системасы, большевизм идеологиясе кысаларына сыя алмавында, бу олы шәхеснең эшчәнлегендә һәм иҗатында илаһият тәгълиматының фән белән янәшә, үрелеп барган булуында. Ә бу татар рухи тәрәккыятенең үзенчәлеге иде. Марксизмның аерылгысыз юлдашы булган сугышчан атеизм Мәрҗани мирасын кабул итмәде, читкә этәрде.

XX гасыр ахырында татарларга ренессанс яңадан әйләнеп кайтты. Ш.Мәрҗани идеяләре, остазның рухи мирасын бу милли яңарышның яңа ташкынын көчәйтергә, татар дәүләтчелеген торгызу хәрәкәтен җимерелмәслек итеп үстерергә, тирәнәйтергә ярдәм итәргә тиеш. Көн тәртибенә аның хезмәтләрен оригиналда да, татар һәм урыс телләрендә дә тулысы белән бастырып чыгару мәсьәләсе килеп баса. Бу – Татарстан Фәннәр академиясе, аның Тарих институты җилкәсенә төшәчәк мөһим эшләрнең берсе. Шул ук вакытта аның исемен мәңгеләштерү дә бик актуаль. Казандагы бер мәчетнең генә Мәрҗани исемен йөртүе киң җәмәгатьчелекнең, татар халкының бу олы каһарманга рәхмәт вә ихтирам хисләрен канәгатьләндереп җиткерми. Мәркәзебезнең тарихи урамнарының берсе, һичшиксез, аның исеме белән аталыр, шәһәр үзәгенең матур бер урынында бөек остазның мәһабәт һәйкәле дә калкып чыгар, дип ышанырга кирәк. Ниһаять, Казанда Мәрҗани музеен булдыру да зарури.

Бүгенге тантана – Мәрҗанинең 100 еллыгыннан соң аны зурлап, хөкүмәт карары белән үткәрелә торган беренче рәсми юбилей. Тагын бер елдан Мәрҗанинең вафатына да 110 ел тулачак. Ул дөньядан киткәннән соң күпме сулар аккан, татарның күпме күз яшьләре түгелгән, ничәмәничә буыннар алмашынган. Ул яшәгән XIX гасыр күптән үтеп, инде XX гасыр тәмамланып бара. Ерактан шаулап килгән язгы ташкын кебек, егерме беренче гасыр тавышлары ишетелә. Тарихтагы гасырлар алмашыну, мең еллыклар бусагасын үтеп, ашкынулы рәвештә киләчәккә барган чакта татар күңелендә Мәрҗани рухы яши, безнең белән бергә аның җанлы күләгәсе бара. И.Гаспринский сүзләре белән әйтсәк, Мәрҗани юбилейлары аның үзе өчен түгел, безнең өчен, татарның киләчәге хакына кирәк. Мәрҗани – татар халкының даны һәм горурлыгы.

Бөек остазның рухы тыныч булсын!

*** Истикъляль – бәйсезлек.**
**** Икъбаль – якты киләчәк.**

Аяк баскач газиз җиремә

Усаклының үрләренә менсәм,
Туган якка карыйм – күренә:
Каеннарым шаулап яфрак ярган,
Аккошларым төшкән күленә.

Җаным тетрәп атылырга тели,
Утны-суны кичеп сикерә.
Битләремнән сөеп җилләр үпте,
Гөлләр сипте юллар читенә.

Туган якның күкрәүләрен тоям,
Яңгыр суларына чылансам.
Сагышларны татыган кеше аңлар,
Күзләремнән яшьләр чыгарсам.

Әллә яшен ялгангандай була
Йөрәк тулы кайнар хисләргә.
Узган юлларыма түгелеп калган
Тальян моңы айлы кичләрдә.

Түбәләрем күккә тимәгәндер,
Аяк баскач газиз җиремә.
Сагынганда битләремне куям
Туган яктан искән җилеңә.

Якты ялар итеп күзалладым,
Килечәкне җырда көйләдем.
Бушка гына калды юрауларым,
Хыял канатларым, көйрәдең.

Дала кошы сыман иркенлекне,
Чиксезлекне, җаным, теләдең.
Бу тормышның михнәтеннән башка
Юанырлык назын күрмәдем.
Исәреклә́р, угры, фәхишәләр
Арасына килеп юлыктым.
Аза-туза адәм балалары –
Гамьсез кешеләрдән курыктым.

Хыял канатларым яраланды,
Бу заманда нәрсә күтәмен.
Тормыш шау-шулары уртасында
Бөргәләнеп яшим күптән мин.

Мине табарсың

Юксынганда сәхрәләргә чык син,
Булган сагышларың таралсын.
Кырларымда тракторлар гөрли,
Буразнадан килсәң табарсың.

Фәрит СУФИЯРОВ

Туган якка күбрәк төшә бугай Хәтта кояшның да яктысы...

Төштә күрәм

Туган якның чиксез киңлекләре,
Яшел үзәннәре, гөлләре,
Җырлап аккан чылтыр чишмәләре
Гашыйк итәр әллә кемнәрне.

Мин аларны күңелемдә йөртәм,
Хисләр таша ургып тирәндә.
Иртән торып мин юксынып йөрим,
Туган җирне төштә күрәм дә.

Оялардан очып ерак киттек,
Туфрак тарта җанны, җирсетә.
Уйландырып, борчып, тынгы бирмәс
Без бервакыт җәннәт күрсәк тә.

Күбәлекләр булып очты микән
Җаныбызның әллә яртысы?
Туган якка күбрәк төшә бугай
Хәтта кояшның да яктысы.

Язмыш уртак

Ахры...
Йөргән юллар урау булды,
Үткәннәргә алып кайтмады.
Туган җирем, яшьлек күкрәүләре,
Бәгыремдә һәрчак сакланды.

Авылдашлар, күңелем сезнең белән,
Ерак түгел безнең аралар.
Горур булып биек таулар гына
Арабызда басып торалар.

Тормышыгыз матурлана бара,
Сөенеч бар һәрбер кешедә.
Кыңгыраулы пар атларда быел
Кемнәр тагын килен төшерә?

Күпләрегез яңа йорт өлгерткән,
Өй котларга кемнәр җыена?
Юл уңае төшсә, мин дә кайтам
Берегезнең бәбәй туена.

Газиз туфрак безне очраштыра,
Юлларыбыз үтми бер читтән.
Кайда гына инде яшәсәк тә,
Язмыш уртак, язмыш бер икән.

Хыял канатларым яралы

Сугыш еллары да, ачлыгы да
Туры килде малай чагыма.
Хәтеремнән юып ташламадым,
Моңсулыгым йөздә чагыла.

Авыр уйларыңны читкә ташла,
Башка хисләр синдә яңарсын.
Чалгы янап, болыннарны иңлим,
Печән пакусыннан табарсың.

Йөргән сукмагымда гөлләр үскән,
Түшләреңә өзеп кадарсың.
Хезмәт дәрте белән яныл яшим,
Күзләремә кара – танырсың.

Айлы төндә урамнарга чыксаң,
Гармун тавышларын тыңларсың.
Юксынганда, борчылганда, килеп,
Җырларымнан мине табарсың.

Байлыгым

Биләүләргә, әни, төргәнсең син,
Назларыңны миңа биргәнсең.
Кояш кебек балкып елмайгансың,
Кайнар сулышыңны өргәнсең.

Алтын канатлы бул, күз нурым, дип,
Иртән-кичен бәхет теләдең.
Отып алдым бишек җырларыңны,
Синең телең белән телләндем.

Күккә, айга, ерак йолдызларга
Кулларымны сузып эндәштем.
Күңелемә минем моң салгансың,
Сандугачлар белән серләштем.

Тел ачкычын мирас итеп бирдең,
Юмарт булуыңны яраттым.
Телем белән таптым дошманымны,
Дусларымны җайчак югалттым.

Сөенсәм дә үзем, көенсәм дә,
Эч пошырган уйдан айнудым.
Халкымның ул бетмәс хәзинәсе –
Туган телем – минем байлыгым.

Җир яме

Күгем зәңгәр чатыр кебек,
Җирем – яшел бишегем.
Анадан тугач та күрдем:
Дөнья матур – юк шигем.

Ил картлары кебек тыйнак
Чалмалы биек таулар.
Бөйрәм күлмәкләрен кигән,
Чукларын аскан таллар.

Дәрьяларым дулкынлана,
Егетләр кебек ярсу.
Сары гөрәбә төсендә
Күренә күзгә басу.

Кызлар кебек асыл булып
Җиремдә үсә гөлләр.
Куанычы белән килсен
Миңа бу якты көннәр.

Таңнар, шәфәкълар балкышы
Нурга күмә кич-иртән.
Чишмәләрнең көмеш моңын
Сәхрәләрдә ишетәм.

Күз камаша бизәкләрдән,
Көн-төн чигү чигәсең.
Яшь киленнәр кебек җирем,
Сокланырлык чибәр соң!..

Юлаучыга юлдаш булам

Тауга менсәм, тау буласым килә,
Моңы булам аккан чишмәнең.
Күккә карыйм тәрәзәмне ачып,
Йолдыз булып балкыйм кичләрен.

Мин камышы булам зәңгәр күлнең,
Дулкыннарын ярда кочармын.
Мин шонкары булам кыяларның,
Офыклардан биек очармын.

Карны тишкән умырзая булам,
Җиргә якты бизәк өстәрмен.
Кышы, язы, җәе, көзе булам,
Күз камашкан төрле төстә мин.

Кешеләрнең мин шатлыгы булам,
Мирас итеп барын өләшәм.
Кардәшләрем итеп якын күрәм,
Сәлам биреп сезгә эндәшәм.

Юлаучыга юлдаш булып барам,
Маяк булам карлы юлларга..
Көмеш кыңгыраулар кебек чыңлап,
Җырым барсын ерак илларга.

*Башкортстан,
Яңавыл шәһәре.*

шигырь 6 нечкәлек билгесе белән языла

Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк

Илбашларның "авыр көннәре"

Танылган астролог Павел Глоба журналистларга 1998 елда һәм якын киләчәккә астрологик фаразларын игълан итте.

■ Деноминация тышкы яктан шома үтәр, ләкин аның күңелсез нәтиҗәләре тиздән үзен сиздерер. Ике ел ярым вакыт үтүгә чираттагы акча алмашыну көтелә, анысының зыяны тагын да зуррак булачак.

■ *1 марттан 15 апрельгәчә Президентның сәламәтлеге өчен "авыр көннәр" көтелә. (Глоба Б.Ельцинны беренче генә тапкыр куркытмый инде). Ләкин, Глоба фикеренчә, бу курку – файдалы. Президент һәм аның яраннары алдан ук хәстәрен күреп, усал язмышны куркытып торачак. Бу юлы да авыру шома гына үтеп китсә, Президентның яңа срокка сайлануы да ихтимал.*

■ *Черномырдин өчен бу ел бигүк күңелле булырга охшамый. Аны хакимияттән читләштерү мәсьәләсе кискен куелачак. Кем белә, бәлки, бары да үтәр.*

■ *Чубайс Игезәкләр билгесе астында туган кеше, бәхет аны гыйнвар азагына кадәр генә озата бара, шуннан соң язмыш аңа аркасы белән борылачак. Ләкин бу кеше судан коры чыгарга оста булганлыктан, аның башка өлкәдә, башка урында – барыбер хакимият башында калкып чыгуы бар.*

■ *Питер шәһәрендә хакимият башындагыларга һөҗүмнәр көтелә. Беренче чиратта Яковлевка сак булу кирәк.*

■ *Авиаһәлакәтләр 1997 елның декабрендә дөньяны дер селкеткән иде, гыйнвар азагына дөнья бераз тынычланыр. Бу афәтләрнең сәбәпчесе – Җиргә якын очкан комета (самолет бакларындагы су кушып сыегайтылган ягулык түгел). Комета узып китәр, самолетлар оча бирер.*

■ *Патша гаиләсе сөякләре җәйгә кадәр Урал туфрагында ятачак. Россель сөякләрне тиз генә биреп җибәрергә ашкынып тормый һәм, гомумән, аларның Санкт-Петербургка кайтарып күмелүе – бәхәсле.*

■ *1998 елның иң куркыныч көне – 22 август. Бу көнне нәрсәдер булмый калмас. Хәтта 1991 елгы август вакыйгалары кабатлануы мөмкин. Бу көнне Кояш тотыла.*

■ *Мәскәүдә бары да тыныч. 1998 ел азагында бик шаулы бер бәйрәм буласы.*

■ *Мәскәү метросын нәрсәдер көтә. Бигрәк тә башкаланың көньягында. Хәерле булсын.*

■ *Гельмут Кольны да шатлыклар көтми. Аның сәяси рейтингы түбәнәя бара. Аның иң түбән дәрәҗәгә җитеп, дәүләт рулен кулыннан ычкындыруы да мөмкин.*

■ *Принцесса Диананың үлеменә китергән яңа фактлар билгеле булачак – королева гаиләсендә чираттагы низаг туып килә.*

20-25 елдан соң Бөекбританиядә монархия бетәчәк.

■ *1999 елда Кавказ сугышы янә башланачак. Һәм ул 2001 елгача дәвам итәр. Сугыш хәрәкәтләре Русиянең көньягына җәелер. Русия гүя вак кисәкләргә таркала бара.*

■ *Русиянең икътисади чәчәк атуы 2003 елларда башланачак.*

Астролог П.Глоба менә шуларны фараз итә. Астролог ни дәрәҗәдә хаклы – 1998 ел ахырында күрербез, иншалла.

(АиФ).

Мөнәсәбәт

Уфаның милли сәясәте Мәскәүгә файдалы

Мәскәү матбугатында Башкортстандагы хәлләргә багышланган мәкаләләр еш басылып тора. Аларның һәркайсында диярлек республика җитәкчелеген, хакимият органнарыннан кайбер башка милләт вәкилләрен кысрыклап чыгарып, алар урынына башкортларны куялар, дип гаеплиләр.

Бу сүзләрдә хаклык юк түгелдер. Мәсәлән, башкортлар республикада яшәүчеләрнең 22 процентын гына тәшкил итүгә карамастан, Башкортстан парламентының югары палатасында башкорт депутатлары 38,7 процент, ә түбән палатада исә бу сан 55 процентка җитә. Моңа Башкортстанның сайлау турындагы законы мөмкинлек бирә: республикада сайлау округлары административ районнар белән тәңгәл килә – нәтиҗәдә аз санлы авыл районнары, шәһәрләргә караганда, хакимият органнарына төп халык вәкилләрен күбрәк күрсәтә ала. Уфаның үзендә урыслар халыкның 57 процентын тәшкил итсә дә, шәһәрнең җиде районыннан өч кенә хакимият башлыгы урыс милләтеннән. Башкаланың мэры да славян түгел.

Ләкин бу мәсьәләгә икенче яссылыктан күз салыйк. Бүгенге статистика буенча, республикадагы халыкның 39,3 проценты урыслар, 28 проценты – татарлар. Чынында исә республикада татарлар күпкә артыграк. Мәсәлән, Татарстан белән чиктәш районда яшәүчеләр татар телен үз ана телләре итеп саныйлар. Татарлар үзләре дә аларны аерым сәбәпләр аркасында кайчандыр башкорт булып язылган үз канкардәшләре дип исәпли. Кемнәрдер моны, бәлки, җитәкче урыннарга утыру җиңелрәк һәм тизрәк барсын өчен дип тә эшләгәндер. Ә менә башкорт милли радикаллары күзлегеннән караганда, бу – республиканы "татарлаштыруның ачык мисалы". Шунысы да сер түгел, совет заманында партия обкомы секретарьлары нәкъ менә "татар телле" башкортлардан билгеләнә иде.

"Бүгенге көндә башкортларны "татарлаштыру" урыслаштыру мәсьәләсеннән кискенрәк тора, – ди башкорт милли хәрәкәте идеологларының берсе. – Татарлар һәм башкортлар төрки телләр төркеменә кергән кардәш халыклар. Аларның телләре дә берберсенә бик якын. Татарлар безне хәтта "татардан бозылган", "икенче сортлы" татарлар дип саныйлар. Бу вазгыятьтә башкортларның татарлар эчендә эреп бетү куркынычы гаять зур. Кайберәүләр инде башкорт теленең көнбатыш шивәсен, ягъни шул ук татар телен мәктәпләрдә укыта башлау мәсьәләсен дә күтәреп чыктылар. Республика җитәкчеләре арасында "яшерен" татарлар да күп. Паспортларында башкорт дип язылган булса да, аларның ана теле – татар теле. Башкортлар Русиягә кушылган мәлләрдә күпчелек халыкны башкортлар тәшкил иткән. Һәм башкортлар үзләрен беренче чиратта төркиләр итеп түгел, нәкъ менә башкортлар итеп тойганнар. Безнең халыкның милли үзаңы һәрвакыт югары булды. Моңа ачык мисал: Октябрь революциясеннән соң беренче булып нәкъ менә Башкортстан Республикасы төзелде". Милли хәрәкәт идеологының фикеренчә, республикага исем биргән халыкка җөмһүрият парламентында 50 процент квота бирелергә тиеш. Чөнки законнар чыгарганда, хөкүмәтне төзегәндә, министрлыкларда кадрлар, предприятие һәм учреждениеләргә җитәкчеләр, уку йортларына ректорлар өзерләгәндә төп халык мәнфәгатьләрен яклау зарур. Төп этносны яклауның мондый ысулларын (бу терминга аңлатма бирү – үзе үк бәхәскә урын калдыра) "национал-радикаллар", республикада төп милләт азчылык булган очракта һәрвакыт үз файдаларына кулланалар.

Моңа ачык мисал итеп Латвия белән Эстонияне китерергә була. Анда гражданлык турындагы законнар, азчылык милләтләрдән сан буенча бик аз гына өстен булуга карамастан, төп этносларга гамәли яктан үз дәүләтләренең хакимият структураларын тулаем монополияләштерүгә мөмкинлек ачты.

Башкортстандагы төп халык исәбенә кермәгән милләт вәкилләренең хәле, әйтергә кирәк, Абхазия яки Балтыйк буе илләре белән чагыштырганда күпкә яхшырак. Дәүләт – административ системасыннан башка тармакларда татарлар һәм урыслар, дискриминация тою түгел, хәтта, киресенчә, төп милләткә караганда югарырак урыннарда эшлиләр. Мәсәлән, промышленность предприятиеләре җитәкчеләренең 48 проценты – урыслар. Өстәвенә, урыслар һәм татарларның уртача матди хәле башкортларга караганда яхшырак. Йөз башкорт гаиләсенең 22,8 процентында гына автомобиль булса, урыслар һәм татарлар арасында бу күрсәткеч 34,3 һәм 29,7 процент тәшкил итә. Тулай торакларда башкортларның 8,5 проценты яшәсә, әлеге сан урысларда – 3,8, ә татарларда – 5,7 процентка тигез. (Бу саннар Рәшит Ирназаровның "Равенство этносов в республике Башкортстан" дигән китабыннан алынды).

Моны ничек аңларга? Башкортларның күпчелеге Урал буенда икътисади яктан артта калган авыл районнарында тупланып яши. Ә совет заманында барлык капитал нигездә республиканың үзәк, көньяк һәм көнбатыш регионнарына җибәрелде, чөнки ул регионнарда икътисади потенциалның 90 проценты тупланган иде.

Тагын бер аңлатма бар. Элек, игенче татарлардан аермалы буларак, башкортлар күчмә тормышта яшәгән. Тәҗрибә шуны күрсәтә: элек күчмә тормыш алып барган халыклар базар икътисадына җир эшкәртү белән шөгыльләнгән утрак тормышлы халыкларга караганда авыррак яраклаша. Башкортстандагы вазгыять Кыргызстандагы хәлне хәтерләтә. Анда кыргызлардан кала ике эре этнос вәкилләре – урыслар һәм үзбәкләр яши. Бизнеста үзләренә караганда уңышлырак эшләүче үзбәкләрдән һәм урыслардан арыну өчен, национал-радикаллар милекне хосусыйлаштыру вакытында республикага исем биргән халык өчен хәтта махсус квота кертүне таләп итеп чыктылар.

Әмма, Уфа җитәкчелеге нинди генә "мотивлар" буенча эшләмәсен, факт факт булып кала: "титуллы булмаган" халык вәкилләре җирле хакимият структураларыннан әкренләп кысрыклап чыгарыла бара. Бәхәссез ки, мондый сәясәт алып бару кеше хокукларын бозуга керә. Шулай да төшенергә тырышып карыйк әле: Уфаның мондый эшчәнлеге Мәскәү мәнфәгатьләренә ничегрәк җавап бирә икән?

Казанда да, Уфада да татар-башкорт конфедерациясен төзү идеясе бик популяр. Моның перспективада булу мөмкинлеге турында Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов бер әңгәмәсендә әйткән иде. Бу ике республиканың Мәскәү белән мөнәсәбәтләрдә шактый үзсүзле икәнен исәпкә алсак, 8 миллион халыкны берләштерәчәк конфедерация үзәкнең (Мәскәү) бу регионда болай да бик зәгыйфь булган йогынтысын бермә-бер киметәчәк.

Башкортстанны Казакъстаннан 30 чакрымлы Ырынбур өлкәсе җире аерып тора. Ә бит анда да татарлар һәм башкортлар шактый тыгыз тупланып яши. Конфедерация төзелгән очракта куәтле яңа альянс кардәш халык мәдәнияте һәм теле хөкем сөргән Казакъстанга чыгар өчен чикләрне яңабаштан сызу мәсьәләсен күтәреп чыга ала. Ә моннан инде башка төрки республикаларга – Урта Азиягә кул сузымы гына кала. Мортаза Рәхимов үз әңгәмәсендә ("Н.Г.") Башкортстанның бүгенге чикләре ясалма рәвештә сызылган, ул чикләр республика Русия эчендә калсын өчен махсус исәп-хисап белән билгеләнгән, иң мөһиме – ул чикләр Башкортстан союздаш республика статусын дәгъва итмәсен өчен эшләнгән, диген иде.



А.ГУРСКИЙ рәсеме.

Шулай итеп, Уфаның титуллы милләтне яклау юнәлешендә алып барган бүгенге сәясәте Кремль мәнфәгатьләренә бик тә туры килә. Республика хакимияте структураларында башкортлар никадәр күбрәк булса, Казан-Уфа альянсына урын шулкадәр азрак кала. Беренчедән, хакимият структураларының "башкортлаштырылуы" Казан ягыннан ризасызлык тудырмый калмаячак (бүген әле бу дәгъвалар турында сүз алып барылмый), ә бу, үз чиратында, күршеләр арасында мөнәсәбәтләргә тискәре йогынты ясаячак. Икенчедән, мондый берләшү, беренче чиратта, башкорт сәяси элитасы өчен файдалы түгел, чөнки яңа мөнәсәбәтләрдә Казан, нисәң дә, лидерлыкны үз кулына алачак. Һәм шуңа күрә бу очракта "титуллы милләтнең" (димәк, башкортларның) үз республикасында да алдынгы, өстен сәяси позицияне саклап кала алуы бәхәсле.

Игорь РОТАРЬ.
("Н.Г.")

Еллар ызанында очрашу

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җырчысы, Татарстанның халык артисты Клара ХӘЙРЕТДИНОВА белән без 1997 һәм 1998 еллар ызанында очраштык, күзгә-күз карап озак кына сөйләшеп утырдык.

– Клара ханым, 1997 ел тарихка кереп бара инде. Сезнең йөрәктә ул нинди эз калдырды?

– Хәрәкәттә – бәрәкәт, дигәндәй, ел азагы сәфәрләргә бик бай булды. Ноябрь ахырыннан алып, декабрьнең уннарына кадәр ерак чит илләрдә – Һолландия, Алмания һәм Бельгиядә театрыбызның гастрольләре үтте. Анда бер төркем артистларыбыз йөри иде инде, без дә "Борис Годунов" спектакле белән килеп кушылдык. Мин ул спектакльдә шинкарчы хатын партиясен җырлыйм. Борис партиясен элек Зур театрда эшләгән, ә хәзер Нью-Йоркта яшәүче Михаил Крутиков башкарды.

Тамашачылар спектакльне яратып, җылы кабул иттеләр, дәррәү алкышларга күмделәр, аягүрә басып озатып калдылар. Әйтергә кирәк, Алманиядә гастрольләребез аеруча уңышлы үтте.

– Сез, "Борис Годунов", дигәч йөрәк әллә нишләп куйды. Югыйсә, ерак чит илләргә үзебезнең милли операны алып чыксагыз, ул да шундый уңыш казанса, нинди күңелле булыр иде. Шундый җырчыларыбыз, композиторларыбыз була торып...

– Бу турыда күп сөйләнде, күп язылды инде. Милли опера мәсьәләсе хәзер чияләнгән бер төенгә әйләнмәде микән? Уйлап-уйлап карыйсың да, бөтен нәрсә милли репертуарга барып тоташа, дигән нәтиҗәгә киләсең.

– Быелгы сезоныгыз да моннан 50 елдан артык язылган "Алтынчәч" белән ачылып киткән иде ләбаса.

– Анысы да бик сирәк уйнала. Дөрес, соңгы вакытларда Бату Мөлековның "Сөембикә" исемле операсын әзерләү бара.

– Әмма ни өчендер бик озакка сузылды инде.

– Әйе шул. Ә шулай да, милли репертуар мәсьәләсе, иң әүвәл, театрыбызда Нияз Даутов кебек шәхесләр булмау белән бәйле.

– Сезнең режиссерыгыз да юк бугай бит.

– Юк шул. Менә шундый театр өчен янып-көеп йөрүче зур шәхес, музыка белгече булсын иде. Нияз Даутов бит ул безне – шәкертләрен үз тирәсенә җыеп, туплап, һәр адымыбызны, һәр сулыш алуыбызны белеп-тоеп тора иде. Ул безне бик күп нәрсәгә өйрәтеп калдырды. Ул өйрәткәннәр, күрәмсең, гомеребез буена җитәрлек булды. Ә бүгенге көндә театрда җырчының кадере бетеп бара.

– Ә бит халык, иң элек, театрга җырчыны тыңларга дип килә.

– Әйе. Аннары, элекке заманнарда опера һәм балет театрына йөрү дәүләт җитәкчеләре өчен дәрәҗә санала иде. Хәзер исә безне уйлаучы да, чаң кагучы да юк. Ә бит бу катлаулы мәсьәләне югары даирәләр катнашыннан башка ерып чыгу мөмкин түгел. Әнә, Мәскәү телевидениесенең "Ирина Архипова представляет" исемле тапшыруында катнашкан классик тавышлы яшь җырчы Илдар Әбдрәҗәковка Башкортстан дәүләте, ярдәм итү йөзеннән, машина бүләк итеп биргән. Нәрсә, безнең моңа лаеклы җырчыларыбыз юкмыни? Классик җырчыларыбыз болай да бармак белән генә санарлык бит. Яхшы мөнәсәбәт турында әйткән дә юк инде. Безгә алмашка кем килер – билгесез.

– Ләкин Сез, милләтпәрвәр кеше буларак, тик ятмыйсыз. Әнә, чит илләрдән кайтып төшүегез булган, шундук Санкт-Петербургка концерт бирергә китеп баргансыз. Саф татарча менә дигән концерт биргәнсез.

– Казанга кайткач та, миңа "Нур" оешмасы җитәкчесе Мөхлисә ханым Зарипова шылтыратты. Ул, Санкт-Петербургта яшәүче татарларны бергә җыеп, төрле очрашулар, чаралар үткәрү белән шөгыльләнә, ана телебезне, милли моңыбызны саклау өчен җан атып йөри. Ул мине концерт куярга дәште. Баштарак үзем генә чыгып китәргә кыймасам да, соңрак күндем, тәвәккәлләдем. Гонорары турында сорап та тормадым. Без шулай тәрбияләнгән инде – тыңларга теләүче булса, рәнҗетмәсләр әле, дим.

– Ә шулай да, каян килә бу искитмәле зыялылык, итагатьлелек һәм сабырлык?

– Әниемнән. Аны авыл интеллигенциясе вәкиле диярга була. Педагогик белем алган. Партия бетерелгәнчегә кадәр парторг булып эшләде. Хәзер ялда.

– Концертыгызда нинди әсәрләр җырладыгыз соң?

– Иң әүвәл, концертымны "Гөлҗамал" белән ачып җибәрдем. Аннары халкыбызның яраткан моң ияләре С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, Р.Яхин, И.Шәмсетдинов, Ә.Бакиров, Ф.Әхмәт, Р.Еникеев, А.Монасыйпов әсәрләрен башкардым. Һәм, беләсезме, болай җылы кабул итәрләр дип башыма да китермәгән идем. Микрофонсыз җырлаганга бигрәк тә исләре китте.

Менә мин, күптән түгел, А.Аббасов һәм З.Хисмәтуллина язмаларын тагын бер кат сокланып һәм таң калып тыңлап чыктым. Аларда бит һәр сүз, һәр аваз ярылып ята! Элегрәк радиода да таләпчәнлек зур иде. И.Шәмсетдинов ул яктан таш кыя булды, сүзең аңлашылмаса, язуга якын да җибәрмәде. Ә бүген?!

– Шуңа күрә халык чын башкаручылар сәнгатенә сусаган да инде.

– Әйе, мин үзем дә шаккаттым. Санкт-Петербургта егермедән артык әсәр җырлаганмындыр, ә һаман да сәхнәдән җибәрмичә, кул чабалар. Чәчәкләрне алып чыгып киткәч тә әле байтак кына алкыш яуды. Җырлаттылар да җырлаттылар.

– Димәк, халкыбыз чын сәнгатьне аңлый, бәяли белә. Концертны үзегез алып бару тәэсир итми калмагандыр.

– Әйе шул, үзем алып бардым. Мин анда татар мәдәнияте, хосусан, Р.Еникеевнең күптән түгел гөрләп үткән юбилей кичәсе, яңа концерт залында һәр ел саен үткәрелә торган кичәләр, Р.Яхинны искә алу кичәләре турында сөйләдем; тел, латин графикасына күчү, җыр сәнгатенә кагылышлы күпсанлы сорауларга җавап бирдем. Дөрес, күңелне тырный торган сораулар да булгалады. Мәсәлән, берәү торып басты да: "Ә нигә татарга опера?" – диде. Мин түбәндәгечә җавап бирдем:

"Әйе, мин үзем дә, авыл кызы буларак, гармунны бик яратам. Әйе, опера Италиядә туган. Урыста да, ниместә дә, французда да элек опера булмаган. Әмма нигә соң әле без, Аурупага күрсәтерлек "Алтынчәч", "Шүрәле"ләребез булган мәдәниятле халык, опера сәнгатен, симфоник музыканы үстермәскә, бар дөньядан артта калырга тиеш?!" – дидем.

– Бик дөрес әйткәнсез. Димәк, Сез җырчы буларак кына түгел, ә бәлки халык илчесе, граждан буларак та үз вазифагызны намус белән үтәгәнсез. Әмма бу очракта Санкт-Петербурглылар бездән бәхетлерәк булып чыккан, чөнки әле сезнең Казанда мондый зур сольный концерт биргәнегез юк. Бәлки үзегезнең юбилей көннәрендә безне сөендерерсез?

– Әйе, июль аенда минем түгәрәк бәйрәмем була. Әле кичә генә җырларга өйрәнеп йөри идем кебек. Бактың исә, җырлыйм-җырлыйм дип, гомер үткән дә киткән. Ә юбилейга килгәндә, минем әле ул турыда ныклап уйлаганым юк иде. Уйлыйсы булыр, ахры. Көзгә табарак бер концерт-бенефис бирсәң шәп булыр иде. Әмма хөкүмәт ярдәменнән башка моны күтәрү мөмкин түгел. Аннары, ни дисәң дә, сәхнә яшьлекне, матурлыкны ярата. Без инде бүгенге заманның "модный" җырчылары түгел.

– Мин Сезнең белән бөтенләй үк килешеп бетмәс идем. Сездәге тавыш, Сездәге тәҗрибә яшьләрдә булсын иде әле.

– Шул тәҗрибәне түкми-чәчми тапшыру өчен тырышып йөрим үзем дә. 1997 елның көзеннән алып консерватория һәм музыка училищесында җыр (вокал) буенча дәресләр алып барам.

Мин үзем укытучым Валентина Андреевна Лазькодан бик уңдым. Аның шәкертләре З.Сөнгатуллина, В.Ганиева, С.Рәенбәкев исемнәрен атап китү генә дә җитәдер, мөгаен.

Үзең җырлаганга караганда башкаларны өйрәтү бермә-бер катлаулы булса да (алар җырлаганда бик нык дулкынланам, йөрәгем дөп-дөп тибә), укыта башлау белән иңнәремә канатлар үсеп чыктымыни, әйтерсең лә, икенче сулышым ачылгандай булды.

– Үз иҗатыгызны үстерүгә дә илһам бирәдер укыту эше?

– Тел очымнан өзеп алдыгыз. Композиторлар берлегенең күптән түгел үткән XXY пленумында яшь композитор Светлана Зорюкованың япон шигырьләренә иҗат ителгән өр-яңа вокаль циклы яңгырады. Ул миңа бик ошады. Шуны мартта узачак "Аурупа-Азия" фестивалендә җырларга әзерләнәм. Аннары симфоник оркестр белән язмалар эшләргә ният бар. Татарстан телевидениесендә фильм-концерт төшерәсем килә.

– Ә опера театрында хәл ничек тора?

– Анда француз телендә "Кармен"ны өйрәнәбез. Мин Мерседес партиясен җырлыйм. 5 февральдә исә Ф.Шаляпин фестивале башланып китә. Соңыннан... театр ремонтка ябыла.

– Шәхси тормышыгыз турында бер-ике сүз әйтеп китегез инде.

– Шәхси тормышымда бик зур шатлык булды. Кызым Айгөл (ул музыка училищесының өченче курсында укый) тормышка чыкты, матур гына туйлары булды.

– Алай булгач, тәбрик итәбез сезне! Киләчәктә тупырдап торган, сәламәт, милли җанлы, музыка яратучы оныклар үстерергә язсын!

– Амин! Шулай булсын.

Әңгәмәдәш – **Фирдәвес ӘҺЛИЯ.**

Наил **КУРАМШИН** фотосы.

Тамаша залы чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

30 гыйнвар – "Каениш, көндәш һәм башкалар" (Г.Камал).
31 гыйнвар – "Хуҗа Насретдин" (Н.Исәнбәт).
1 февраль (көндез) – "Кылый Кирам балдагы" (Аманулла).
1 февраль (кич) – "Хушыгыз" (Т.Миңнуллин).
2 февраль – Артист-шоу.
4, 5, 6 февраль – "Караул, талыйлар", премьера (Г.Камал).
7 февраль – "Мәхәббәт хатирәсе" (Ф.Бүләков).
8-15 февраль – Башкортстан театры гастрольләре.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

30 гыйнвар – "Гайфи бабай, өйлән давай!!!" (Г.Зәйнашева).
1 февраль (көндез) – "Мыгыр-мыгыр мыгырдык" (Ш.Фәхретдин).
1 февраль (кич) – "Сакла сөюне, таплама бер үк" (Х.Төхфәт).
2-7 февраль – Юморина. Студентлар өчен КВН.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

30 гыйнвар – "Белоснежка и семь гномов" (К.Хачатурян).
31 гыйнвар – "Белоснежка и семь гномов" (К.Хачатурян).
5 февральдән Ф.И.Шаляпин исемендәге фестиваль:
5 февраль – "Пиковая дама" (П.Чайковский).
6 февраль – "Царская невеста" (Р.Корсаков).

Цирк

30 гыйнвар-6 февраль – Зур Мәскәү циркы йолдызлары тамаша күрсәтә.

Курчак театры

30 гыйнвар – "Беда от нежного сердца" (В.Соллогуб).
31 гыйнвар – "Дюймовочка" (Х.Андерсен).
1 февраль – "Дюймовочка" (Х.Андерсен).
6 февраль – "Глаза змеи" (И.Зиннуров).
7 февраль – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).

Татар яшьләр театры

30 гыйнвар – "Тозакка төшкән аучы" (Н.Дәүли), Маяковский исемендәге мәдәният йорты.
31 гыйнвар – "Тозакка төшкән аучы" (Н.Дәүли), 126 нчы мәктәп.
3 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Невосельская), 59 нчы мәктәп.
4 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 50 нче мәктәп.
5 февраль – "Мисс убырлы" (Ф.Галиев), 194 нче балалар бакчасы.
5 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 103 нче мәктәп.
6 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 401 нче балалар бакчасы.
7 февраль – "Әй син, исәнме!" (Г.Мамлин), Осиново эшчеләр бистәсе.

Зур концерт залы

30 гыйнвар – Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Программада И.Брамс әсәрләре.
7 февраль – Вокаль музыка кичләре. Урыс романслары. Башкаралар – Р.Аббасов, Н.Варшавская, Г.Антонов, Л.Маслова, Г.Ибушев, С.Кадыйрова, Н.Сәгыйрова.


Ренат ГАФФАР

ҖЫЛАН

(Хикәя)

Урам якта машина гөрелтесе ишетүгә, Мөрдәнша карт ябык гәүдәсе белән тәрәзәгә капланды. Каршыда гына үсеп утырган сирин куаклары арасыннан каршы торган машинаның зур "күзләрен" шәйләп алды. Аннары, галошларын да киеп тормастан, оекчан гына тышка чыгып китте. Оныгы кайтасы иде, шулдыр, дип уйлады.

Эңгер төшеп килә иде. Өйалды баскычы да, ишек алды ташлары да рәтләп күренерлек түгел.

Кабалана-кабалана капкасын ачып, урамга чыкканда, машинадан ике кеше төшеп, бире таба килә иде. Алар нидер сөйләшә, көлеп-көлеп куялар.

Мөрдәншаның йөрәге кысылып алды.

– Сәйдәш олан ич! – дип, үзалдына пышылдап алгач, гадәте буенча, кул сырты белән чалбарын күтәреп куйды.

– Саумы, бабай! әллә танымыйсың инде?

– Синме, олан? – диде карт. – Кайттыңмы? – Аның тавышы калтырап китте. – Соңгы кат күренүеңә ни гомер, исеңә төшкән икән бер синең дә. Җир упкандыр дип торабыз тагын...

Келә шыкылдады. Капка да сөенгән – бөтен тирәне яңгыратып шыгырдады.

Мөрдәнша карт оныгының әле күптән түгел генә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, күрше республиканың бер совхозында баш инженер булып эшли башлавын ишеткән иде. Менә бүген, җае чыгып, бабасын күреп килергә тәвәккәлләде Сәйдәш. Башлыгы, урак өстенә әле байтак булганга күрә, каршы килмәде – бер-ике көнгә кайтып килергә рөхсәт бирде.

Карт иң әүвәл оныгына гына карап торганлыктан, аның янәшәсендәге кешегә бөтенләй илтифат итмәгән иде. Машина утында торган сап-сары чәчле, сипкел баскан егеткә борылып:

– Урыс икән... – дип, аның иңбашына кулын салды. – Атың кем була, улым?

– Данила... – Егет бөтен ишегалдын яңгыратып аваз салды.

– Эшләпәң кая? – дип сорады ул оныгыннан. – Киемең ник тузанлы? Башлык шулай буламыни?

Инженер булгач, гел ыспай киенгән, эшләпәле итеп күз алдына китерә иде ул оныгын. Машинасы да башлыклар йөри торган түгел икән. Менә шуңа кәефе кырылды, эченә җылан керде аның. Хәер, оныгының нәкъ менә шушындый машинада кайтуы әйбәт булды әле. Яз көне урманчы Галләм тау битенә каен утырттырган иде. Бераз утын бирермен, дигәч, Мөрдәнша да мәктәп балаларын өйрәтә-өйрәтә каен утыртып йөрде. Инде менә җәйләр җитте, арыш утыра башлады, утынның әле кайтканы юк. "Кипми кала", – дип эче пошты аның. Башта кителгән күңеленә хәзер инде сөенеч йөгерде. Машинасы да бит тавык куркытып, тузан туздырып йөргән ишеләрдән түгел инде – келәт хәтле "ЗИЛ"!..

"Җүн кылды болай булгач, Галләмнән генә яшереп, бер-ике бүрәнә дә салып булмасмы. Эшләпәсен эшләр беткәч киеп кайтыр. Бу юлга ярар инде...", – дип уйлады ул. Шулай да:

– Эшләпәсез килешми икән сиңа, олан. Нүжәли бер җүнәтеп булмады инде? Кеше ни уйлар? – диде.

Данила, кырт-кырт кыяр кимерүеннән туктап һәм дә сүзнең асылына төшенеп, хихылдап көлгәч кенә Мөрдәнша карт шым булды.

Тын авыл өстенә йолдызлар сибелгәндә ул җиңелчә генә исергән иде инде, оныгының инженер икәненә әле һаман ышанмыйча йокыга китте.

Мөрдәнша карт тавык кыткаклавына уянып китте.

– И-их, тирес гөләйләре! Күзләр генә җитсен! Шундый итеп кычкыртырмын әле, әйе. Тәки йокы бирмәделәр бит, ә! Арада бер кыңгыр кикриклесе, әшәке тавышлысы бар. Бүген үк суясы булыр, – дип уйлап ятты ул беркавым.

Ул, торып, болдырга керде дә, каплаган кунасын читкә шудырып, чиләккә чүмеч батырды.

Бары тик чәйне генә үз итүче картының бу галәмәтен күреп торган Мөнәвәрәсе түзмәде:

– Ниемә дип эчәсең инде шул салкын суны, җә! Ичмаса, күрми дә калганмын. Тукта дим, чәй кайный, – диде.

Карт, бөтен ишек алдына яңгыратып ыхылдап куйганнан соң, күңеленә иң хуш урынына – кузлага барып утырды.

Аның бүгенге уйлары оныгы хакында.

"Кара син аны, ә? Дөү кеше булган диген – инжинирт".

Оныгының нәкъ менә шундый зур башлык булуы аңа күңел хушлыгы бирә, сөендерә иде.

"Менә бит нинди итеп үстергәнмен, – дип уйлый ул бераз һаваланып.

– Кара, ник утырам соң әле җөелеп?"

– Мөнәвәрә! Уят, җитте. Ират өйлә җиткәндә йоклап ятмас, кайткач түнәрләр, – диде ул юынгычка җылы су салып торган карчыгына.

– Бераз ял итсеннәр, өшәнгәннәр ич. Нишләмәкче буласың?

– Уят, бетте! Сорама. Эш бар.

Мөрдәнша үе белән генә капка төбендәге теге иләмсез машинада тузан туздырып, Чишмә чокырыннан печән кайтарып ташлады. Аннары урманга китте. Анда утыннан тыш тагын бер йомышы бар иде аның...

Менә инде ничә еллар ак мунча җиткезеп куярга исәпләп йөри ул. Шул исәбен һич кенә дә тормышка ашыра алмый. Уң як күршесе Садрыйныкы нинди бит әнә. Дөнья рәхәте! Өй каршына сузып салынган бүрәнәдә тәмәке тарта-тарта дөнья хәлен сөйләшеп утырганда, Садрыйның:

– Әйдә, гадук, чабынып чык бер. Сөякләрең җиңеләеп китәр. Килен тагын ягып җибәрде бугай, ахрысы, – дип әйтә торган гадәте бар.

Ул шулай диюгә, Мөрдәншаның борынына мәтрүшкә аралаштырып бәйләнгән каен себеркәсе исе килеп китә.

Үз мунчасы тәмам искерде. Кем әйтер Мөрдәнша балта остасы булган дип? Ягарлык түгел инде. Караучысы булмагач, бакаларга хәтле ташлап киткән.

Башта күршесенең кыргый чиялеккә ак мунча салып куюына әллә ни исе китмәгән иде дә Мөрдәншаның, тора-бара эченә корт, җылан керде, ике күрше арасын мәче кисте.

Тора-бара ике күрше бергә чабыну түгел, бүрәнәгә утырып тәмәке дә тартмас булды.

Исенә төшкән саен Мөрдәнша ант эчә: "Салам, Садрый! Салам булгач, салам!!!"

Карт бер керешсә, җиткезәсе дә куясы, юкса. Әнә бит ярты авыл йорты аның балтасыннан үткән. Соңгы араларда бу шөгылен ташлады-ташлавын. Вәләкин, йөзе җыерчыклана барган саен, Мөрдәншаның җаны котыра гына барды. Бүрәнәләрен генә кайдан юнәтәсең менә...

Сәйдәш олан бабасының теләгенә каршы килмәде.

Ничә еллар аягы басмаган тугайларда дөньясын онытып торып, чалгы селтәвең ни тора!

Авыл малаена җаен гына бир.

Туктаусыз печән чабудан соң, пакуска яткан килеш, болынны тыңлап ятканда әллә ниләр искә төшеп бетте.

Печәнне алып кайтып аударгач, урманга чыгып киттеләр. Кич җиткән иде инде. Сыек кына булып томан төшә башлаган иде. Тигезле-тигезсез урман юлы белән бара торгач, Мөрдәнша туктарга кушты.

Аның уенча, нәкъ менә шушы төштә мунчага ярарлык менә дигән каеннар булырга тиеш иде.

"Утыны качмас, Галләм югында тәвәккәлләргә кирәк..." Бактың исә бөтенләй башка төшкә килеп чыкканнар икән.

Мөрдәнша яшьләрне юл карарга җибәреп, үзе машина янында калды.

Аның баскычына утырган килеш тәмәкесен кабызгач, уйга чумды: "Таушалган көе ник нужаланып йөрим әле? Печәнле иттеләр. Киссеннәр, тәясеннәр соң. Сөбханалла, тазалар. Ә мин черем итеп алырмын..."

Урман тын.

Күпме шулай утыргандыр, тынналары беткән егетләр чаптырып килеп җитте. Карт "дерт" итеп куйды.

– Нәстә булды?

– Анда кеше сөйләшә!

– Ык итмәгәе мык итсен миңа димәгәе. Ә бит уйлаганыем аны каравылчы Галләм йокламый ул дип. Миңа терәлгәч, шулай ул... җә, өйдәгез, балалар, вакыт уза, аттырыйк моннан кеше-кара күргәнче.

Әйтүен әйтте, тик үзе ашыкмады. Каршында үсеп утырган имән агачына текәлеп катты да калды.

– Яраттың, ахры, бабай, имәнне. Күзеңне ала алмас булдың, – диде Данила.

– Балалар, әллә, мин әйтәм, арыбире китерикме шушыны, ә? Нигез буена бата бу. Эзләп йөрисе юк. Нәкъ менә шушыңа иш ике бүрәнәсе ишек алдында ята бит. Черемсери дә башлаганнардыр инде.

"Ну, Садрый, җан җаһиләңне..."

Ниндидер сихер кабинага меңеп барган Сәйдәшне җиргә тартып төшерде. Ул бабасы янына килеп басты.

– Тукта! Кисмик бу имәнне.

Карт әле оныгына, әле машина яктырткан имәнгә карап алды.

– Чү, ник тагын?

– Таныш имән, – диде Сәйдәш.

Әле күптән түгел шушы төштә ике имән үсеп утыра иде, булса биш ел булыр. Инде берсе генә калган. Икенчесе урынында өсте күгелҗемләнгән юан төп. Кырмыска оясына күмелеп кала язган.

Төпнең ян-ягыннан берничә яшь үсенте калкып чыккан, пеләш башта коелмый калган чәч бөртекләрен хәтерләтә.

– Тукта әле, монда кыргый груша булырга тиеш иде бит, – дип исенә төшерде Сәйдәш. – Шушы тирәдә генә иде бугай...

Шунда гына булган икән, кармалана-кармалана бер җимеш өзеп, авызына капты. Груша суыннан яңаклары өчетеп куйды. Егет, сузылып, төпнең шома өслегеннән сыйпап алды. "Салкын..."

Ялгыш сындырудан курыкса да, үсентеләрне тотып-тотып карады.

Уйга калды:

"Кышкы салкыннарда ничекләр түзәсез икән? Беренче кырау алырмы, әллә берәр ач куян кимереп китәрме?

Ел саен шулай булыр: кышын кимерерләр, язын тагын тернәкләнерсез.

Әүвәлге имәнне алмаштыра алырсызмы икән?

Үзенә күрә көрәш..."

– Син бит бу, Динә! – дип пышылдады Сәйдәш көтмәгәндә. – Бу – синең бүгенең...

Җәйләрен җиләккә, көзен чикләвеккә йөргәндә алар гел шушы имәннәр турысына җиткәч ял итә иделәр. Соңгы мәртәбә мәктәптә чыгарылыш беткәч килделәр.

Якында гына өлгереп килгән арыш кыштырдый, бытбылдык оскырта.

Урмандагы кош авазы йокыны китерә. Рәхәт...

– Ай!

Ачыргаланып чыккан аваздан урман сискәнде. Бытбылдык тынды.

– А-а-ай! – дип җавап бирде урман.

Сәйдәшнең коты алынды. Җыланны әле күргәнгә һәм Динәнең каты кычкыруыннан ул бөгәрләнеп килде.

– Ни булды, Динә?

Абага арасына сызгыра-сызгыра кереп киткән җыланны күргәч, Динә шуннан куркып кычкырган, дип уйлаган иде дә, кыз балтырында кызарып-агарып калган урынны күреп алды...

– Сыдырылган гына ул, Динә, – дип юаткан булды.

Әмма аның тәмам хәле китеп, ак алъяпкычына кадәр калтырый башлагач, оялуын җиңеп, җәрәхәттәге канны суыра башлады. Аннары юка каерысы белән жгут салып куйды.

"Нишләргә? Авылга хәтле дүрт чакрым. Өлгермим. Олы юлга чыгарга кирәк. Анда район үзәгенә баручы машиналар очрар әле".

Ул, Динәне күтәреп, олы юлга таба китте...

Шуннан бирле аерылышмас күк иделәр. Тик көнең син дигәнчә генә бармый икән...

Динә бүтәннеке булды. Инде аерылган да икән...

Бүген иртән Динәсе турыннан узышлый, бабасы Динәнеке дигәч, нәни бер кызны туктатып: "Кем кызы син?". – дип сораган иде. Бала:

"Әнинеке", – диде. Әнә бит, әтинеке түгел, әнинеке. Динәнеке.

Менә хәзер уйлары бөтенләй икенче якка борылды да куйды.

"Ни генә булмасын, Динәнең сер белән тулы күзләре, ягымлы тавышы, көлүе бар. Иреннәре дә шул уктыр... Көтәдер, көтми калмас. Авылга кайтып төшүемне күргәндер, ирештергәннәрдер".

Бу грушалы, җыланлы төшнең изге икәнен, исән калган бердәнбер имәнне ник кисәргә ярамаганын аңлатып кара син Мөрдәнша бабаңа!..

– Ник кисмибез, дим, әннән киткән? Урамдагы бөтен мәткә таныштыр сиңа, урмандагы агач – икеле әле... Җан җаһиләңне! Рас мин кушам, аудар, майт җакасын!

Мөрдәнша картның ут яктысында карават тимере күк ябык зәңгәрсу-кара булып күренгән тамырлы куллары калтырый иде.

– У-у-ух, әнсез! Инжинирт кавеме...

Картның йөрәген авырттырып, нидер чеметеп алды. Димәк, оныгы аның теләгенә каршы? Бабасына яңа мунча салышу уенда түгел!

Карт эшнең ахыры хәерле бетәсенә өмете өзелеп, өйгә бернисез кайтып керәсе итте.

"Күрсен авыл кемне үстергәнемне!"

Мөрдәнша картның өч көн инде беркая чыкканы юк. Галләм биргән рөхсәт кәгазе тагын матчага кыстырылды. Оныгы китеп баргач, тәмам боегып калды, чәе үтмәс, сүзе чыкмас булды. Аны иң курыкканы бүтән нәрсә – урмандагы хәлләрне Садрый ишетеп алгандыр да, йөридер мыек астыннан гына көлеп...

Көннәр шулай уза торды.

Инде тышта сентябрь ахыры. Тупыллардан яфрак коела. Бөрәңгесен алып бетергән бер иртәдә Мөрдәнша карт, гадәтенчә, кузлага тәмәке тартырга утырды.

Янынннан гына, горур кыяфәт белән, әтәч үтеп китте.

– Племенной! – диде ул мыгырданып һәм лач итеп читкә төкереп куйды.

Тавык халкы, бодай чүплəгән җирдән, шиккә калып, башын күтәрде.

Иске капка түбәсендә моңланып кына мәче мияулап алгач, түзмәде, "Садрыйныкы! Көлә!" – дип, галошын салды да капкага бәрде.

Ачулы иде карт...

Шулчак капка келәсе шыкылдап куйды. Шуны гына көткән, ахрысы, болдыр астыннан имгәк кенә бер көчек тәгәрәп чыкты.

– Кем бар? – дип кычкырды Мөрдәнша, капкага борылмый гына.

Хат ташучы Банат иде бу.

– Почта, Мөрдәнша абзый. Хат бар.

– Суң.

Хат Сәйдәштән булып чыкты.

– Анасы, чык әле!

Җавап бирүче булмагач, үзе укырга керештә. Хатның һәр сүзен, һәр юлын укыган саен йөзе ачыла барды.

– Кайтып китәм әле, дисең инде, алайса, ә? Кайтырсың шул – бабаң ич мин! Ярый, шулай булсын... Агач төяп кайтам бу юлы, урман хуҗалыгыннан сатып алдым, дисең алайса. Шәп, улым! Шәп!..

"Мунча була инде болай булгач, ә? Ну, Садрый, җан җаһиләңне чиртәм бит..."

Тик менә кайткач өйләнәм дигән юллары башта пошаманга салдысалуын. Шулай булса да, ул чиксез шат иде.

Болдыр баскычыннан, кулын итәгенә сөртә-сөртә, Мөнәвәрә түти төшеп килә иде.

– Чәй куй. Дәшерсең кайнагач. Садрый кордашларда булырмын. Тәмәке тартып алыйк әле бер. Сагынылган...

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГӘЗИТЕНЕҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ N1 (53)

Яңа елда сүздән – эшкә

* * *

(өзек)

Үткәннәрдән
нинди гыйбрәт алдык,
Ни үзгәрде
бүгенге көн Илдә?..
Төшәр күлен җуйган
Аккош сыман,
"Демократия" сүзе бөтерелә
Баш очында. Ә күл,
бәлки, корыган?!
"Демократия" сүзе Ил өстендә
Бөтерелә ялгыз Аккош сыман...

Ямаш ИГӘНӘЙ.

Борынгылар сүзен тыңламасаң, борының белән капланырсың

Барганда сөйләмә, кайтканда сөйләрсең

Сәхифәбездә:

- *Туган телне – гамәлгә! Чаллыда үрнәк эшләр. Никах теркәүчеләр киңәшә. Атама бирү – җаваплы эш.*
- *Г.Исхакыйның тууына 120 ел. Мирасыннан тагын бер үрнәк.*
- *Эш кәгазьләрен яза беләбезме? Ярдәмлектән рәхим итегез!*
- *Яңа "реплик": сүз рәссамнарына кытлык китте.*
- *Этимологик табышлар.*
- *Яңа журналга хәерле юл!*

Телләрне гамәлгә ашыру комитетында

Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы "Татарстан халыклары телләре турында"гы законны гамәлгә ашыру комитеты узган ел шактый актив эшләде, төрле чаралар үткәрде. Елның соңгы айларында башкарган кайбер чаралары турында гына булса да яңа мәгълүмат, хәбәрләр җиткерәбез.

Хәзерге милли яңарыш чорында республикабыздагы милли телләрнең үсеше "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру шартларында бара. Бу өлкәдә берникадәр алга китеш, уңай нәтиҗәләр дә күзгә чалына. Әмма эшләнәсе эшләр, бурычлар әле шактый күп күренә.

Киң җәмәгатьчелекне аерым алганда географик атамаларның (урам, мәйдан, шәһәр исемнәренең) тарихи-мәдәни хәлебезне дөрес чагылдыру дәрәҗәсе, дәүләт телләрендә дөрес әйтелеше, язылышы борчый. Бу турыда сөйләшү дә күптән бара. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комитетының топонимия комиссиясе дә (рәисе тарих институты фәнни хезмәткәре Р.Хәйретдинов) бу юнәлештә эшен җанландыра бара. Әйтик, 4 декабрьдә Татарстан Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында топонимия комиссиясе әгъзаларының галимнәр, матбугат хезмәткәрләре, Министрлар Кабинеты әһелләре белән берлектәге киңәшмәсе булып узды.

Фикер алышуда Казан дәүләт университеты профессоры Г.Саттаров, мәгариф идарәсе башлыгы И.Гарәфетдинов, республика прокуроры урынбасары К.Әмиров, энциклопедия институты директоры урынбасары Г.Сабирҗанов һәм башкалар катнашты.

Нигездә сүз яңа топонимик атамаларны гамәлгә кертү, искеләрен яңарту, туган тел таләпләренә туры китереп әйтү, язу хакында барды.

Чыгып сөйләүчеләр, тулаем алганда, топонимик атамаларны тәрҗемә итмәскә, алар дәүләт телләрендә дөрес язылырга, әйтелергә тиеш, дигән фикердә иде. Шул ук вакытта бүтән төрле, бәхәсле фикерләр дә булды. Аерым алганда, Ф.Ганиев, Г.Сабирҗановлар кайбер очракларда урыстан татарчага тәрҗемә итү дә кирәк, дигән тәкъдим әйттеләр. Чынлап та, нигә татарча да, урысча да "Зеленая улица", нигә "Школьный переулок" кебек атамаларны ике телдә дә йөртмәскә?!

Фикерләрне гомумиләштереп түбәндәге фикерләрне ассызыклап әйтергә кирәк дип саныйбыз:

1. Атамалар һәр ике телдә аларның фонетик, лексик-семантик системасына туры килеп торырга тиеш.
2. Яңа атамалар тарихи-мәдәни, фәнни нигезләмәләргә таянырга тиеш.
3. Элек дөрес кушылмаган урам исемнәрен тарихи дөреслек нигезендә үзгәртә барырга кирәк (Тукай мәйданы, Кремль урамы һ.б.).
4. Кайбер очракта атамаларны тәрҗемә итәргә дә була (Чүпрәле районы – Дрожжановский район, Проспект победы – Җиңү проспекты һ.б.) Монда атаманың нинди милли җирлектә торуын истә тоту белән бергә, аның ана телендә дөрес итеп, шушы тел кагыйдәләренә туры китереп әйтелүе зарур.
5. Урыс теле җирлегендә туган атамаларны тәрҗемә итү мөмкинлеген, аның туган телне саклау, баету чарасы икәнен дә онытмаска кирәк.

Кыскасы, атамаларны кушканда алар белән бик сак эш итәргә кирәк, алар тарихи-мәдәни, фәнни, рухи нигезләмәләргә туры килергә тиеш.

Милли хасият көчәя барсын

М.ХӘЙРУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты.

Никахны – үзебезчә

Казанның Никах сараенда башкала районнарының һәм шушы тирә шәһәр, районнарның гражданлык актларын теркәү (загс) хезмәткәрләренең һәм шушы эшчәнлеккә караган галимнәрнең киңәшмәсе булды. Анда бу өлкәдә Татарстан халыклары телләре турындагы законны үтәү барышы мәсьәләләре каралды һәм алда торган эш, бурычлар турында уртага салып сөйләшенде.

Никахны, бала тууны тантаналы теркәү процессларын һәм башка рәсми йолаларны ана телендә тәэсирле үткәрү алымнары турында белгечләр, гамәли хезмәткәрләр тәҗрибә уртаклашты, фикер алышты; чыгышларда шулай ук рәсми документларның татарча үрнәкләрен булдыру, кеше исемнәре сүзлекләрен камилләштерү кирәклеге искәртелде.

Киңәшмә-семинарны комитетның гыйльми сәркатибе Ким Миңнуллин алып барды һәм чыгыш ясады.

Үрнәк булырлык шәһәр

Комитетның 23 декабрьдәге утырышында берничә мәсьәлә каралды. Аерым алганда, Телләр турындагы законны гамәлгә ашыру эшләре хакында Чаллы шәһәре хакимиятенең хисабы зур кызыксыну белән тыңланды (докладчы – хакимият башлыгы урынбасары Фәйрүзә Мостафина). Шәһәр оешмаларында бу юнәлештә игътибарга алырлык эш башкарыла һәм аның нәтиҗәсе дә күренә. Аерым алганда, милли мәгариф, ике теллелекне гамәлгә ашыру мәсьәләләре шәһәр Советы сессияләрендә, аның даими комиссияләре утырышларында еш тикшерелә. Соңгы ике елда гына да бу юнәлештә мэрның унике махсус карары чыккан.

1990/1991 уку елыннан соң татар мәктәпләренең саны бердән унбишкә үскән, татар-урыс мәктәпләре саны утыз җидегә җиткән, татарча укый торган класс-төркемнәрнең саны 64тән 475кә арткан. Хәзер барлык баланың 48 проценты ана телендә белем ала. 1990/1991 уку елында нибары 4,8 процент иде.

Биредә татар музыка мәктәбе ачылган, бер һөнәри-техник училище татарча укытуга үзгәртелгән, күбесендә татарча төркемнәр оештырылган. Гомумән, хәзер шәһәрдә татар балаларының 99,6, урыс телле балаларның да 99 проценты татар телен өйрәнә.

Чаллыда өзлексез педагогик белем бирү институты оештырылды, анда татар филологиясе факультеты булдырылды. Оешма, предприятиеләрдә татар теленә өйрәтү курслары эшли; ике телдә эшләүчеләргә, аттестация үткәннән соң, хезмәт хакына 15 процент өстәмә түләнә; мэрия аппаратында эш кәгазьләре һәм эш йөртү ике телдә алып барыла; төрле телләргә өйрәтә торган 12 якшәмбе мәктәбе эшли.

Комитет утырышында чаллыларның игътибарга алынырлык тагын да күп кенә яңалыклары билгеләп үтелде, утырыш карарында аларны уңай тәҗрибә итеп билгеләп, башка хакимиятләргә дә җиткерергә дип билгеләнде. Шуны истә тотып, "И туган тел..."нең алдагы саннарының берсендә без аларга тәфсилләбрәк тукталырбыз.

Яңалык! Яңалык!

Җиңүчеләрне котлыйбыз

Татарстан Мәгариф министрлыгы "Татар гимназиясе-97" конкурсына йомгак ясады. Конкурс республиканың яңа төр татар уку йортларының үсешенә, укытучыларының һөнәри осталык дәрәҗәсе күтәрелүенә, укучыларга шәхес буларак формалашу өчен шартлар тудыруга, уку йортының матди-техник базасын ныгытуга юнәлтелгән иде. Анда катнашу хокукы татар гимназияләренә, мәктәп-гимназияләргә, татар-урыс һәм урыс-татар гимназияләренә, татар лицейлары, мәктәп-лицейларга, татар-урыс һәм урыс-татар лицейлары, мәктәп лицейларына бирелгән иде.

Күптән түгел конкурс-тикшерү комиссиясе ярышка йомгак ясады. Казан, Чаллы шәһәрләре уку йортлары арасындагы ярышта I урынга Казанның икенче татар, II урынга Казанның бишенче гимназиясе, III урынга Чаллыдан илле җиденче гимназия лаек булды.

Республика шәһәрләренең уку йортлары арасындагы ярышта I урын Әлмәт, II урын Түбән Каманың икенче, III урын Лениногорски гимназияләренә бирелде.

Республиканың авыл, район уку йортлары ярышында I урынга Кукмара, II урынга Саба, III урынга Аксубай гимназияләре чыкты.

Конкурста җиңүчеләргә I, II, III дәрәҗәле Диплом һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Котлыйбыз!

Сүздән — сурәт

Быелгы тел, әдәбият олимпиадаларына да әзерлек бара. Сораулар әзерләнә. Миннән дә тәкъдимнәр үтенделәр. Кабатлый киләм, телне гамәли куллану, сөйләм оештыруга кагылган сораулар, күнегүләр күбрәк булырга тиеш. Быел бәлки "Сүз белән сурәт ясап күрсәтегез", дигән сорау да кертергәдер? Уйлашыйк әле, хөрмәтле укытучылар, методистлар!

... Фикереңне кемгәдер җиткерергә алынганда,– син аны телдән әйтәсеңме, әллә язмача белдерергә ниятләдеңме,– иң тәэсирле сүзне табарга тырышасың. Иң тәэсирле сүз ул – син уйлаган төшенчәне төп-төгәл итеп, күз алдына китерерлек итеп белдерә торганы. Ә күз алдына китерү өчен ул төшенчә сурәт рәвешендә булса, үтемлерәк. Чөнки аның бүтән төшенчәләрдән аерылып тора торган сыйфат, үзенчәлекләре җитәрәк күренәчәк.

Моның өчен, әлбәттә, рәссам буявы, кыл-каләм кирәк. Ә гадәти сөйләмдә сурәтне сүз белән ясарга туры килә инде. Әйе, әйе, сурәтне сүз белән дә ясап була. Телебез шундый могҗизага да ия. Моңа яраклы чаралары да бихисап аның. Моны күпчелегебез тоемлый, тоемлап кына калмый, җае чыкканда файдаланырга да омтыла. Аеруча шагыйрь, язучы, журналистлар. Җор телле әби-бабайлар да моңа хирыс. "Сүздән сурәт ясау" дигән күренеш фәндә дә танылган; аерым алганда, матур әдәбиятның образ тудыру сәләте асылда телнең нәкъ менә шушы могҗизасына таяна да.

Сүз белән сурәт ясау сәләте язучыларга хас, аны куллану алардан гына таләп ителә, дигән фикер дөрес түгел. Фикерне, төшенчәне ап-ачык, үтемле, тәэсирле итеп, тиз белдерү һәркайсыбызга кирәк ләбаса. Ә телебез исә шушы максатка тулысынча туры килерлек. Куллана гына бел. Ата-баба аны гасырлар буе шулай иҗади куллана-куллана баеткан да инде. Әкиятләрне, бәетҗырларны шундый тасвир, сурәт чаралары аша гомерлек хәтергә салганбыз да. "Камыр батыр ишекне ачса, күрә: ишекнең төбендә **үзе бер карыш, сакалы биш карыш** бер карт басып тора...";

"Анда җырлый җирдә һәр таш,
Кул изи һәрбер агач.
Анда кайтсам мин дә башка,
Анда **мин дә сандугач".**

Бик тә кызганыч ки, телебезең куллану өлкәләре, даирәләре тәмам кысрыкланганга, бүген аның менә шушы могҗизалы сурәти чаралары да сөйләмдә азайды, коргаксыды. Мондый кәсәфәтнең сәбәбе дә әлләни яшерен түгел: урысчадан тәрҗемә итеп фикерләргә күнеккән буыннарның сөйләмен дә чит тел калька-калыплары иң башта нәкъ менә ана теленең шушы үзенчәлекле йомшак мамыкларын, тәэсирле бизәк, буяуларын тоныклый, тибәрә дә инде.

Вакыт-вакыт иң тәэсирле, иң сурәтле сүзне, гыйбарәне таба алмыйча, һавасыз интеккән балык кебек, әлсерәп утырганда, кинәт авылга кайтасы килә башлый. Шунда гына табарсың кебек. Хәер, язучылар ул саф сулы мул чишмәне элек-электән белгән. Гомәр ага Бәшировның ни дигәнен хәтерлисездер әле: "Халык үзенең әйләнә-тирәсендәге һәр нәрсәне, һәр күренешне, үзенең хезмәтен, тормышын шигъри исемнәр, хәтердә калырдай җанлы образлар белән бизәгән. Ул табигатьнең һәр күренешен поэтик күтәренкелектә күрергә омтылган. Чишмә ага дип әйтү белән генә канәгатьләнмәгән, аныңча **чишмә чылтырап ага.** Таң ата гына түгел, **сызылып таңнар ата, кошлар чут-чут сайрый, сулар борыла-борыла ага..."**

Андый җанга сары май булып ята торган тасвири үрнәкләрне минем "Авылым дәфтәре"ннән дә аз булса да табарга була. Менә: "Күрше малай, әтисенә ияреп, урманга барып кайткан. Гөмбә җыйганнар. "Күпме?", дим. "Дөнья!", ди малай. Өстәвенә әле бөтен Җир шары чаклы өелеп тора дигән сыман кулларын да җәеп җибәрә".

Ә без булсак, "күп", бик күп" дияр идек, укымышлыракларыбыз "бихисап" дип тә җибәрер иде. Шулай да болар барысы да күршем ясаган сурәттән нык кайтыш булыр иде.

Авылда да хәзер куен дәфтәренә теркәп куярдай мондый табышлар яр буенда тәгәрәп яткан соры ташлар арасында мәңгә бер елтырап куйган гәрәбә бөртеге кебек кенә очрый. Быел җәй бер авылдаш хатын унберенчене тәмамларга торган кызы белән киңәшкә кереп чыкты. "Дүрт-бишкә генә укыды, педуниверситетка керергә ниятли, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буласы килә, нинди рәк киңәш бирерсең икән..."

Андый чакта ни әйтергә дә белмисең. Яраткан бер темасына инша-сочинение язып карарга киңәш бирдем. Берничә көннән – әзер. Темасы: авыл табигате һәм аңа яшьләрнең мөнәсәбәте. Кызык кына тема. Мисал, фактлар бар. Язылышы да шома гына: җөмләләр төзек, гәзит, радио куллана торган, димәк, барыбыз да куллана торган, бер-берсенә охшаш, шомарып беткән, туры мәгънәле сүзләр. Хет бер генә күчерелмә мәгънәле, образлы, сурәтле бәрәмлек (эпитет, фразеологизм, метафора, гипербола, әйтем, мәкаль һ.б.) булсачы! Кайда канатлы, җор, хикмәтле гыйбарәләр! Бар да бер төсле стандарт кирпечләрдән өелгән төссез, соры стена инде...

Борчылып, уйланып утырдым: авыл баласының сөйләме авыл өенең нарат ниргәләренә төшерелгән чәер сурәтләре кебек җылы, серле, хикмәтле, төрледән-төрле булырга тиеш иде ләбаса. Кызыбыз төзүче, инженер, хисапчы булырга җыенса, бер хәл иде, ул бит татар теле һәм әдәбияты укытучысы булырга хыяллана. Образлы, тасвирлы фикерләү аның канында булырга тиеш. Үзендә булмаганны ул бүтәннәргә ничек өйрәтсен...

Әйе, сурәтләү фикерләү сәләте тумыштан була, ул нәселдән килә. Моның күнегүләре гаиләдән башланырга тиеш. Мәктәптә инде балаларның барысында да бу сәләт фәнни нигездә үстерелергә, күнегүләр аша беркетелергә тиеш.

Тиеш тә бит, беркетеләме икән соң? Кызганыч ки: бүген моңа, тулаем алганда, уңай җавап биреп булмыйдыр. Нигәме? Әйдәгез мәктәп программасына гына күз салыйк. Әйе, программа татар телен укытуның иң төп бурычлары арасында ("ана телен дөрес һәм йөгерек куллану күнекмәләре бирү, укучыларның тулы грамоталылыгына ирешү, әйтмә һәм язма тел культурасын күтәрү, башка фәннәрне дә ана телендә үзләштерү, гомумән, татар теле фәне нигезендә эзлекле белем бирү һ.б") сурәтле фикерләргә өйрәтү бурычын аерып күрсәтми. Хәер, акыллы укытучы "ана теленә мәхәббәт тәрбияләү..." бурычын балада телнең иң нечкә, иң тәэсирле хәзинәсен тою, кулланырга омтылу теләген тәрбияләми торып үтәп булмасын болай да аңлар дип уйлаганнардыр. Аңларлармы икән соң?!

Ярый әле методист галимнәр бу төп нигезләмәне программаның азагында ачыграк искәртеп куюны кирәк тапканнар. Укучыларның язма эшләренә нинди таләпләр куела дигәндә, "укучының тел байлыгы, сөйләменең төгәл һәм образлы булуы", "язуның образлылыгы исә үзенә сүз һәм фразеологик әйтелмәләрне, сурәтләү чараларын (эпитет, чагыштыру, сынландыру, гипербола кебекләр) куллануны, һәр ситуациянең үзенә генә хас сөйләм төрен һәм стилен саклап язуны ала" кебек таләпләр истә тотыла.

Күренә ки, телгә өйрәтүнең максаты, бурычлары да, өйрәтүнең нәтиҗәләренә бәя бирү таләпләре дә асылда дөрес билгеләнгән. Әмма программада моңа ирешүнең фәнни, методик нигезле системасы тәгаенләнмәгән, димәк ки, аның үтәлүе дә каралмаган. Мәсәлән, фразеологизмнарны өйрәнүгә сәгать бирелгән, ә башка күчерелмә мәгънәле бәрәмлекләргә (хәтта әлеге өземтәдә саналганнарына да) – юк, алар программада атап телгә дә алынмаган. Дәреслекләрдә дә шундый ук хәл.

Шул хакта сүз чыкса, методистлар да, укытучылар да: "образ тудыру, сурәт ясау – әдәбият эше, шунда өйрәнелә", дип котылмакчы була. Әйе, әдәбият фәне үзе дә, укучылар танышырга тиешле матур әдәбият әсәрләре дә бу юнәлештә берникадәр мәгълүмат бирә; тәҗрибәле укытучылар да бу мөмкинлектән берникадәр файдалана, күнегүләр бирә ала. Бирәләр дә. Габдулла Тукайдан **"сорыкортлар", "өй түрендә җил елый", "кәфер почмагы"** һ.б. хәтердә кала бит.

Укытучы үз алдына шундый максатны куйган булса, хәтердә кала. Куймавы да ихтимал, чөнки программа, шундый максатны тулаем куйса да, аңа ирешү системасын монда да булдырмаган. Һәр темада, һәр язучыда, һәр әсәрдә ул бурыч эзлекле куелмый. Очраклылык хөкем сөрә. Образ тудыру, сурәтле фикерләүгә ирешүнең әдәбисәнгати чаралары үзенә, тел чаралары үзенә мөстәкыйль өйрәнелми, күнегүләрне эзлекле үтү күздә тотылмый.

Гомумән дә, бу бурычны әдәбиятка гына кайтарып калдыруның зарардан башка бернинди файдасы юк; матур әдәбият образ белән фикерләргә өйрәтергә тиеш, тормышта бит моңа сәләтле кешеләр күп түгел, ихтыяҗ да чамалы, язучы будырдай укучылар бармак белән генә санарлык була. Ә телне барыбыз да белергә тиеш, шул җөмләдән аның сурәтләү чараларын да. Адәм баласы бит көндәлек фикерләүдә дә, иҗтимагый-публицистик, эпистоляр (хат язу) фикерләүдә дә, хәтта фәнни һәм рәсми фикерләүдә дә телнең сурәтләү, тасвирлау чараларын элек-электән куллана килгән. Телнең бу мөмкинлеген бүген тагын да активлаштырырга, үстерергә кирәк.

Мондый махсус эшкә әдәбият фәненең генә көче җитәме? Хәер, әйткәнебезчә, моннан әдәбиятка зарар гына, әдәбиятның үз эше дә җитәрлек.

Сөйләмне җанландыру, сынландыру, төрләндерү бурычын үтәүдә матбугаттан, радио, телевидениедән дә җаваплылык төшерелмәгән. Әмма бүген алар да мактана алмыйдыр. Район гәзитләренә күз саласың, радио, телевидениедә җитәкчеләрнең, хәтта зыялыларның, депутатларның, укытучыларның сөйләвенә колак саласың, әйткәннәре аңлашыла да кебек үзе, тик сөйләмдә җылы, мөлаемлек, бизәк юк диярлек. Сөйләм, әлеге дә баягы, кирпечтән, тимер-бетон блоклардан корылган. Сурәт кайда, тасвир кайда?

Кайбер гәзит-журналларыбызда, кайбер язучы, журналистларыбызның язмаларында ара-тирә очрап куйган бизәкләр энҗе бөртекләре кебек карашны ачып, күңелне җилкендереп җибәрә бит: "Сабый бәләкәйдән үк **моң бишегендә** тәрбияләнеп үскән", "Андыйларны **станокка бәйләп куйсаң да** эшләмәячәк", "Ул акчаны да әле инфляция дигән **корт кимерә"**...

Кагыйдә буларак, сурәт ясарлык тел бизәкләре әле олылар сөйләмендә, аеруча авылда гомер кичергәннәр сөйләмендә күбрәк очрый. Шундый үрнәкләр килеп кердеме, язмаларыбыз җанланып, җылынып, нурланып китә: "Безнең балалар **ындыр табагында, эскерт асларында үсте"**, "Төпи йөреп киткән бере **кул арасына кереп барды"**, "Инде килеп, **дүрт арыш арасында бер бодай** дигәндәй", **"Юктан башкасы юк чаклар"**, **"Болыт кадәре** өе бар, **өрмәгән җиргә утыртмый** торган балалары...", "Гомеренең **сары көзләренә** аяк баскан..." һ.б.

Тулаем алганда исә, көндәлек матбугатта күчерелмә мәгънәле, сурәтле бәрәмлекләр, гыйбарәләр ара-тирә очраса да, күпчелегендә алар йә беләүләнеп беткән үзебезнең калыплар ("көнне төнгә ялгап", "кара алтын", "җиң сызганып" һ.б.), йә урысча тәрҗемәдән калькалар ("кайнар эзләр буенча", "юмарт абзый", "гаилә учагы", "кычкырып торган саннар" һ.б.).

Безгә инде татар теленең күчерелмә мәгънәле, канатлы бәрәмлекләре сүзлеген чыгарырга да вакыт җиткәндер. Шул ук вакытта булганнарының, беренче чиратта, Нәкый Исәнбәтнең фразеологизм, мәкаль сүзлек-җыентыкларын һәр мәктәптә, һәр китапханәдә булдырырга, даими дәреслек, куллану дәрәҗәсенә күтәрергә иде.

Ярар, тәкъдимнәрне шушында туктатыйк, аларны укытучылар, методистлар әйтсә, урынлырак булыр. Шул уңайдан сүз белән сурәт ясау темасын олимпиада сораулары рәтенә кертү тәкъдименә дә сездән фикер көтеп калам.

Илдар НИЗАМОВ.

Кирәкле кулланма

Татарстан китап нәшрияты Зәйнагетдин Вәлиевнең "Эш кәгазьләре үрнәкләре" ("Образцы деловых бумаг") дигән җыентыгын басып чыгарды. Ул ике телдә әзерләнгән.

Җыентыкка тормышта аеруча еш очрый торган һәм закон таләп иткән махсус формада тутырыла торган эш кәгазьләре үрнәге (телеграмма, белдерү-игълан, тәбрикләү, хат, биография, алу-бирү кәгазе, гариза, доклад язмасы, сыйфатнамә (характеристика), беркетмә, боерык, шартнамә (килешү), ышаныч язуы, мираска хокук, васыятьнамә, акт, китерелгән зарарны кайтару йөкләмәсе һ.б.) кертелгән.

Документ үрнәкләре билгеле бер эзлеклелектә гадидән катлаулыга үсеш тәртибендә мәктәп дәреслекләрендә үк очрый торган иң гади формадагы эш кәгазьләре үрнәкләре бирүдән башланып, әчтәлеге һәм формасы катлаулана барган документлар урнаштырылган.

Кереш сүзендә автор – озак еллар мәктәптә эшләгән тәҗрибәле педагог, хәзер дәүләт оешмасы хезмәткәре – бик урынлы билгеләп үткәнчә, мәктәпне тәмамлаган укучылар әле тормышта даими очрый һәм билгеле бер формада гына тутырыла торган эш кәгазьләре, гражданлык-хокукый характердагы документлар белән эш итә белми. Ә хәзер, татар теле дәүләт теле статусы алгач, мәсьәлә тагын да җитдиләнә төшә, чөнки дәүләт телен куллану, аны гамәлгә кертү эш кәгазьләрен, гражданлык-хокукый документларны шул телдә кулланудан башлана. Шулай итеп, җыентык, мәктәп балаларын һәм киң катлау укучыларны иң әһәмиятле эш кәгазьләрен ике телдә дә дөрес тутырырга өйрәтүне һәм дәүләт теле статусы алган татар телен гамәлгә кертү эшендә конкрет булышуны максат итеп куеп, изге эш башкара дип саныйк.



■ *Иҗади эш, мәдәни эш... бер сыйныфның көче белән генә эшләнә алмый...*
■ *Һәммәбезгә гомуммилләт юлында эшләргә тиеш, фарыз.*
■ *Кулыңда ни бар, күкрәгеңдә нинди көч бар: китер милләт мәйданына, китер!*

Гаяз ИСХАКЫЙ.

"...Милләтнең иң бөек демократ мөхәррире"

Гаяз Исхакыйның беренче урыс революциясе елларында чыгарган "Таң йолдызы" гәзитенең шигаре кыскалы: "Белем – фикер ачкычы вә сәгадәт баскычыдыр". Әмма бу гаҗәп түгел, чөнки гәзит, "эшче вә һәм үзе эшләп көн күрә торган авыл халкының файдасы вә сәгадәтләрен" күзәтү белән бергә, "татарларның милли вә дини эшләренең һәммәсенең дә тәмам үз кулларына" керүе өчен җиңәчәклеген белдергән иде.

1913 елда оештырылган "Ил" гәзитендә исә милли-мәдәни мәсьәләләр аеруча киң куела, һәм алар халыкның сәяси һәм икътисади хокукларын яклау җирлегендә яктыртыла. Мәдәниятне, бигрәк тә әдәбият-сәнгатьне үстерү, яшь буынга белем һәм милли тәрбия бирү, дин мәсьәләләре, милли матбугат бурычлары "Ил"нең (соңыннан – "Сүз", "Безнең ил") даими игътибар үзәгендә була. Бу гәзиттә Гаяз Исхакыйның үз мәкаләләре дә күп басыла. Аларның бертөрлесе баш мәкалә сыйфатында – теге яки бу вакытта, үзенчәлекле хәлдә хәрәкәт итү юлларын сызып күрсәтәләр, икенчеләре, аерым көнүзәк мәсьәлә уңаеннан язылып, аны җитди бәяләү һәм гомумиләштерү белән тәмамлана, кайберләре билгеле бер теманы махсус тикшерү максаты белән язылган (әйтик, Г.Тукай темасы, татар театры мәсьәләләре, үсеп килүче яшь буынга милли тәрбия бирү бурычлары әнә шундыйлардан).

Фатих Әмирхан Гаяз Исхакыйның "демократ милләтнең иң бөек демократ мөхәррире" дип танылуын әйтә. ("Кояш", 1917, 11 апрель). Әйе, Гаяз Исхакыйның очлы күзе, тынгысыз зиһене күп нәрсәләрне күрә, һәм ул бернәрсәгә дә битараф калмый. Еш, шактый еш очракларда ул борчыла, көенә, ярсый, әмма шатлана, куана, горурлана да белә. Менә аның "Ял итү мәсьәләсе" ("Ил", 1914, 10 гыйнвар) исеме белән чыккан бер мәкаләсе. Ул Казанның Дума мәҗлесендә әлеге мәсьәләнең каралуы уңаеннан язылган.

"Көтелгән, "курку белән көтелгән" эш бер генә иде, – диелә мәкаләдә, – ул да мөселманнарга үз бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә ирек бирү, мөселманнарга чиркәү бәйрәмнәрен мәҗбүри иттермәү иде". Приказчикларның Шәрык клубында җыелышып, Казан мөселман хезмәткәрләренең ял итү көннәре мөселман бәйрәмнәрендә булса иде дигән карарга килүләрен, бу фикерне урыс җәмәгатьчелегенә җиткерергә, урыс гәзитләренә язып чыгарга "сүз төенләну"ен сөйләп, Г.Исхакый бу хәлгә югары бәя бирә, әлеге карарның "бөтен мөселман дөньясына тәэсире булачагы"на куана, дини-милли хокуклар өчен шундый бердәм хәрәкәтләрне хуплый:

"Мөселман приказчикларының шул зур мәсьәләдә бер көч, бер куәт булып бергә хәрәкәтләрен вә шул дини-милли мәсьәләдә күзләрен ачып, алны-артны карый белүләрен бик шатланып каршы аламыз.

Вә киләчәк мәҗлестә хуҗаларның да шул әһәмиятле дини-милли мәсьәләдә үзләренең вак-төяк мәнфәгатьләреннән югары торып, кибетләренең артыкы ишекләрен ябарга ачык карар бирүләрен вә сатлык календарьчыларның мөселманның һәр бәйрәмен җомгага тугъры китерттерү юлыннан тәмам бизгәннәрен ап-ачык әйтүләрен вә тотыруларын көтеп торамыз".

"Мөселман фракциясе" исемле мәкаләсендә ("Ил", 1913, 13 декабрь) Г.Исхакый "Тәрҗеман" гәзитенең мөселман халыкларына "гафил милләт" дигән мөһер сугуына үртәлә (мәкаләдән күренгәнчә, "Тәрҗеман" мондый нәтиҗәне IV Дәүләт Думасындагы Мөселман фракциясенең секретаре, канцелярия эшләрен йөртүчесе квартирасы булмавыннан "озын мәгънәләр" чыгарып ясый) һәм, иң элек татар халкын күздә тотып, "безнең милләт гафил түгел" дигән фикерне яклап чыга, яклап кына калмый, аның булдыклылыгын, тырышлыгын күрсәтә, ассызыклый, шуның белән горурлана, шул хисне укучыларга җиткерергә ашыга:

"Шул "гафил милләт" бит үзенең милли мәктәбен тәрбия итеп килә! Берне, унны, йөзне, меңне түгел, берничә меңне тәрбия итеп килә.

Шул "гафил милләт" бөтен халкымызга йитеп торырлык муллалар чыгара торган мәдрәсәләрне тәрбия итеп килде, һаман да килә.

Шул "гафил милләт" тырышып-тырмашып хөкүмәт мәктәпләрендә укучыларга ярдәмгә кереште. Көннән-көн ярдәмен арттыра.

Шул "гафил милләт" көннән-көн арта торган, соңгы сигез елда йөз мәртәбә арткан китап базарын күтәреп килде. Һәм дә килә.

Шул "гафил милләт", Уфада дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимәт мәсьәләсе чыккач та, ике йөз мең сумны чылтыратып мәҗлескә салды. Шуны икеләтергә, өчләтергә разыйлыгын күрсәтте.

Шул "гафил милләт"нең Казандагы гына бүлеге кызлар гимназиясе чыгу берлән, мәҗлестә ике йөз мең сумлык бер сәрмаяны мәйданга атты. Манигълар булмаса, тагын арттырачагын күрсәтте.

Шул ук "гафил милләт" беренче, икенче, өченче Думаларда фракцияләрен күтәреп килде".

Моннан тыш, "Ил"дә хөрмәтле шагыйребезгә Г.Исхакыйның "Милли фаҗига" (1914, 2 апрель) һәм "Тукай мәхәббәте" (1914, 2 сентябрь), "Петербург, 19 март" (1914, 29 март) исемле мәкаләләре дә багышланган. Бу турыда махсус сөйләргә кирәк.

Ә бу санда, кадерле укучылар, без сезгә милләтебезнең бөтенләген, мәдәни үсешен, сәяси хокукларының камил булуын күрергә, шуларга ирешү мөмкинлекләрен зарыгып көткән әдип һәм публицистыбыз, асыл мөхәрриребез Гаяз Исхакыйның "Саф башына" исемле мәкаләсен тәкъдим итәбез. Бу мәкалә "Ил"нең февраль революциясеннән соң яңадан үз исеменә кайтып чыга башлаган 1917 ел 23 март (N 1) санында басылган.

Саф башына

Бөтен Русиянең өстенә албасты ишәюе булып яткан иске идарә җимерелде. Бөтен Русия халкының алга таба атлавында кулын, аягын богаулап яткан, бөтен Русия халкының яхшы сүзенә, яхшы уена "язык" мөһерен сугып яткан идарәи мөстәбидә сәберелеп ыргытылды. Русиянең бөтен халкы өстендә җәберен, золымын йөретеп торган падишаһ, үзенең бөтен былчырак министрлары белән үзенең бөтен хыянәтчел киңәшчеләре белән бергә зинданнарга атлады.

Русия халкының алга атлавында, Русия халкының хокуклы булуына киртә булыр өчен ясалган диваннар, мәхкәмәләр төбеннән кырылды. Аларның корган үрмәкүч оялары пыран-заран китерелде. Аларның юлбашчылары, аларның түрәләре җәһәннәмнәргә җибәрелде.

Хәзер Русиянең өстенә басып тын алырга ирек бирми торган патша юк.

Хәзер Русиянең халкына күкрәк киереп сулыш алырга ихтыяр бирми торган фиргавен хезмәтчеләре, жандармнар, полицияләр юк.

Хәзер һәрбер яхшы күңелле кешенең өстеннән карап тора торган шпион юк.

Һәрбер төркем халыкның мәдәни эш эшләвеннән донос итеп тора торган даирәләр, идарәләр юк.

Хәзер халыкның файдасына эшләнгән һәрбер сәясәт, мәдәни, милли хезмәт өчен төрмәләргә, зинданнарга яба торган мәхкәмә, суд юк, һәр яхшы эшкә каршы килә торган закон-канун юк.

Хәзер золым, җәбер, талау падишаһлыгының нә тәхете бар, нә диваннары бар, нә төрмәләре, нә дә жандармнары бар!

Хәзер бөтен халыкны изеп тотарга корылган исКе идарәнең нә кәнцәсе бар, нә шуны борып халыкның күз яшене сыгып чыгаручы, канын агызучы төрмәләре, хезмәтчеләре бар!

Хәзер һәммә бетте. Һәммәсе җимерелде.

* * *

Боларның җимерелүеннән без, Русия мөселманнары, кайгырмыйбыз, боларның җәһәннәмгә китүеннән без, Русия мөселманнары, матәм тотмыйбыз.

Чөнки, **чөнки иске идарәдән без, Русия мөселманнары, золым, җәбердән башка һичбер нәрсә күргәнебез юк иде.**

Чөнки без, Русия мөселманнары, иске идарәдән киләчәктә дә бертөрле файда күрәчәк түгел идек, күрү ихтималыбыз юк иде.

Иске идарәнең бабаларымыз белән ясаган могаһәдәләрендә безнең динемезгә тәгъриз итмәскә ант иткән булса да, аның падишаһы, аның түрәләре, аның мәхкәмәләре ислам динен үзләренең канцелярияләренең уенчыгы ясаган иде. Ислам диненең әсасларын, ислам халкының хокукларын былчырак полицейский участокларының идәнендә таптаткан иде.

Иске идарә мәхәлләсенә имам тәгъйин итүне исерек урядник, ришвәтче приставның карамагына тапшырган иде.

Унар миллионлы мөселман халкының рухани башлыгына мөфти тәгъйин итүне охранкадагы шпионнарның кулына биргән иде...

Иске идарә безнең газиз бабаларымызның балаларына изгелек итәр өчен калдырылган меңәр миллионнар сумлык вәкыфларын талап бетергән иде. Аның падишаһлары, түрәләре шул вәкыф җирләрене газап итеп, шуларга гишгашрәт урыннары төзегән иде...

Иске идарә безнең милли хәятемез башланмасын өчен кулыннан килгән бөтен усаллыкны эшләгән иде. Ул мәктәпләремезне, җәмгыятьләремезне йөзәр-йөзәрләбән япкан, мөгаллимнәремезне, мәдрәсәләремезне, җәмәгать хәдимнәремезне йөзәр-йөзәр Себерләргә сөргән иде, сөрә иде. Киләчәктә дә сөрәчәк иде.

Иске идарә Төркестанда мәктәп ачуны бөтенләй тыйган иде. Төрле хәйләләр белән мөгаллимнәремез, мөгаллимәләремез дәресләреннән, сөйгән балаларыннан сөрелеп тора иде. Бөтен Төркестан мөселманнарының алга китмәүләре мәктәп ачмаулары өчен, бөтен гыйльми эшне миссионерлар Ильминский шәкерте миссионер Остроумовның ихтыярына биргән иде.

Иске идарә безнең гражданлык хокукларымызны талаган иде.

Без, Русия мөселманнары, никадәр бөтен халык белән бер дәрәҗәдә түләү бирсәк тә, бөтен халык белән бер дәрәҗәдә гаскәр биреп торсак та, хөкүмәттә без таланган идек. Земство сайлауларында безне бөтенләй катнаштырмыйлар иде. Безнең тора торган күп вилаятьләрдә безгә файда булмасын дип земстволар ясатмыйлар иде.

Дәүләт Думасын сайлауда безнең өчен кысынкылыклар, кырык төрле хәйләле тегермәннәр корылган иде. Төркестан, Казакъстан халыклары сайлау хокукыннан бөтенләй мәхрүм ителгән, Идел буена йөз, йөздән бер генә сайлау хакы бирелгән иде. (Утыз миллионлы мөселманның санына күрә, хәзерге Думада җитмеш, сиксән депутат булырга тиеш булса да, хәзер җиде генә кеше булуы ни дәрәҗәдә җәберләнүемезгә шаһәдәтдер).

Боларның һәммәсене дә иске идарә эшли иде һәм дә аңлап йөри, эшли иде. Киләчәктә Русиядә мөселманлык булмасын, киләчәктә Русия мөселманнары мәдәни хәят белән яши торган аерым бер халык булмасын өчен эшли иде.

Шуның өчен шул залим хөкүмәтнең бетүенә без, Русиянең гражданы булуымыз җәһәтеннән бер мәртәбә, Русиядә динемез ягыннан хәбәрләнүче булу ягыннан икенче мәртәбә, милли хәятемез, милли идеалымыз тәхкыйрь ителүчеләр булуымыз ягыннан өченче мәртәбә сөенәмез.

* * *

Хәзер безнең гражданлык хокукымызны алырга каршы килүче идарә җимерелде. Хәзер безнең дини хисләремезне тәхкыйрь итүче, дини эшләремезне изүче идарә бетерелде.

Хәзер безнең бер милләт булып яшәвемезгә каршы аяк чала торган әфсеннәр тозагы кырылды.

Бөтен теләгемезгә, бөтен эшемезгә, бөтен идеалымызга вөҗүдкә чыгаруга киң мәйдан ачылды.

Ләкин бу мәйдан әле буш. Ләкин бу мәйдан әле эшләнмәгән. Мондагы бабаларымыздан мирас калган кырлар сукаланмаган, бабаларымыздан мирас калган бакчалар төзәтелмәгән. Батыр бабаларымызның атларының тояклары астына ялтырап калган юлларымызның буена милли маяклар утыртылган.

Киңлек, мәйданлык, бушлык!

Ләкин әле эшче юк. Шул мәйданлыкта кояш чыкканда, иртәнге хөррият кояшы чыкканда, әле без анда юк.

Милли сандугач сайравы да безне әле уятмаган. Мәзиннең...азаны да әле безне йокыдан калкытмаган.

* * *

Кояш чыкты. Нур балкыды... Эшче эшеңдә бул!

Тамырларыңда бабаларыңның хәләл каны акса, бушлык мәйданына ашык!

Адәм баласының гомерендә генә түгел, халыклар, милләтләрнең гомерендә бер генә була торган шундый сирәк көндә саф башында бул!

Голямасы, руханисы, зыялысы, мөхәррире, язучысы, сәүдәгәре, кәсепкәре, укучысы, укытучысы, һәммәгез мәйданга, саф башына!

Элгәреге вак-төяк низагларны, вак-төяк җирле мәнфәгатьләрне оныт!

Ир бул! Гомереңдә бер генә мәртәбә ир бул!

Милләт, дин, Ватан барыңызны да ир булырга чакыра!

Сәүдәгәр! Һәр нәрсәгә үз мәнфәгатең ноктасыннан карауны бер генә көнгә, бер генә айга ташла!

Мулласы, мәзине, мөгаллиме, мөгаллимәсе, укучысы, язучысы, мөхәррире үзенең тирә-янындагы чүп-чардан өскә чык!

Бүген син җирле мәнфәгатеңнең хезмәтчесе түгелсең. Бүген син бер гаиләнең атасы гына түгелсең. Бүген син бер мәхәлләнең имамы түгелсең. Бүген син табышны күбәйтер өчен генә яши торган бер магазинның хуҗасы түгелсең.

Бүген син меңәр ел дөньяны тетрәткән батыр бабаларыңның угылысың.

Бүген син дине, милләте юлында төрмәләрдә черегән шәһид ирләрнең баласысың. Бүген син киләчәктә туачак якты көн, иреклe хәятне төзүчесең, эшләүчесең.

Һәммәбезгә гомуммилләт юлында эшләргә тиеш, фарыз.

Һәйдә милләт мәйданына! Кулыңда ни бар, күкрәгеңдә нинди көч бар: китер милләт мәйданына, китер. Милләт бинасын ныклап корыр өчен, бергәләп, киңәшләшеп корыр өчен кулыңда ни бар, кызганма!

ГАЯЗ.

Искәрмә. *Мәкаләне мәгънәви буыннарга бүлү, аерым фикерләрне ассызыклау, берникадәр кыскарту безнең тарафтан эшләнде.*

Сүзлек: **мөстәбидә** – *изүче, деспот;* **диван** – *биредә: дәүләтнең югары советы;* **мәхкәмә** – *хөкем итә торган идарә, хөкем йорты, суд;* **могаһәдә** – *килешү, вәгъдәләшү;* **тәгъриз** – *ризасызлык белдерү, каршы тору;* **тәгъйин** – *билгеләү;* **вәкыф** – *килере (кереме) җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек;* **гашрәт** – *эчү, типтерү;* **тәхкыйрь итү** – *мыскыл итү;* **вөҗүдкә чыгару** – *тормышка ашыру;* **голяма** – *галим;* **мәгъсүм** – *гөнаһсыз, керсез;* **манигъ** – *киртә.*

Сәхифәне басмага
КДУ доценты
Мөнҗия МӘРДИЕВА
әзерләде.

И туган тел... 1998 ел 30 гыйнвар № 1 (53)

Ак юл сиңа!

Казанда "Фән һәм тел" дигән яңа фәнни-хәбәри журнал басылып чыкты. Гамәлгә куючылары: Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар бүлеге, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясе. Баш редакторы шул академиянең доценты, техник фәннәр кандидаты, урысча-татарча төзелеш терминнары сүзлекләре, 50дән күбрәк гыйльми һәм методик хезмәт авторы Рәшит Әгъләм улы Шакирҗанов.

Бу – тулаем фәнгә багышланган татарча беренче журнал әле. Ул Икенче Бөтентатар конгрессына багышланган иде. Анда асылда төрле фән өлкәләрендә ирешелгән казанышлар һәм проблемалар турында татар галимнәренең татарча мәкаләләре тупланган. Журналны гамәлгә куючылар аны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү чарасын күрергә җыена. Шул уңайдан журналга тәфсиллебрәк күз салыйк әле.

Баш редактор үзенең кереш сүзендә журнал чыгарырга этәргән күп сәбәпләр арасыннан "иң изге теләкләр – телебезне саклау һәм үстерү, аны алдынгы телләр сафына кертү, татарча тәгълим һәм югары белем бирү, дөньякүләм югары дәрәҗәдә татарча фәнни эш башкару теләкләре – туган телнең көченә, бәеклегенә, якты киләчәгенә ышанган зыялыларның, галимнәрнең, мөгаллимнәрнең, күңел түрендә "мәңге сүнмәс ут булып януын" да атый. Журнал алдына куелган максатлардан ул менә боларны да саный: "татар галимнәре турында даими сөйләү, башкарган хезмәтләрен, халыкыбызга һәм дөньяга тарату; шуларга таянып, татар халкының милли горурлыгын уяту, аның үз теленә мәхәббәте, фәнни мәкаләләр бастыру, татар телендә фәнни мәгълүмат, интеллектуаль байлык туплау эшен тизләтү; фән нигезендә телне, тел нигезендә фәнне өйрәнү һәм үстерү; татар теленең мөмкинлекләрен ачыклау, аның заманча танып белү ысулы икәнен, киләчәге өметле булуын күрсәтү; "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы законын тормышка ашыру, татар телендә югары белем бирү, татарча фәнни терминнар системасын төзү һәм фәнни стиль булдыру мәсьәләләрен карау" һ.б.

Академиклар Мирфатыйх Зәкиев һәм Индус Таһиров яңа басмага хәер-фатиха сүзе әйткәннәр, аның иҗади юнәлешен ачыклаганнар һәм киңәшләр биргәннәр.

Вәгъдәсенә тугры калып, журнал "Мәшһүр галимнәребез" дигән рубрика ачып җибәргән һәм аны Хәмит Мөштәригә, аның иҗатына багышлаган. Күренекле галимнең фәнни хезмәтләре исемлеге, аның турында истәлекләрдән өзекләр урнаштырылган.

"Татар телендә югары белем бирү мәсьәләләре" рубрикасы – иң байлардан. Анда Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясе галимнәре Вәгыйз Фәтхуллин, Альберт Нарбәков, Русия мәгариф академиясе академигы Мирза Мәхмүтов, профессор Яхъя Абдуллин, Казан дәүләт технология университеты галимнәре Ринад Галимулла һәм Марат Мөхәммәтҗан, Кама политехника институты доценты Рөстәм Вәлиев бу теманың төрле якларына караган проблемаларын күтәрәләр, чишелеш юллары да күрсәтәләр.

"Татарстанда сәнәгать һәм төзелеш институты" дигән бүлектә татарның Сөяр Айдаров, Равил Газизуллин, Фәрит Җамалиев кебек белгеч-галимнәре катнаша. Ә "Татар галимнәре – фәнгә" дигән бүлектә күренекле татар галимнәре үз белгечлекләре буенча яңа, актуаль мәсьәләләрне күтәрәләр: Альфред Әхмәдиев, Равил Ибәтов, Ренат Гыйззәтов (төзелеш технологиясе), Расих Сәлимов, Елена Насыйрова (математика), Назим Габбасов, Әмир Сибгатуллин, Самат Тимергалиев, Гали Даутов (математика, физика).

"Фәнни тел һәм стиль" рубрикасы да укучыларны җәлеп итәр дип өметләник. Бу санда тел галимнәре Флера Сафиуллина ("Фәнни стиль үзенчәлекләре"), Лениза Ризванова ("Татар теле һәм кампитр"), Тәүзих Ибраһимов ("Татар тел белеменә караган кайбер мәсьәләләр"), Рәсимә Шәмсетдинова ("Татар телендәге медицина терминнары белән бәйле кайбер проблемалар") язмалары урын алган.

Укучыга соңгы сүзендә редакция саннан-санга журналның сыйфатын яхшыртырга вәгъдә бирә, бу сан турында фикер-тәкъдимнәр әйтүләрен, материаллар җибәрүләрен үтенә, шулай ук журналны бастырып чыгаруда спонсорлык ярдәме күрсәткәне өчен "Инженер-техник үзәк" җәмгыяте директоры Шәүкәт Хәсәнҗановка олуг рәхмәтен белдерә.

Ак юл сиңа, яңа журнал!

И.МАЗИН.

Җырым – телдә, телем – җырда

Җырлыйк, дуслар,
бергәләп җырлыйк, дуслар,
Иң матур җырларны сайлап кына.
Иң матур җырларны сайлап кына,
Яшик бу илләрдә сайрап кына.

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА.

Күз җиткезер,
күз җиткезмәсә,
сүз җиткезер

Күңел сырхавы –
күп сөйләү

Этимологик табышлар

Кир ат, киртеш һәм кәркәдән

Хәтта филологлар да еш кына җырларда очраган **кир ат** сүзен **(Салават батыр ир иде, Менгән аты кир иде...) кире ат** дип аңлаталар.

Хәлбуки **кир** төрки телләрдә киң таралган **кәр** – **"аксыл туры"** (ат төсмере) сүзенең татарча яңгырашы һәм аның кызыклы тарихы бар.

Борынгы төрки **кәр, кәәр**, монголча **кәгәр,** фарсыча **кәһәр** "мамонт, казылма фил" һәм, гомумән, **"әзмәвер, гигант (хайван)". Кәр, кир** "мамонт төсендәге" дигән сүз булып чыга. Борынгы Урта Идел төркиләрендә бу сүз **кәр** булып яңгыраган һәм шуннан урысча **карий** "караңгы коңгырт" сүзе килеп чыккан.

Себер төркиләрендә **кәр,кәр** "гадәттән тыш зур, әкияти"; **кәр** балык "кит, әкияти гаять зур балык", **кәр йылан** "филләрне йота торган елан", **кәр куш** "биниһая зур әкияти кош (рух кошы, сәмруг, ганка һ.б.ш.). Безнең **кара кош** дигәнебез, ихтимал, ки, **"кәр кош"** сүзеннән азгандыр.

Себер татарларында **киртеш "мамонт теше"** (шуны да әйтеп үтик – **мамонт** сүзе үзе дә Себер татарлары шивәсеннән таралган дип уйлыйлар. Элек Себердә **мамонт сөлтәрләре** бик күп табылган һәм Себер татарлары **киртештән**, хәтта, **киртәләр** корганнар.

Кир – кәр – кәһәр сүзен борынгы һинд-иран телләрендәге **кәәрк** "гаял, гаять зур кыргый сыер (сыер сыманнарның иң зуры, авырлыгы тонна тирәсендә); мөгезборын" сүзенә кайтарып калдыралар. Бу **кәәрк** сүзеннән борынгы ирани кәркәидан "су сыеры бегемот, мөгезборын" сүзе ясалган. Шуннан татарча **кәркәдән** "мөгезборын; мөгезле коңгыз" сүзе килә (бу сүз төрки язма телдә киң кулланылган).

Хәзерге китапларда очрый торган **борынмөгез, мөгезборын** сүзләре урысчадан кирәкмәгән калькалар (урысча **носорог** дигәннән). Татарча дөреслек төзүчеләр татар телен тиешле дәрәҗәдә белмиләр һәм шуннан **мөгезборыннар** һәм башка "мөгез"ләр чыгарыла.

Гаялны мөгезборын һәм бегемот белән, ә соңгысы мамонт белән буташтырулар җитмәгән, татарча **кәркәдил**, урысча **крокодил** сүзе дә әлеге **кәркәдилгә** кайтып кала.

Киршән

Татар сөйләшләрендә **киршән** һәм **кәршән**, башкорт сөйләшләрендә **кәрсән,** күп кенә төрки телләрдә (үзбәк, әзәрбәйҗан һ.б.) **кәрсән, кәрсәң, киршәң** "улакчык; тормоз калыбы; ванна" сүзе борынгы **кәр, кир** "агач савытның озынча төре" сүзеннән килә. Бу сүз татар телендә дә булган: моңа дәлил – татар сөйләшләрендәге **балакир** "кечкенә кир, агач тагарак" (урыс сөйләшләрендә **балакир** "балчык тагарак") һәм мари телендәге **кир, гәр, кирсалма, гәрсалма** "үлчәү табагы" сүзләре.

Кисәртке, кәсәртке һәм кәлҗыгыр

Кисәртке, кәсәртке дип кәлтәнең бер төрчәсен – Н.Исәнбәт буенча "кечерткән кәлтәсен" атыйлар. Бу сүз кыпчак төрки телләрендә (башкорт, караим, казах, кумык һ.б.) шуңа охшаш, ә карачай-балкарча **кәсәликә**, борынгы кыпчак-гарәп сүзлекләрендә **кәсәлтки, кәсәлтәки**, Алтай-Енисей төркиләрендә **кәләски, кәләскән** кебек яңгырашларда очрый.

Бу сүзне этимологик хаклы рәвештә борынгы **кәләз – кәләр – кәлән** (бу вариантлар хәзерге телләрдә дә очрый) "кәҗелле кәлтә, варан" нигезенә нисбәтлиләр. Борынгы төрки язмалардагы кәлар, кәлан "сыңар мөгез (мифик мөгезле айгыр" сүзе дә шулар рәтенә карый һәм Кытай телендәге **цилинь, килинь, килиң** "сыңар мөгез, **кәркәдән**" сүзеннән килсә кирәк.

Ләкин моннан **кәсәртке-кәләзәртке** сүзенең тамыры Кытай теленнән дигән нәтиҗә чыкмый әле. Кытай теле ничек кенә оригиналь булмасын, бөтенләй изоляциядә үсмәгән. Һәм **кәлар** тамыры үзе төрки телләрдән булырга мөмкин: кытайлар сүз азагында -рны -нга әверелдергәннәр (мәсәлән, **татар сүзен татань** дигәннәр). Гомумән **кәл, кәр** тамыры "кәлтә" мәгънәсендә Евразиянең күп телләрендә очрый: таҗик һәм төрекмән телләрендә **калпеса**, борынгы сугди телендә **кәрпесәк** һ.б. "кәлтә".

Татар һәм башкорт сөйләшләрендә очрый торган **кәлҗыгыр** "мунча кәлтәсе; кәлтә кыяфәтендәге мунча иясе" сүзе дә шул **кәл** тамырыннан, әлбәттә.

Кәлтә сүзенең үзенә килгәндә, ул **кәл** тамырыннан түгел, ә күп төрки һәм күрше телләрдә таралган **кәлтә** "кыскартылган, кәтек" сүзеннән. Кәлтәнең тулы атамасы **кәлтәкисәк-кәлтә-кәләзәк** (әлеге кәләз!) ягъни "кыска варан".

Татар биологик терминологиясендә **кәлтә, кәлҗыгыр һәм кисәртке** сүзләрен аерым хайван төрләрен белдерү өчен файдалану хәерле.

Кисәү һәм күсәк

Кисәү "янып торган утыннарны, күмерне болгата торган тимер корал". Кайчакта "янып яткан агач кисәкләре" мәгънәсендә дә кулланыла. Ләкин бу куллаңыш дөрес түгел – соңгы мәгънәдә дөресе **кисәүбаш** (чаг. урысча головня, головешка).

Кисәү сүзе, һичшиксез, **күсәү** вариантыннан үзгәргән (аналогы: **кигәвен – күгәвен** "күк башлы бөҗәк"). **Күсәү** исә борынгы (Ибне-Муханна сүзлеге һ.б.) **күсәчү "кисәү"** сүзеннән, ә бу сүз исә **күсә-мәк** "янган учакны, мичне болгатып, яну процессын көйләү" фигыленнән ясалган.

Шул ук **күсәчү** сүзеннән **күсәк** сүзе дә килә.

Бу сүзләрнең тамыры **күс-күөс** "янып яткан күмер". Шуннан **үт-күз** парлы сүзендәге **күз** сүзе дә килә.

Бу фикерләр төрки телләрдә булган йөзләрчә мисаллар белән раслана. Ләкин монда соңгы **күз** вариантының килеп чыгышы аңлашылып бетми. Ихтимал ул шул мәгънәдәге **куз** сүзе тәэсирендә килеп чыккандыр. Шулай ук, **күс-күз** вариантларының борынгы **көйөс көйөз** (ө – монда гомумтөрки ачык ө, үө) нигезеннән булуы да ихтимал (ягъни **көй-ү** сүзенә тамырдашлар). Чагыштыр: татар сөйләшләрендә **күзәү, көйзәү** "учакны болгату; ашлыкны җилпеп, кибәктән арындыру".

Рифкат ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы,
профессор.

2002 Мәзәк

Сынык ил

Дәрестә укытучы:
– Русия нинди ил була инде?
Укучы:
– Сынык ил.
– Ничек инде сынык ил?
– Элекке СССРның сыныгыдыр инде.
– Ничек алай, каян алдың?
– Газитта "СНГ" дип язалар ич!

КИЛӘСЕ САННАРДА:

- ***Туган телне – гамәлгә!*** *Чаллыда үрнәк эшләр бар – өйрәник, кушылыйк.*
- ***Икенче Конгресс һәм тел мәсьәләләре.*** *Сентябрьдә – республикаара фәнни-гамәли конференция. Алдан әзерләник!*
- ***Гаиләдә тел тәрбиясе. Әби-бабайга рәхмәт әйтик.***
- ***Тел байлыгы артамы, кимиме? Лексик күзәтү.***
- ***Агач авыз – балта тел. Тәрҗемә "кәлҗемәләре".***

Кушымтаның мөхәррире
Илдар НИЗАМОВ.

Адресыбыз:
Бауман урамы, 19.

Гаяз Исхакый ВАРИСЫ

Мәшһүр татар сәясәтчесе, мөһаҗирлектә яшәүче татарларның күренекле вәкиле, ирекле журналистика аксакалы Али Акышка 80 яшь тулды. Бу шәхес XX гасырның дөньякүләм давылларын үз язмышы аша кичергән дияргә мөмкин. Шуңа күрә аның мажараларга искиткеч бай тормышы татар халкының яңа тарихында аерым бер сәхифә булып торырга лаеклы.

Әгәр тарихыбызда Али Акыш кебек затлар булмаса, дөресен әйтик, бик оятлы хәлгә калыр идек. Әйе, бабаларыбыз, әтиләребез канлы сугыш кырларында күкрәкләре белән амбразураларны капладылар, рейхстаг түбәләренә кызыл әләмнәр кададылар. Әмма рәхмәт урынына большевик-залимнәр милли һәм дини изүне көчәйттеләр генә, советлар империясендә яшәүче халыкларны милли инкыйразга сарык көтүең куган кебек кудылар. Аяныча, моңа каршы чыгучылар күп булмады. Һәр хәлдә, безнең Казан татарлары арасында андыйлар бөтенләй юк иде. Дөрес, кырым татарлары, украиннар, Балтыйк буе халыклары арасында тоталитар режимга каршы чыгучылар булды, аларны диссидентлар дип атадылар. Бу батыр затлар үз халыкларының азатлыгын, шәхес иреген, кеше хокукларын яклап зинданнарга ябылдылар, лагерьларга куылдылар. Шуңа күрә бүген кайбер замандашларыбыз "без диссидент идек" дип күкрәк сукканда, алар өчен кызарып та куясың. "Сугыштан соң батырлар күбәя" дип юкка гына әйтмиләр шул. Әмма безнең милләттәшләребез арасында да, шөкер, кыю көрәшчеләр бар иде. Али Акышны шуларның иң күренеклеләреннән дисәм, ялгышмам кебек. Али ага искиткеч тыйнак кеше, аннан беркайчан да мактану сүзләре ишетмәссез. Шулай да аның якын кешеләреннән ишетеп белүемчә, совет агентлары Али аганы өч тапкыр юк итәргә маташып карыйлар. Берсендә снайпер аны тәрәзә аша фатирында җәрәхәтли, әмма ул исән кала. Бу хәлләр "салкын сугыш" чорында Мюнхенда була. Али Акыш мөһаҗирлеккә үз теләге белән китми, ул 1918 елда чит илдә туа. Аның әтиәниләре Кытайдагы КВЖД тимер юлында эшләүче күпсанлы татарлар арасында була. Чыгышлары белән алар элеккеге Пинҗә гөбернәсеннән (хәзерге Мордовия республикасы) ишле вә затлы Агишевлар нәселеннән. Кайберәүләр, бәлки, белеп тә бетермидер: патша заманында татарлар тырышлыгы белән Себер һәм КВЖД тимер юллары буйлап сәүдә вә тәэминат эшләре яхшы куелган була. Татарның пәрәмәчләре-кыстыбыйлары бик үтемле ризык саналган.

Кечкенә Али башлангыч белемне Хайлар шәһәрендәге татар мәктәбендә ала. Аннары Харбинда урыс гимназиясен тәмамлый. 1935 елда Харбинга Гаяз Исхакый килә һәм "Милли юл" дигән нәшрият оештыра. Аның тирәсенә мөһаҗирлеккә киткән татар әдипләре, сәясәтчеләр туплана. Монда татар җәмгыяте барлыкка килә, аның эшендә 17 яшьлек Али Акыш та актив катнаша. Гаяз Исхакый Алины үз улы кебек якын итә, журналистика дөньясына алып керә. Яшь журналистның беренче язмалары Кытайда чыгып килгән "Милли байрак" мәҗмугасында дөнья күрә. Димәк, безнең замандашыбыз Али Акыш татар мәдәниятенең иң күренекле әһелләреннән берсе булган Гаяз Исхакый шәкерте. Тиздән без бу бөек шәхеснең 120 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Али ага кебек, аны якыннан белгән кешеләр, бәлки, бүген инде бөтенләй калмагандыр да. Менә ул заманнар бәйләнеше. Шуңа күрә Г. Исхакый юбилеена Али аганы кунак итеп чакыру бик дөрес булыр иде.

Гаяз Исхакый белән Али Акыш арасындагы дуслык тирән мәгънәгә ия. Бу — гади дуслык кына түгел, бу — рухи кардәшлек. XX гасыр татар дөньясында зур вә көчле күтәрелеш белән башлана. Бу тәрәккыятне галимнәр хаклы рәвештә хәзер татар Ренессансы дип атый башладылар. Ренессанс — ул халыкның терелүе, аның мәдәниятенең, идеалларының яңаруы. Идеаллары булмаган халык милләт булып оеша алмый. Табигый, коллыкта яшәгән халыклар идеалы бер — ул азатлык, бәйсез дәүләтчелек ихтыяҗы. Татар милли азатлык хәрәкәтен әйдәп баручы, аның чын лидеры һичшиксез Гаяз Исхакый була. Ул татар милли азатлык идеясен бер тәгълимат буларак формалаштыра. Аның атаклы "Идел-Урал" әсәрендә нәкъ шушы тәгълиматның гәүдәләнешен күрергә мөмкин. Менә кемнең варисы безнең замандашыбыз Али Акыш, менә нинди көрәшченең дәвамчысы ул!

1937 елда большевизм оппозиционерлары Варшауга күчеп киләләр. Бу очраклы булмый, әлбәттә. Польшаның азатлыгы өчен көрәшүче, илнең шул чордагы президенты Юзеф Пилсудский заманында Архангель гөбернәсендә сөргендә Гаяз Исхакый белән бергә була. Шунда алар дуслашалар. Варшауда татарлар азатлык көрәшен киң җәелдерәләр. Алар тырышлыгы белән бирелдә Сталин режимына каршы "Прометей" исемле сәяси блок төзелә. Бу блокка советлар империясендә коллыкка дучар ителгән халыкларның вәкилләре керә. Аеруча активлык күрсәтүчеләрдән украиннар, әзәриләр һәм татарлар була. Урыс эмигрантлары бу эшкә кушылмый.

1939 елның көзендә Һитлер белән Сталин үзара килешеп Польшага һөҗүм итәләр. Молотов-Риббентроп пактында каралганча, гестапо белән НКВД сәяси эмигрантларны бер-берсенә тотып бирә башлыйлар. Татар мөһаҗирләре канга батырылган Польшадан яшерен рәвештә көч-хәл белән чыгып китәләр. Татра һәм Карпат таулары аша башта Мажарстанга барып җитәләр. Аннан Трансильвания аша Румыниягә эләгәләр. Ниһаять, Кара диңгез буйлап Төркиягә килеп төшәләр.

Төркия татар мөһаҗирләрен үзенә сыендыра. Али Акыш тормышында яңа сәхифә ачыла. Башта ул Мисырның данлыклы "Әл-Әзһәр" университетында дин әһеле булырга укый (Али ага да Ислам тәгълиматын искиткеч тирәнтен белә). Әмма Африка һавасы аның сәламәтлегенә килешми. Али Төркиягә кире кайтып Истанбул университетының икътисад факультетына укырга керә. Ләкин аңа бу уку йортын тәмамларга да насыйп булмый. Вазгыять катлаулы булу сәбәпле, аны Төркия Армиясенә алалар. Али Акыш хәрби уку йортларын тәмамлап офицер була. Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач, "җиңүче" Сталин Төркиягә каршы гаять зур дәгъвалар белән чыга. Диктатор Советлар Союзына Осфор һәм Дарданелл култыкларын тапшыруны таләп итә. Төркия җитди рәвештә каршы торырга әзерләнә. Офицер Али Акыш үзенең солдатлары белән Каф тауларында карлы-бозлы окопларда совет һөҗүмен көтеп ята. Әгәр АКШ тәвәккәллек күрсәтмәсә, Сталин һичшиксез Төркиягә һөҗүм иткән булыр иде. АКШ Президенты Трумен Сталинны кисәтә: "Сугыш башласагыз, без сезгә каршы атом коралы кулланачакбыз".

Али аганың Төркия Армиясендә хәрби хезмәте 60 нчы елларга кадәр дәвам итә. Ниһаять, ул журналистикага әйләнеп кайта, аны "Азатлык" радиосына эшкә чакыралар. Мин аның ул чордагы чыгышларын әле дә хәтерлим. Безнең гаиләдә "дошман" радиостанцияләрен тыңлау гадәткә кергән иде. Мәрхүм әтием советларны, коммунистларны бер дә сөймәде. Шул ук вакытта ул бик татар җанлы, милли рухлы шәхес иде, мәчетне дә калдырмады. КГБның махсус хезмәте бу тапшыруларны техник чаралар белән бик тырышып томалый, шуңа күрә колаклар тонып бетә иде. Безнең күршедә яшәүче, инженер радиоалгычны 13,16,19 метрлы кыска дулкыннарга көйләп бирде. Бу дулкыннарны томалау булмады, чөнки совет радиоалгычларының иң түбән ноктасы 25 метр иде. Шулай итеп, Али аганың салмак тавышы безнең гаиләдә көн саен диярлек яңгырады. Мин аны гаилә әгъзасы сыман кабул иттем. Күп еллар үткәч, Али аганың үзе белән дә танышу бәхетенә ирештем. Ул 1990 елда беренче тапкыр Казанга килгән иде. Хәтеремдә, милли хәрәкәтнең зур митингы бара, айлы-йолдызлы әләмнәр җилферди, мәйдан тулы халык. Моны күреп Али ага бик дулкынланды, күзләренә яшьләр бәреп чыкты: "Өнемме бу, төшемме?" — дип сорап куйды. Гомумән, Али ага саф күңелле, зирәк кеше. Аның белән аралашу күңелгә ләззәт, җан рәхәте бирә. Аның эрудициясе таң калдыра, фикерләве тирән вә үзенчәлекле.

Соңгы ун елда татар милли азатлык идеясенең нык үсүендә, киң таралуында Али Акыш кебек фидакарь затларның өлеше гаять зур. Алар бу идеяне җиде дистә ел буе тоталитаризм шартларында саклап, яшәтеп килделәр. Али Акыш совет империализмын, Мәскәү колониализмын фаш иткән ике китап авторы. Аның мәкаләләре чит илләр матбугатында даими рәвештә басылып килә. Моннан тыш, аның тавышы ике дистә елга якын "Азатлык"тан да яңгырады. Миңа ул вакыттагы "Азатлык" тапшырулары тынчыган бүлмәгә саф һава кергән сыман тоелды. Һәр хәлдә, күңел түрендә азатлык хыялы, өмет чаткылары сүнмәде. Соңгы елларда Али ага мөһаҗирләрнең Бөтендөнья татар лигасын җитәкләп килде. Бу хезмәтләре өчен Али Акышны милли каһарман диярга була.

Али Акышның 80 яшьлек юбилее Русиядә милли азатлык хәрәкәтләренә каршы реакция көчәйгән чорга туры килде. Азатлык даулап күтәрелгән татар да төшенкелеккә бирелә башлады. Халыкны аңлап була: "суверенитет" чын азатлыктан шактый ерак булып чыкты. Әмма милләтнең азатлык юлында булуы хәерле. Төн үткәч таң ата, моны беркем дә үзгәртә алмый. Гәрчә, безнең кебек халыклар хәзергә эңгер-меңгер чорын кичерсәләр дә, дөньяда колониализм төне үтеп бара. Иншалла, безнең халык та хөрриятка ирешер. Мин Ходайдан бер генә нәрсә ялварып сорыйм: Али ага Акышка татар халкының чын азатлыгын, Татарстанның бәйсезлеген күрү насыйп булсын иде. Ул моңа безнең барыбыздан да күбрәк лаек.

Тәлгат БАРЫЙ.

Киңәш-табыш

Французча дәва

Минем еш кына тамагым авырта. Ләкин температура күтәрелми, гомуми авыруым да юк кебек. Тамак төбе кыра, ризык йоту кыен. Нәрсә икән соң ул? Тамакны дәваларга берәр яхшы дару юкмы икән, көн саен тамак чайкый торган төнәтмәләр дә туйдырды инде.

Х.ГАЗИЗОВ.
Казан.

Тамагы болай авырткан кешеләр үз хәлләренә күнегеп бетәләр. Температура булмагач, өске тын юллары ялкынсынуын табиб та раслый алмый. Ләкин, ангина һәм фарингит вакытындагы кебек үк, мондый хәл тамакка инфекция керү белән бәйле.

Нәкъ менә шундый авырулар өчен француз табиблары ("Пьер Фабр" фирмасы) ДРИЛЛ дигән препаратлар кулланалар. Пастила (как) рәвешендәге бу дару юеш һәм коры ютәл вакытында, томау төшкәндә, тамак авыртканда җиңеллек китерә. ДРИЛЛ пастилалары Көнбатыш дару җитештерүчеләренең "өч авыруны бер дару җиңә" дигән принцибына туры килә: инфекцияне җиңү, авыртуны бетерү һәм организмның авыру белән көрәшүенә ярдәм итү.

Как телемнәрен суырырга кирәк. Хәтта ул шикәр авыруыннан интегүчеләргә дә шифалы. Ләкин аны чәйнәргә һәм 5 көннән артык кулланырга киңәш итмиләр — тамакның табигый микрофлорасы бозылуы бар. Даруханәләрдән ДРИЛЛ кагы сорагыз.

Кызлар күңелен ничек яуларга?

■ Елмаегыз! Хатын-кыз пөхтә киенгән, әйбәт кырынган, елмаючан ир-егетләргә игътибар итә.

■ Хатын-кызга кыска, әмма үткен караш ташлау — "игътибар ит, бу — мин!" дигән сүз.

■ Бераз озаграк карап торуны хатын-кыз кызыксыну һәм чакыру дип кабул итә.

■ Ике арада симпатия тууын сизгәч, беренче адым ясала. Урындыгыгызны аңа якынрак шудырту тыныч үтсә, яңа адым ясарга мөмкин.

■ Битараф булып кыланыгыз. Бу кыяфәт сезне "серле" итә. Хатын-кыз бу "серне" ачарга омтылачак. Ләкин сезнең "битарафлык" юрамалый гына.

■ Хисләрегезне белдерегез. Монда арадашчы кирәкми, тәвәккәл, ягымлы булыгыз һәм кыю эш итегез. Хатын-кызлар "җебегән", "бозау" ирләрне өнәми.

Иң-иң...

Дөньядагы иң карт кияү – 103 яшьлек Гарри Стивенс. Ул 1984 елда 84 яшьлек Телма Лукаска өйләнә. Бу хәл Америкада, Висконсин штатындагы "Каравилла" картлар йортында була.

Иң яшь премьер-министр – Лихтенштейн дәүләтендә яшәүче доктор Марио Фрик 28 яшендә премьер-министр була.

Иң күп бала табучы ана– Русиядә яшәүче крәстиән хатыны Федора Васильева. Ул 1725-1765 елларда яшәгән. 27 тапкыр бала таба, 69 бәби алып кайта. 16 – икешәр игезәкләр, 7 мәртәбә өчәр һәм 4 мәртәбә дүртәр игезәк бала таба. Ул 69 баланың кечкенә чакта авырып икесе генә үлә.

Шундый ук мул уңышка ирешүче хатын XYII гасырда Англиядә яшәгән. Элизабет Гринхилл 38 тапкыр бала таба, аның 32 кызы, 7 улы була.

Дөньядагы иң карт кеше – француз хатыны Жанна Луиза Кальма. Ул 1997 елның августында 122 яшендә вафат була. Жанна Луиза 1875 елның 21 февралендә туган. Ә бүгенге иң карт кеше – ул да хатын-кыз – Канадада гомер итүче Мария Луиза Феброн-Мейлер. Аңа 116 яшь.

Кеше тәнендә иң югары температура булуын Атланта шәһәрендә (АКШ) күзәткәннәр. Эссе суккан 52 яшьлек Уилли Джонс Грейди "Мемориал" хастаханәсенә китерелә. Аның тән эсселеге 46,5 градус була. 24 көннән соң, терелеп, ул өенә кайтып китә.

Иң озак очкылык тотучы кеше Американың Антоны шәһәрендә яшәүче Чарлз Осборн. 1922 елда аны очкылык тота башлый, очкылык тотудан ул 1990 елда гына котыла. Ул ике тапкыр өйләнгән кеше, 8 баласы бар.

Иң озак үле ана карынында яткан бала Виргиния штатында (АКШ) туган кыз. Ул ана карынында 84 көн тора. һәм исән-имин дөньяга килә. 1983 елның 5 июлендә туган бу бала баш мие зарарланып вафат булган әнисе карынында шулай озак ята.

("КП").

Җир астында иң озак торган кеше – ул Һиндстан йогы Свами Нарайяна. Аны, эксперимент үткәргәндә, каткан буыннары, сулышы булмаган, йөрәге типмәгән һәм пульсы сизелмәгән хәлдә... җиргә күмәләр. 14 көннән соң, алдан килешү буенча, кабердән казып алалар. Йогны кайнар су белән юып, җылы май белән тәнен, әгъзаларын уып, терелтәләр. Күпләр моны фокус, мистика, могҗиза дип карый. Ә бу асылда – йоглар системасы. Аның нигезендә, ихтыяр көче, рәхимсез рухи һәм физик күнекмәләр, үз организмын идарә итүдә шәхси дисциплина ята.

Иң озак ач торучы кеше 1962 елда совет галиме – физик В.Лешковцев үз өстендә үзе эксперимент үткәрә. Ул 45 тәүлек ач тора! Су белән генә туклана. Тәҗрибә яхшы үтә. В.Лешковцев әйтүенчә, 3-5 көннән соң ашыйсы килү теләге бөтенләй бетә.

("Книга сенсаций").

Күңелнең сулмас гөлләре

Декабрь аеның зәмһәрир җилләре җаннарны өтеп-куырып алгандай итте. Әмма – ни могҗиза – шушы карлы-бозлы салкын көннәрнең берсендә аллы-гөлле чәчәк дөньясы пәйда булды. Ул көннәрдә "Казан" милли мәдәният үзәгендә рәссам Миләүшә Нуруллинаның шәхси күргәзмәсе ачылды. Нинди генә гөлләр юк иде аның тукыма-киндерләрендә! Алар гүя җаннарны җылытып, бозларны эретеп җибәрде.

Миләүшә – танылган язучыбыз Вакыйф Нуруллинның кызы. Быел аны Татарстан Рәссамнар берлегенә әгъза итеп алдылар. "Чәчәкләр дөньясы" – рәссамның икенче шәхси күргәзмәсе.



Нигәдер бездә хатын-кыз иҗатына бераз кимсетеп карау бар. Әмма Миләүшәнең рәсемнәре беркатлылыктан ерак тора. Аларда шактый гыйна тормыш тәҗрибәсе туплап, бар нәрсәне үз йөрәге аша үткәргән, дөньяның байтак нечкәлекләренә төшенә барган хисчән яшь ханымның уйчан карашы сизелеп тора. Аның иҗатына битараф, ят карашлардан яшерен шәһвәтлелек һәм нәзакатьлелек хас. Әйтерсең лә бу чәчәкләр – җанлы, әйтерсең лә һәркайсының үз йөрәге бар!

Һәр төс тә кешегә үзенчә тәэсир итә. Берсе шомландыра, берсе – моңландыра, ә берсе күңелгә җан тынычлыгы иңдерә. Миләүшәнең исә, хәтта "битараф" яшел төсе дә бинигһая төсмәрләре белән балкый, капма-каршы төсләрне дә кавыштыра, бербөтен итә. Рәсемдәге яфраклар, таҗ яфракчыклары кайсы җылы, кайсы салкын, кайсы җиңел, кайсы авыр, кайсы шома, кайсы кытыршы... Күз карашың белән шуны тоясың күк.

Миләүшә гөлләрен чорнап алган тирә-юнь мохит белән оста эш итә, дөресрәге, аны уйната белә. Шушы фон, "һава" ярдәмендә композицияне, яисә аның берәр өлешен яктыртып җибәрүгә җиңел ирешә.

Миләүшәнең иҗатында гөлләр генә тантана итми. Рәссамның графика өлкәсендә уңышлы әсәрләре эротик шәлкеме, сюрреалистик, галәм темасына багышланган үзенчәлекле рәсемнәре дә бар. Шуңа күрә аның иҗаты белән кызыксынучылар, күргәзмәне ачу тантанасына килүчеләр дә күп булды. Алар Миләүшәнең үзен дә чәчәк бәйләмнәренә күмделәр, әсәрләре БДБ илләрендә, Франция, Италия, Германия, Канада да шәхси тупланмаларда саклаучы рәссамга изгедән-изге теләкләр, яңа күргәзмәләр, иҗат уңышлары теләделәр.

● Рәссам Миләүшә Нуруллина һәм аның сулмас гөлләре.

Валентина ХӘЛИМДАРОВА,
"Казан" милли мәдәният үзәгенең сәнгать бүлеге хезмәткәре.

ЙОЛДЫЗНАМӘ
(2 - 8 февраль)

КУЧКАР (21.03-20.04). Акчагызны, малыгызны, табышларыгызны уяу саклагыз, чөнки бу атнада сезнең матди хәлегезгә зыян килүе бар. 4 февраль сезгә эшкә керешер өчен кулай көн. 3е көнне файдалы килешүләргә ирешерсез, хезмәттәшлеккә керешерсез. Әмма атна сездән сабырлык таләп итә, 2се һәм 7се көнне эшегездә шактый катлаулы бәхәсләр килеп чыгуы мөмкин. Дөньяда матди канәгатьләнүдән тыш рухи ихтыяҗ барлыгын да онытмагыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). Бу атна сезнең өчен уңышлы башланып китә. Тыгыз элемтәләр урнаштырып, яңа эшләр башлап җибәрерсез. Эшегездә зур үсеш кичерерсез. Ләкин үзегезнең таяныч булган якын кешеләрегезне онытмагыз. Тормышыгызда күңелле очрашулар, вакыйгалар булыр, илаһи көчләр сезнең җанга шәфкать иңдерер, тик аны максатчан итегез, яман ниятләрдә файдаланмагыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05-21.06). Бу сезнең өчен уңышлы атна түгел. Беренче чиратта бурларның кесәгезгә, сумкагызга керүе мөмкин. Сәламәтлек мәсьәләсендә дә шактый борчулар булуы ихтимал. 4, 5е көнне мөһим эшләргә алынмагыз, аларның нәтиҗәсе булмас. Гадәти шөгыльләр белән уздырыгыз. Эчке көчләрегезне туплап, киеренке хисләрегезне җиңелрәк уздырып җибәрергә тырышыгыз. Атна ахырында сез юлга чыгарсыз, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруга ирешерсез.

КЫСЛА (22.06-22.07). 2, 3, 7се сезнең өчен бик уңайлы көннәр. Атна башы үсеш вәгъдә итә. Илаһи серле көчләр дә сезнең карамакта. Рухи үсеш кичерерсез. Әмма тормыш үзенчә сынаулар куя, бәхетле минутлар да, көтелмәгән ямьсез вакыйгалар да булыр. Ләкин сез сабыр холыклылардан, бусын да тыныч кына кичереп җибәрергә тырышыгыз, начар уйларга бирелмәгез.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). Эшегез сезгә иң зур сөенеч китерер. Тагын да дәрәҗәле булырсыз. 3е көнне сез илаһи серле көчләр карамагында. Изге эшләргә алыныгыз, тормышыгыз тагын да тирәнрәк мәгънәгә ия булыр һәм алга куелган максатыгызга ирешерсез. Сезне юллар чакыра. Ул эшлекле узар, ләкин транспортта йөргәндә юл йөрү тәртибен саклау шарт. 7се көнне матди табыш керер, гаилә бюджетын тулыландырыр. 8е көнне якын туганнарыгызның хәлен белегез, өлкәннәрне искә алыгыз, зур проектларга керешмәгез.

КЫЗ (24.08-23.09). 2, 3, 5е сезнең өчен иплe, җайлы көннәр. Нәрсәгәдер ирештем дип, башкаларга бәйләнергә ашыкмагыз, чөнки тормыш сынаулардан тора. Бүген бәхет сезгә елмайса, икенче көнне ул башкаларга юлдаш була. 4, 6, 7, 8е сезнең өчен шундый сынау көннәре. Ләкин сез бирешмәскә тиешсез. Бәхәсләргә керешмәгез, үзегезне йөгәнле, чикле белегез. Сезнең өчен гаугага керешмәү хәерле.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). Атна башындагы күңелле очрашу тәэсире белән яшәргә туры киләчәк. Илаһи көчләр сезгә юлдаш. 4е көнне акчагызга игътибар итегез, кирәкмәс килешүләр төзергә ашыкмагыз, алтын таулары вәгъдә итүчеләргә ышанмагыз. 5, 6, 7, 8е көннәрендә сезне бәхәсләр, көтелмәгән күңелсез вакыйгалар, борчулы мәсьәләләр, күңел төшенкелегенә бирелү көтә.

ЧАЯН (24.10-22.11). Бу сезнең өчен борчулар, сынаулар атнасы. Гаиләдә, эштә, финанс мәсьәләләрендә, сәламәтлектә, тирә-юньдәге кешеләр белән үзара мөнәсәбәттә тулысынча капма-каршылык хөкем сөрә. Әлбәттә, моңа Чаянның холкы да сәбәпче. Еш кына ул үзен чикли, туктата, кулга ала белми һәм шуның белән уңайсыз хәлләр китереп чыгара.

УКЧЫ (23.11-21.12). 2, 8е көннәрендә сез илаһи көчләр карамагында. Сез рухи сафланасыз, күңел түрендә саклаган авыр йөкләрдән-хатирәләрдән арынасыз. 3е көнне бәхәскә керүдән сакланыгыз. Болай да начар, какшаган нерв эшчәнлегенә артык йөк салмагыз. Сәламәтлегегез какшау сәбәпле, дәвалану чаралары күрү шарт. Кешеләргә карата төшенкелек, өметсезлек кичерсәгез дә, сез аларны кичерә белергә тиеш. Якыннарыгыз, иң кадерле кешеләрегез сезгә изге ниятгә.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). 2, 5е көннәрендә сез юлда йөргәндә, эштә, транспортта бәхетсезлекләрдән нык сакланырга тиеш. 3, 4, 6, 8е сезнең өчен яңа башлангычларга, хезмәттәшлеккә, мөнәсәбәтләргә юл ача, кызыклы очрашулар көтә.

СУКОЯР (21.01-19.02). Сезнең эшләрегез, шәхси тормышыгыз үр менә һәм бәхетле мизгелләр кичерәсез. 3е көнне икеләнми зур эшләргә алыныгыз. Изге нияттән башланган гамәл үз җимешләрен бирми калмас. 4е көнне акчагызны нык саклагыз, бурычка бирмәгез. 5е көнне сәламәтлекне ныгыту буенча чаралар күрергә туры килүе ихтимал. Кешеләргә карата ышанмау сездә күп сораулар тудырыр. Ләкин җавапны үзегездән эзләгез. 8е көнне сезне көтелмәгән, әмма күңелле вакыйга көтә.

БАЛЫК (20.02-20.03). Узган атнада кичергән бәхетле көннәрдән соң сезгә бераз тынычланып, сабырлык күрсәтү кирәк булачак. Атна башында мөһим, җаваплы эшләргә алынмагыз. Илаһи көчләр сезне юлга, табигатькә әйдәр, барыгыз. Гомумән, сез атна дәвамында серле көчләр карамагында. Җан таләбенә колак салыгыз. Рухи сафлану кичерергә тырышыгыз, изгелек кылыгыз, әрвахларны искә алыгыз. Февральдә сез илаһи серле көчләр карамагында булачаксыз һәм алар сездән изге гамәлләр көтә.

Ул үзе дә чаптар ат сыман

Әле генә Казанда күренекле башкорт шагыйре Муса Галинең "Атылган йолдызлар" исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Һәм бу һич тә очраклы хәл түгел. Татарстан белән Башкортстан үзара дуслык килешүе төзеп, аның аерым маддәләренә туры китереп, Башкортстан һәм Татарстан дәүләт китап нәшриятлары "Каләмнәр дуслыгы" сериясендә Уфада һәм Казанда китаплар чыгару турында сөйләшкәннәр иде. Хәзергә 30дан артык китап басылды. Муса Галинең югарыда әйтелгән җыентыгы шул дуслыкның бер үрнәге булып тора.

М.Галинең туган төбәге турында кыскача гына булса да белешмә китерү урынлы булыр. Ул ил – Башкортстан. Күптән түгел бер авылдашым (зур галим), Швейцариядә булып кайткач, болай дигән иде: "Швейцария Альпын мактап күпләрнең авыз суы корый. Әйе, Швейцария бик матур ил, әмма дә ләкин Көньяк Урал тагын да матуррак". Шулай шул: моннан тайга урманнары башлана. Республиканың җирләрен Агыйдел, Караидел, Дим, Сакмар, Йөрүзән, Ык кебек күп сулы, балыкка бай елгалар юа. Ходай күлләрне дә кызганмаган. Кара туфраклы җирләрдә мул иген үсә.

Уфада урысча еш телгә алына торган ярым шаян сүз бар: "Деньги есть – Уфа гуляй, денег нет – Чишма сиди". Чишмә – шул исемдәге район үзәге. Уфага иң якын районнарның берсе. Татарлар яши торган төбәк. Шул район Башкортстанга халык шагыйрьләре Сәйфи Кудашны, Мостай Кәримне, атаклы җырчы Фәридә Кудашеваны, күренекле галимнәрне, сәнгать осталарын бирде. Бу исемлеккә Муса (үз исеме Габдрахман) Галине дә өстәргә кирәк. Ул шунда – Муса авылында – 1923 елның 15 октябрендә туган. Бик иртә ятим калган. Шулай да, тырышлыгы аркасында, авыл мәктәбен, Дәүләкән педучилищесын тәмамлаган. Шунда беренче шигырьләрен язган, район һәм Уфа гәзитләрендә бастырган. Бөек Ватан сугышында каты яралана, контузия ала. Сугыштан соң Уфада пединститут тәмамлый. Мәскәүдә Югары Әдәби курсларда укый. 40 китап авторы. Салават Юлаев исемендәге Дәүләт бүләге иясе. Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре. Уфада яши. Кыска гына итеп әйткәндә, шагыйрь турында рәсми мәгълүматлар әнә шундый. Калганы – иҗатында дип уйларга урын бар...

Бу беркемгә дә сер түгел: шагыйрьләр үзләрен пәйгамбәрләр затыннан дип хис итәләр. Кем белә бит, бәлки алар хаклыдыр. Югыйсә, Муса Гали:

Дөнья иркен бу күк астында,
Чикләре юк урман, суларның.
Иркен. Чиксез...
Чөнки дөньяны мин
Мәхәббәтем белән сугардым,

– димәс иде.

Лирик шагыйрь Муса Галинең әлеге җыентыгына 176 шигырь, 2 поэма кергән. Әмма теге яки бу китапка бөяне ниндидер санга карап түгел, әсәрләрнең эчтәлегенә, сәнгатьчә эшләнешенә, актуальлегенә карап бирү дөрестер. Философик уйлануларга, лирик кичерешләргә төренгән шигырьләр, җан азыгы буларак, күңел кылларын тибрәтәләр. "Атылган йолдызлар" поэмасындагы түбәндәге юллар шул фикерне раслый кебек:

Җанны үртәп,
азмы Иблис таптый
Җирнең Ходай салган бизәген;
Шыксыз хәнҗәр еш-еш ярып керә
Изгелекнең алтын үзәген.

Поэманың төп геройларыннан берсе Айбулат та, башка бик күпләр кебек, "Әфган сугышы"на аның хаклыгына ышанып бара, урыс империализмының чын сәясәтен белми, "бөек илебезнең чикләре мең ярым чакрымга көньяктарак үтәчәк", дип уйлый. Өстәвенә, әфган халкының (Әфганстанда, пуштуннардан тыш, күп санлы үзбәкләр, таҗиклар, кыргызлар, казахлар да яши) Монголия кебек, "капитализм формациясен үтми генә социализмга күчәчәгенә" ышана. "Әфган сугышының" төп сере – Петр I васыять итеп калдырган "бөтендөнья урыс империясен төзүгә" бер өлеш кертү иде. Безнең корал белән Азия, Африка, хәтта Америка кыйтгасындагы илләрдә сугыш барды. Бөтен дөньядагы компартияләргә Мәскәү даими рәвештә акча белән ярдәм итеп килде. Алар нигезендә шул ук империалистик сәясәт ятты. "Әфган"да, әлеге лозунгны өләм итүчеләр түгел, гади авыл малае Айбулат һәлак була. Ата-анасын мәңгелеккә кайгыга сала. Сөйгән кызы Гөлназ да бу кайгыдан үзенә урын таба алмый.

Поэмада сүз күбрәк Әфганстан күгендә балкыган йолдызлар турында барса да, шагыйрь Айбулатны атылган йолдызга тиңли (без дә балачакта, атылган йолдызны күреп, ул бер кешенең гомерен алып китте дип ышана идек):

Әй, атылып сүнгән йолдызларым,
Ничек кичтегез бу афәтне?

– дигән сорау куя шагыйрь.

Кем белә бит әгәр поэма соңгы вакытларда иҗат ителсә, башкачарак та ясалыр иде. Кызганыч, кайчак әсәрдә ялган патриотизм шаукымы да сизелеп китә.

"Коммунизм төзү" елларында нинди генә экспериментларга дучар булмады ил. Аурупада, бигрәк тә Голландия, Бельгия, Дания кебек илләрдә җирнең һәр сантиметры алтын бәрабәренә саналганда, СССРда тоташтан гидроэлектростанцияләр төзү китте. Миллион-нарча гектар иң уңдырышлы җирләр, урманнар су астында торып калды. Мондый чакта халык: "Бер тиенлек куян, ун тиенлек зыян", ди. Ил җитәкчеләре моның белән генә дә тынычланмадылар. "Авылларны эреләндерү" кампаниясе киң колач алды. Хрущевның туган авылы Калиновкада (Курски өлкәсе) халыкны биш катлы таш йортларга күчерделәр. Мал-туар тоту бетте. Янәсе, авыл да шәһәр белән бергә, коммунизмга күчә. Бу – буш хыял гына түгел, искиткеч зыянлы эш тә булып чыкты. Моны аңлатып торасы да юк. Бер генә сан китерик: бүген дә бәрәңге, ит, сөтнең иң күбесен шәхси крәстиян хуҗалыклары бирә. Авылны бетерү – фаҗигагә тиң. Шагыйрь үтә дә борчылып болай ди:

Күчкән авыл...
Төн йөзенә багып,
Елый иде нигез ташлары...
Иңри кошчык, сукмак,
тын чишмәләр –
Барысы да иңри тоташтан.

Моның бәласе анда гына да түгел, "авылларны эреләндерү" вакытында күпләр, гомумән авылны ташлап, Урта Азиягә киттеләр, Себер киңлекләренә таралдылар. Тагын шунысы да бар: авыл кеше шәхесен иң затлы сыйфатлар биреп тәрбияләүче көчле фактор да. Нәкъ авылда "ул атасы – утыз, кыз анасы – кырык" дигән тәгъбирләр тормышка аша. Кеше нинди генә югарылыкларга күтәрелмәсен, туган төбәген онытмый. Муса Галигә кушылып, мин дә, гади укучы, болай димен:

Мин агачны, ташны,
җилне сагынам...
Барысы да якын, танышлар.
Ә нигә соң йөрәгемне айкый
Томан артындагы тавышлар?..

Әлеге китапта кешеләр, халыклар, илләр арасындагы дуслыкка зур урын бирелгән. "Сабый Тукай", "Шүрәле урманнары", "Ак күкләр астында ак күлләр" – әнә шундыйлар. Шагыйрь якут халкына булган дуслык хисләрен болай тасвирлый:

Әй, Сахастан!..
Бер моң булып калды
Безне кавыштырган хак көннәр.
Йөрәгемә синдә ак манзараң:
Ак күкләр астында ак күлләр.

Бу да Америка ачу түгел: шагыйрьләр галәм категорияләре белән эш итәргә яраталар. Шуңа күрә бөтен дөнья – аларныкы:

Хозурланып айга карап торам,
Яктылыгы нинди, күкләр нинди.
Шушы айның моңсу тынлыгында,
Дөньяларның төпсез чоңгылында
Зиһеннәрем җитмәс сер күп нинди!

– ди шагыйрь.

Әйе, галәм – бөек, аның серләрен аңларга адәм затының гына зиһене җитәрлек түгел, ахрысы. Табигатьтәге төңгәллеккә карап гаҗәпләнәбез. Чыннан да, күк җисемнәре механизмын кем көйләп җибәрде икән?

Шагыйрь Муса Гали дә әйтә:

Тугай буйлап ярсып бер тай чаба
Түгәрәк юл салып, әйләнеп.
....
Әй, Җир генәм, бу җиһанда син дә,
Дулап чапкан шушы тай сыман.

Бу, үзенә күрә, Җиргә афәт китерүчеләргә кисәтү кебек тоела...

Шагыйрь Муса Гали – катлаулы, олы тормыш юлын узган, талантлы зат. Тынгысыз бу әдипнең киләчәк планнары да бар:

Җырлаячак күпме җырларым бар,
Башкортстан, горур илем, сиңа,

– ди.

Без, татар укучылары, шагыйрьгә изге хыялларын тормышка ашыруда ак юллар, иҗат уңышлары телик.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк

Артур Кларк фараз итә...

Фәннең төрле өлкәләрендә дөньякүләм танылган Артур Кларк – йөздән артык фәнни-фантастик романнар, язмалар авторы. Математика, физика, астрономия өлкәсендәге тирән белеме белән галим космик киңлекләрне үзләштерү программасында консультант буларак катнаша.

Кларк 80 яшьтән узып китсә дә, әлеккечә үк, алдан күрә белүче галим һәм язучы булып кала бирә. Күптән түгел аның "3001 елның соңгы одиссеясе" дигән китабы дөнья күрде. Анда киләчәктә кешелек дөньясын көткән үзгәрешләр турында языла.

Өйрәтүче шлемнар. Кешелек дөньясының мәктәпләргә, югары уку йортларына ихтыяҗы бетәр. Кеше махсус, кампитр эчле шлем кигәч, теләсә нинди һөнәр һәм белемнәр аның миенә барып ирешәчәк.

Хисләргә авызлык. Фән теләсә нинди уй-тойгыларны (мәсәлән, гаеп, оят, кайгы, югалту) бетерә торган чара уйлап табачак.

Орбиталь шәһәрләр. Киләчәктә галәмдә якынча миллиард кеше яшәячәк. Калганнары орбиталь станцияләрдә гомер итәчәк. Әлбәттә, аларның җиргә менеп-төшү җайланмалары булачак.

Микропроцессорлар. Бала организмына тугач ук, микропроцессор кертеләчәк һәм аны галәмнең теләсә кайсы почмагыннан эзләп табу, тану мөмкинлеге булачак.

Кешеләр үсемлек белән тукланачак. Өстәлләрдә ит дигән нәрсә булмаячак, чөнки һәммә кеше үсемлекләр белән туклануга күчәчәк.

Супервиртуаль чынбарлык. Киләчәк кешесе галәмнең теләсә кайсы урынына һәм теләсә кайсы вакытына – үткәненә виртуаль сәяхәт итә алачак. Бу исә, үткәнгә кайтып, Икенче бөтендөнья сугышын, Шекспир трагедиясе премьерасын яки үз әти-әниеңнең туен күрү мөмкинлеге бирәчәк.

Роботлар. Йорт эшләре һәм шундый башка эшләр кечкенә роботлар "микроталар" тарафыннан башкарылачак. Ә аларның зурлыгы мәче чамасы булачак.

Чиркәүләр бетәр. Кешеләр әлеккечә үк Аллага ышанырлар, әмма дини оешмалар бетәчәк. Һәр кешегә Алланы үзенчә табарга туры киләчәк.

("Тайная власть").

Ике гәүдәгә... бер баш

Ставрополь медицина институтында профессор Б.Гилевич җитәкчелегендә яшь ярымлык кыз балага гомердә булмаган операция ясала. Бу сабыйның... дүрт кулы, дүрт аягы, ике гәүдәсе бар, әмма башы – берәү генә!

Эчке әгъзаларда гайре табигый хәл күзәтелә: ике ашказаны, биш бавыр һәм...бер генә йөрәк. Бу катлаулы операция уңышлы тәмамланды: барлык артык әгъзалар кисеп алынды, тегәсе – тегелде, ямасы – ямалды. Верочка исемле кызчык хастаханәдән сәламәтләнеп һәм гадәти бала булып чыкты.

("Книга сенсаций").

Йолдызнамә. Сукоярлар (21.01 - 19.02)

21 гыйнвардан 19 февральгә кадәр адәм балаларының язмышын хәл итүдә Сукояр билгесе катнаша. Киләсе гасырда нәкъ менә Сукоярлар идарә итәчәк. Аларга тоемлау, алдан күрә белүчәнлек хас.

Сукоярлар башкалардан ерак торалар, үз эчләренә бикләнеп яшиләр. Алар тарихка, фәлсәфәгә, дингә бирелгәннәр, космик элемтәдә торалар һәм хәтта үз организмнарындагы авыруларны да тоймыйлар, аны яшькә сылтыйлар. Алар гаҗәп көчле ихтыярлы, авыру киң таралмасын өчен нерв эшчәнлеген эшкә җигеп, аны күзәтү астында тоталар.

Әлеге билге гәүдәнең түбәндәге өлешләренә – аяк, кул буыннарына, табаннарга, учларга көчле тәэсир итә. Шуңа күрә дә кул, аяк өлешендәге кан тамырлары начар эшли. Аларның еш кына ашказаны кызыша, кул, аяк буыннары чыгу, тартылу күзәтелә, йокысызлык җәфалый. Төрле клиник авырулар белән ихтыяр көчен туплап аякта йөрсә дә, Сукояр тиз һәм нык авырып китә.

Билгенең энергетик тозлары – магнийлы фосфат һәм хлорлы натрий. Ләкин моны ашка сала торган тоз дип уйлый күрмәгез. Болар – күзәнәкләрдән торган, аеруча бөртеклеләрдә, диңгез балыгында, инҗирдә булган тозлар.

Сукоярларның диетасында махсус чикләүләр юк. Сезгә көненә 1,5 литр су каралган, ләкин сыра, химик буяулар кушылган газлы сулар эчү катгый тыела.

Аяктагы кан юлларына профилактикалар үткәрү йөзеннән, ягъни күзәнәк мембраналарын ныгыту өчен аскорбин кислотасы һәм рутина, башка витаминнар таләп ителә. Бу комбинация аскорутин препаратында тупланган. Әгәр сез көн саен лимон, фейхоа, кара карлыган, петрушка куллана алмасагыз, ел дәвамында ике тапкыр таблеткадагы витаминнарны өч атна дәвамында эчәргә кирәк.

Тиз туза торган нерв эшчәнлеген тукландыру өчен югары калорияле аксым таләп ителә. Ә ул чикләвекләрдә күп.

Көзән җыерулар, теләсә нинди җәрәхәтләр булмасын өчен аякларны хәрәкәткә китерергә, күнегүләр ясарга, 1-2 минут "велосипед" әйләндерергә кирәк. Ә юынганнан соң бөгелеп йөрергә, чүгәләп карарга киңәш ителә.

Яшь арта барган Сукоярларга тауга менүләр, баскычтан күтәрелүләр читенләшә бара, хәл бетә. Әгәр көн саен 10 минут вакытыгызны аякларыгызга багышласагыз, яшегез сезне "көтеп торачак". Айга бер мәртәбә булса да каен яфраклары белән ванна ясау яки эссе мунчада аякларны парлау һәм кызарганчы ышку кирәк. Аякларыгызны кадерләсәгез, сакласагыз, ул сезне саклар.

Сезнең нумерология пароле – 4. Бу тәүлекнең билгегә көчле тәэсир иткән вакыты. Кичке сәгать дүртләр тирәсендә сез арыйсыз. Югыйсә, эш сәгате бетәргә дә күп калмаган. Аркагызны урындыкка яки стенага терәп утырыгыз. Тәрәзәне ачып куярга онытмагыз. Сулыш алу тренингын башлап җибәрегез. "Дүрт" дигәнче һаваны эчкә алыгыз, "дүрт" дигәнче аны эчегездә тотыгыз һәм "дүрт" дигәндә һаваны чыгарыгыз. Бу ара эчендә сезнең аша шәмәхә, сезгә якын астрологик яктылык челтәре үтеп китә. Көн саен күнегү үткәргән рәвештә сез шәмәхә агымда үзегезне яхшы хис итәрсез һәм медитация башланыр, чөнки сезнең рухи тәэсир көче, дәвалану сәләте өстән килә.

Һәм соңгысы. Сез тирә-юньдәге кешеләрне нык сайлыйсыз, аларны уртача якынлыкка гына җибәрәсез, бик сирәк кенә кемнедер якынайтасыз. Чөнки сезгә якын булган кешеләрнең рухи, акыл байлыгы да шул дәрәҗәдә булырга тиеш. Кызганыч, андыйларны табу читен. Һәм сез үзегез белән чикләнәсез. Бу хәлдән котылыгыз! Эзләгез! Тирә-юнь гармониясе – ул нәкъ шундый диета, сулыш алу, фитоэнергетик тәэсир итү кебек тулыландыру чарасы булып тора.

* * *

Сукояр Балык белән мәхәббәттә күркәм мөнәсәбәтләргә керә. Сукояр белән Сукояр бер-берсенә омтылып, яңа мөнәсәбәтләр урнаштыра. Ә Кучкар, Игезәкләр, Арыслан, Чаян белән Сукоярга мәхәббәт өлкәсендә куркыныч яный. Ләкин аны бәхәскә җиткерергә ярамый. Сукояр Укчыга, Кыслага карата салкын мөнәсәбәттә, ә Кыз белән хисләрен сакласа да, бәхәсләр дә туар. Бу билге Үгезбозау, Үлчәү, Кәҗәмөгез белән катлаулы мөнәсәбәттә, ызгыш-талашта.

ӘГӘР ХОЛКЫҢ АЛАМА БУЛСА...

Кайда гына булсаң да, үзеңне ничек тотуыңа карап, сиңа бәя бирәләр. Гаиләдә һәм хезмәт коллективында үз-үзеңне ничек тотуың аеруча мөһим. Көн саен һәм еллар буе теге яки бу кеше белән бергә яшәү яки эшләү барышында бер-береңә ошау, дөресрәге, бер-береңне туйдырып бетермәү өчен һәркем үз-үзен ничек тоту турында уйланырга, җәмгыятьтә үз-үзен тоту кагыйдәләрен үзләштерергә тиеш. Шуны исәпкә алып, укучыларыбыз дикъкатенә "Как вести себя в любой компании" дигән китаптан (1997) кайбер өзекләр тәкъдим итәбез.

Корольләр, патшалар – бик кодрәтле кешеләр. Ни телисәләр, шуны эшли алалар. Тик еш кына алар мәхәббәт буенча өйләнмиләр, үз дәрәҗәсендәге кешеләрнең кызлары белән тормыш коруны өстен күрәләр. Кайчак бу традиция бозылгалап та куя. Француз императоры Наполеон III белән булган хәл аеруча гыйбрәтле.

Үзенең дәрәҗәсе белән тирә-юньдә дан тоткан Наполеон III дөньяда иң чибәр һәм масаючан хатынга – Мария Евгения Августина де Монтихога гашыйк була. Киңәшчеләре француз императорын акылга килергә чакыралар, янәсе кем соң ул, гади бер граф кызы гына лабаса. Ләкин акылын җуяр дәрәҗәдә гашыйк француз императоры тәхеттән торып: "Мин үзем яраткан хатынны миңа билгесез булган хатыннан өстен күрәм һәм хөрмәт итәм", – дигән.

Шәп әйтелгән ләбаса. Гашыйкларның бөтен нәрсәсе бар: чибәрлеге, мәхәббәте, байлыгы, хакимияте, сәламәтлеге, бер-берсен яратуы. Мондый никах әллә кемнәрне дә кызыктырырлык, тик...

Аннары ни булган? Аннары менә ниләр ачыкланган: сокланырлык чибәр Мария Евгения Августина де Монтихо акылсыз гына түгел, йомшак холыклы хатын да булып чыга. Ул ирен бигрәк тә көнчелеге белән җәфалый. Мария хәтта илче һәм киңәшчеләрдән дә көнләшә. Император үзенә башка хатын табар дип коты оча аның.

Наполеон IIIне яманлап сеңлесенә сөйли, җылый, үкси, түзә алмыйча, иренең кабинетына бәреп керә, императорны төрлечә мыскыллый. Ул императорның тормышын җәһәннәмгә әйләндерә.

Ул аны юри шулай эшләгәнме? Француз тәхетенә күтәрелгән кешенең хатыны – графиня үз ирен шулай борчу, хурлауны максат итеп куйган дип уйлыйсызмы? Юк. Ул үз ирен яраткан, әмма үз-үзен тиешенчә тота гына белмәгән. Ә нәтиҗәсе?

Б.Рейнхард үзенең "Наполеон яки Евгения. Бер империянең трагикомедиясе" дигән китабында Евгениянең үз-үзен тотышы белән нәрсәгә ирешүе турында яза: "Хәл шуңа барып җитте ки, Наполеон йомшак эшләпәсен күз өстенә төшереп киеп, еш кына яшерен ишектән берәр дусты озатуында качып чыга торган булды".

Әйе, Наполеон еш кына сарайдан чыгып китә торган булган. Ул үзенең мәхәббәте челпәрәмә килгән урыннан качкан. Ул башка хатыннар янына киткән, Евгения ялгыз калудан куркып, үзенең кыланышлары аркасында ялгыз калган.

Шулай итеп, кеше үз-үзен тотышы белән үзенә карата иң җылы мөнәсәбәтне дә суытырга мөмкин. Бу өлкәдә бер-береңә ышанмаудан да яманы юк. Әгәр сиңа начар булса, елмай, елмаю сиңа ярдәм итәр, дип юкка гына әйтмәгәннәр.

* * *

Бер-береңә ышанмауның тагын бер мисалына тукталыйк. Бөтен дөньяга танылган бөек язучы Лев Толстой бик начар шартларда үлә.

1910 елның салкын бозлы яңгыр сибәләп торган октябрь төнендә 82 яшьлек карт кая барасын да белмичә чыгып китә... Ә унбер көннән соң әдәбият даһие, үзенең акылы белән бөтен Аурупаны сокландырган кеше кечкенә генә тимер юл станциясендә үпкәсе ялкынсынудан вафат була. Үләр алдыннан ул үз янына хатынын кертмәүне үтенеп сорый. Гаҗәеп матур башланган тормыш әнә шулай фаҗигале тәмамлана. Иренең бай булуы, мәшһүрлеге, әдәбият өлкәсендәге таланты графиня Толстояга мәхәббәт хисләре белән тулы матур тормыш вәгъдә итә. Тик еллар узган саен алар арасындагы мөнәсәбәтләр суынганнан-суына. Сәбәбе була, әлбәттә.

"Әтиегез үлеменә мин сәбәпче булдым", – дип үкенә соңыннан графиня Толстая.

Бөек философ, фикер иясе граф Толстой Гайсә пәйгамбәр юлыннан барырга омтылган. Үзенә-үзе хезмәт күрсәтергә тырышкан, басуда эшләгән, утын кискән. Бөтен дөньяга данлыклы язучы агач савыттан ашаган, үзенең дошманнарын яратырга тырышкан. Ләкин Лев Толстойның шәхси тормышы мәхшәргә әйләнгән. Ул үзенең әсәрләрен бастырган өчен гонорар алмаган, бастыруны да таләп итмәгән, аны нәширләр ихтыярына калдырган. Ә хатыны? Аңа акча кирәк. Шуның өчен ирен битәрләүләрен күрсәң икән! Туктаусыз бәйләнүләр, үзен-үзе үтерү белән куркытулар... Авызы янына әфьюн флаконы китереп, иләндә тәгәрәүләр. Коега ташланам дип янаулар...

Кайчак ул элекке яшьлек елларына да кайткан. Элекке кебек, якты хисләргә бирелгән көннәре дә булган. Борчылудан караңгы төскә кергән хатын, иреннән илле еллар элек хатыны турында көндәлегенә язган җылы сүзләрне укуын үтенгән.

Аннан соң тагын җәнҗал купкан: "Син мине яратмыйсың". Бәлки, моның өчен сәбәпләре дә булгандыр. Лев Толстой фәрештә булмаган ич. Ләкин хатыны мондый кыланышлары белән нәрсәгә ирешкән соң? Тормышын яхшыртканмы? Яки иренең холкын үзгәртә алганмы? Юк, граф үзгәрмәгән, бары тик хатынын куралмас дәрәҗәгә җиткән, хәтта җан биргәндә дә хатынын гафу итә алмаган.

Димәк, ирегезне яки хатыныгызны үзгәртергә омтылу мәгънәсез.

Атаклы Авраам Линкольн тормышы да моңа дәлил. Егерме өч ел буена төрле ысуллар белән Мэри Тодд Линкольн ирен игәүләгән һәм үлемгә дучар иткән. Бу гаиләдә дә тынкыйть һәм канәгатьсезлекнең чиге булмаган. Иренең үз идеалына туры килмәвен хатын туктаусыз тукып торган. Аның йөреше дә, гәүдәсен тотышы да ошамаган аңа. Аңа гәүдәсен ничек тотарга да өйрәтеп караган ул. Иренең колаклары тырпаеп торуы да ачуын китергән. Башың кечкенә, аяк-кулларың артык зур дип тә бәйләнгән. (Гаҗәп, кияүгә чыкканда күзләре нәрсә караган икән соң!)

Президент Линкольнның рәсемен күргәнегез бардыр. Ул һич тә Линкольн ханым тасвирлаган гарип кешегә охшамаган бит.

Бервакыт пансионатта Линкольннар бергәләп ашап-эчкәннән соң ире ниндидер кечкенә генә ялгышлык ясаган, хатыны шуның өчен иренең битенә кайнар кофе сипкән.

Мондый кыланышлары белән ул ирен бернигә дә чек тә үзгәртә алмаган. А.Линкольн тарихка гаять күренекле шәхес булып кереп калды. Ә миссис Линкольн акылдан шашты. Ире аны гаепләмәде, бары тик үзләренең никахлары шундый үкенечле тәмамлануына гына борчылу белдерде.

Бүгенге көндә дә бер-берсен яратышып өйләнешкән кешеләр тормышында күп кенә күңелсез хәлләр булгалый, элек бер-берсен чиксез яратышкан кешеләр бүген бер-берсенең азыкны ничек йотуын да, ипине ничек кисүен дә, күмәчкә майны ничек сылавын да яратмыйча бер-берсенә төртмәле сүзләр әйтәләр.

Ире эштән кайта. Гаилә җыелып бетә.

– Акчаң кая?

– Нинди акча?

– Кичә алган акчаң?

Шул арада хатын иренең начар кырынганлыгын да күреп ала, ул хакта да әйтергә онытмый.

– Мин әле акча калгандыр, дип уйлаган идем.

– Әллә син нәрсә ашаганыңны белмисеңме?

Мондый сөйләшүләр туйдыра ирләрне. Гаиләдә бер-береңне гаепләргә, бер-береңнең кимчелекләрен күрергә тырышканчы иң әүвәл үзең турында уйларга кирәк. Бер-береңә ирек биргәндә, аны үзеңнең колың итеп карамаганда гына бәхетле, тыныч яши аласың.

Язманы матбугатка
Заһид ШӘФИГЫЙ әзерләде.

КАЗ КАНАТЫ
КАУРЫЙ-КАУРЫЙ

хатлар
язарга ярый

Урта Уралда – милли-мәдәни мохтарият

Свердловски өлкәсендә яшәүче татарлар соңгы вакытта милли алгарыш чорын кичерәләр. Чит өлкәләрдә көн итүче татар диаспорасы, элек "нацмен" дип, кимсетелеп яшәсә, хәзер демократиянең йомшак җилләре тәэсирендә оеша, үз мәнфәгатьләрен кыюрак яклый башлады. Русиянең "Милли-мәдәни автономияләр турында"гы Законы нигезендә, татарлар укмашып яшәгән районнарда, милли-мәдәни мохтариятләр барлыкка килә башлады. Шундый автономия Свердловски өлкәсенең Красноуфимски районында да оештырылды. Бу районда 11 татар авылы бар. Биредә "Кызыл яр" дигән иҗтимагый-мәдәни үзәк эшләп килә. Красноуфимски (Кызыл Яр) шәһәрендә татар халык театры инде сигезенче сезонын ачып җибәрде. Аның режиссеры – талантлы артист Рәйсә Сафина.

Милли автономия советы үз программасын кабул итте. Анда районда методик үзәк булдыру, район үзәгендә татар телендә гәзит чыгару, районның татар авылларындагы барча мәктәпләрендә дә татар теле дәресләрен кертү һәм даими рәвештә укыту, татар телендәге радиотапшыруларны яңадан башлап, җайга салып җибәрү турындагы һәм башка пунктлар бар.

Мөхәммәтнур МУЛЛАНУРОВ.
Екатеринбург-Казан.

Һәркемнең үз җыры

"Мәдәни җомга" гәзитендә композитор Фасил Әхмәтнең "Үзешчәнлек бәласе" дигән тирән эчтәлекле, күңелгә ятышлы язмасы басылып чыкты. Ул мәкаләне кат-кат укып чыктым. Уйлап йөргәч, үземнең дә фикеремне язарга булдым.

Без – "Күккүк"не, "Зәңгәр шәл"не, "Башмагым"ны, "Галиябану"ны тыңлап үскән буын. Бу исемлек зур, аны санап тормыйм. Без Салих Сәйдәшевләр, Нәҗип Җиһановлар, Рөстәм Яхиннар һәм башка композиторларыбыз калдырган бай мирасның кадерен белмибез. Әйе, кызганыч, алар эфирда да, телевизор аша да сирәк яңгырыйлар. Минемчә, биредә гаеп Композиторлар берлегенең үзендә дә бар. Классикларыбызның моң байлыгын пропагандалауда аның тарафыннан әлләни хәрәкәт сизелми.

Татарстан Композиторлар берлеге каршында "Җыр ратучылар клубы" оешса ничек әйбәт булыр иде. Җыр байлыгын кемдер пропагандалаганын, минемчә, көтеп ятарга кирәкмидер. Хәзер моның өчен мөмкинлекләр күп. Әйтик, "Дулкын" радиостанциясе хәзер барлык борынгы көйләрне халыкка җиткерергә әзер. Бу яшь радиостанциягә дөрес юнәлеш бирергә, ярдәм итәргә генә кирәк.

Шулай ук "Курай" радиостанциясе дә бай мирасыбызны, композиторларыбызның классик әсәрләрен пропагандалауга үз өлешен кертә алыр иде. Аларга да дөрес юнәлеш бирүче юк.

Хәзер көне-төне шул радиостанцияләр аша заман җырларын, яшь җырчыларны тыңлыйбыз.

Сез, Фасил ага: "Җыр текстлары түбән сыйфатлы, көйләрнең дә яңгыравы шул кадәр генә, күбесе белемсез, хәтта "композитор", "композиция" дигән сүзләрнең мәгънәсен дә аңламыйлар, белмиләр, нотаны да танымыйлар", дисез.

Барлык үзешчән композиторлар бакчасына да таш атмыйк әле. Аларның барысын да нота "танымаслык" дип мәсхәрәләп булмас. "Бер көнлек" җырлар халык арасында да кабул ителмиләр. Тора-бара андый җырлар "үләләр", халык күңеленә дә үтеп керә алмыйлар. Үзешчән композиторлар арасында халык күңеленә үтеп керерлек җырлар иҗат итүчеләр дә бар. Без аларны яратып тыңлыйбыз. Шул ук үзешчән композиторларның җырларын профессиональ җырчылар да башкаралар түгелме соң? Җыр яратучылар арасында да кемдер романслар, кемдер опера, кемдер классик музыка гына ярата. Әйтик, өлкәннәр кирәксенмәгән Энҗене яшьләр яратып тыңлый...

"Сандугач-97" фестивале күп кенә яңа исемнәрне халык күңеленә якынайтты. Нәфкать Нигъмәтуллин, Бәширә Насыйрова кебек үсеп килүче башкаручылар киләчәктә безне, һичшиксез, сөендерер әле.

Сугыштан соңгы елларда артистларыбыз бармак белән генә санарлык иде. Хәзер 100дән артык җырчыбыз бар.

Фасил ага, сез халкыбызның гүзәл моңсары. Мондый сөйләшүне иртәме, соңмы, башларга кирәк иде һәм Сез бик кирәкле сүз башладыгыз. Рәхмәт.

Рафаэль САЛЬМУШЕВ.
Казан.

Күңелләр кушылгандай була

Миңа язмыш кардәшләрем арасында, Татарстанда яшәргә насыйп итмәде. Ерак Казакъстанның Алматы шәһәрендә яшим. Әмма Татарстанны бик сагынам. Шуңа да "Мәдәни җомга" гәзитен чыга башлаган көненнән бирле алдырам, андагы һәр материалны укып барам. Бу гәзиттә халкыбызның тарихы да, мәдәнияте дә, теле дә, әдәбияты да, сәясииҗтимагый вакыйгалар турында да материаллар бар. Мин үзем инде өлкән яшьтә, пенсионер, Бөек Ватан сугышында катнаштым. Минем кебек өлкән яшьтәге кешене, илен сагынып яшәүчене гәзитегез белән сөендерүегез өчен рәхмәт сезгә! Аны укыгач, кардәшләрем янына кайткан кебек булам.

Хәмит ӘХМӘТШИН.
Алматы шәһәре.

Бер җылы сүз җитә кешегә

Бик тә йөрәгемне әрнеткән бер хәлне язмый кала алмыйм. "Азатлык" радиосыннан Наиф Акмал әзерләгән бер язманы укыдылар. Башкортстанның данлыклы җырчысы Мәгәфүр абый Хисмәтуллин һәм аның хәсрәтле, авыр тормышы турында иде ул. Балачагымда яратып тыңлаган моңлы, оста җырчының авыр язмышы бик тә тетрәндерде, әле мин аны исәндер дип тә уйламый идем. Шул вакытта Илһам абый Шакировның, үземне бәхетсез дип саныйм, дигән сүзләре хәтеремдә яңарды.

Бу талант ияләренең сәхнәдән төшкәч онытылулары коточкыч фаҗига инде. Зинһар өчен Мәгәфүр абыйга ярдәм итегез! Инде бер дә булмаса, хат белән дә күңеленә яктылык өстәргә, яшәүгә ышаныч тудырырга мөмкин. Яхшылык җирдә ятмый бит, үзеңә кайта.

Гөлфирә МӨНИПОВА.
Мамадыш районы,
Олыяз авылы.

Афәрин, Миргазиян ага!

Бу сүзләрне мин беренче тапкыр үткән ел сентябрь аенда "Казан утлары" журналында "Соңгы сулыш" дигән юлъязмагызны укып чыккач әйттем. Әйтмәслекме соң?! Йөрәк кадәр йөрәккә операция ясаткаННАН соң, шундый зур каршылыкларны җиңеп, Кояш чыгышы иле – Японияга баручы "Капитан Нугай" корабына эләгә алуыгыз һәм шулкадәр авыр, озын сәяхәткә чыгып китәргә җөрьәт итүегезгә сокландым. Экипаж әгъзаларыннан аермалы буларак, дөнья байлыгына кызыгып түгел, ә рухи азык алыр өчен баруыгыз сокландырды.

Журналның октябрь аенда басылган саннында юлъязманың ахырын укыгач, тагын бер кат "Афәрин!" дидем. Әмма шунысы кызганыч: журналны бит һәр авылда бармак белән генә санарлык кешеләр ала. Милләт язмышы, ил язмышы һәм аның киләчәге өчен ачынып, йөрәк каны белән язылган бу әсәрне Татарстан китап нәшрияты зуррак тираж белән бастырып чыгарыр дип өмет итәбез. Ә инде әсәрнең 26-27 нче бүлекләрен татар телендә чыга торган гәзитләр бастырып чыгарса, халыкта әсәрне укуга кызыксыну туар иде.

Миргазиян ага үзенең әсәрендә, японнарның җитәкчеләре эш хакын эшчеләрдән бик азга гына артык ала, өйләре дә эшчеләрнекеннән әлләни аерылмый һәм бер чамада, дип яза. Ә бездә җитәкче йорт салса, ул ак карга кебек, әллә каян аерылып тора. Ул хәтта мәктәп яки мәчет салырга дигән материалны да үзләштерүдән тайчанмый. Мондый төзелешләргә халык "Могҗизалар кыры" дип исем бирә. Чөнки алар төзелеш материалын очсыз хак белән генә юнәтә. Тир түгеп икмәк үстерүче, фермада тизәк ерып терлек карауучы, татлы йокысын бүлеп таңнан торып сыер савучылар эшләгән тиеннәрен ала алмыйлар. Ә түрәләр клуб чаклы өйләр салу өстенә, һәр елны, чит илләргә сәяхәт итәләр. Алар намус дигән сүз белән таныш түгел, ахрысы. Бу турыда бит юкса гәзитләр язып, радиолар сөйләп тора. Ә югарыда утыручы түрәләр сукыр һәм чукрак микән соң әллә дигән фикер туа. Аларның девизы: "Эт өрер, бүре йөри торыр".

Эшләгәнен ала алмаган гади хезмәт кешесенең берни дә кыра алмаячагын алар яхшы белә.

Ә Миргазиян ага әсәр ахырында шундый оста итеп кораб язмышын ил язмышы белән чагыштыра.

"... Запас юкка чыкты. Зур җинаять иде бу. Куркыныч җинаять. Корабның иминлеген тәэмин итү өчен капитан чара күрә алмады. Аның кулы пычранып, арт саны тизәккә батып өлгергән иде инде".

Безнең түрәләр дә әллә шушы капитан хәлендә микән соң?

Р.МИНГАПИ.
Ютазы районы,
Димтамак авылы.

Тәмле телле автобус

Өйдә дә бит гел синең көеңне генә көйләп тормыйлар. Бүген мин өйдән эшемә үртәлеп чыгып киттем. Тукталышка барып җитү белән автобуска кереп утырдым.

– Хөрмәтле пассажир иптәшләр, киләсе тукталыш Салих Сәйдәшев тукталышы була, – дигән таныш тавыш ишетелде.

Бу тавышны мин 4 нче автобус маршрутында еш ишетәм. Сүзендә генә түгел, машина йөртүченең тавышында ук пассажирга, үзенең автобусына утырып йөри торган кешеләргә карата гаҗәп дәрәҗәдә олы хөрмәт сизелеп тора. Шул тавышны ишетүгә минә бүген дә өемнән чыгып киткәндә үртәлгән күңелем язылып, кәефем күтәрелеп китте. Ярый әле автобусның шушысы туры килде. Аның йөртүчесе һәрвакыт, халык машинадан төшкәндә, елның кайсы фасылы булуга карап:

– Аяк асты пычрак, иплап төшегез, иптәшләр, – дип, яисә:

– Бүген аяк асты тая, егыла күрмәгез, – дип, хәер-фатиха биреп озата. Өстәвенә, әле:

– Юл билеты алганнарыгызга хәерле юл телим! – дип, шаяртып та куя.

Гел шундый ул. Мондый тәмле телле шоферлар бик сирәк бит безнең Казанда. Шуңа күрә бүген минем аның исем-фамилиясен беләсем килде. Алексей Борисович Лесников икән ул.

Алексей Борисович йөртә торган 4 нче автобус иске генә, бәләкәй генә. Шундый машина йөртүчегә өр-яңа автобус бирсәләр дә бик ярар иде. Нихәтле кеше рәхәтләнеп йөрер иде аның белән.

ИБРАШ.
Казан.

Сталин оныклары низаглаша

Лондонда модерн ысулы белән иҗат итүче яшь грузин рәссамының шәхси күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәнең авторы – Сталин оныгы Яков Джугашвили. Аның әтисе – Евгений Джугашвили – Ватан сугышы чорында немецләрдә әсирлектә һәлак булган Яков Джугашвилиның һәм Ольга Голышева улы. Кече Яков Джугашвили Глазго шәһәрендә сәнгать мәктәбендә укый.

Рәссамның әтисе Грузиядә Сталин мирасын өйрәнү хәрәкәтенә нигез салган кеше. Ул коммунистлар ярдәмендә Украинада, Белоруссиядә, БДБ илләрендә бу хәрәкәтнең бүлекләрен ачарга җыена. Мәскәүдән гаиләсе белән Грузиягә күченеп кайткан пенсиядәге бу офицер бабасы турындагы ялган язмаларның матбугатта тулып ятуына борчыла. Ул совет ГУЛАГы һәм Сталин режимының башка җинаятьчеләре турында матбугатта сүз әйткән кешеләрнең "кара исемлеген" төзәгән. Бу исемлеккә 57 яшьлек Александр Бурдонский да эләккән. Ә ул Евгений Джугашвилига – туганнан-туган энекәш. Театр режиссеры һәм шигърият белгече Александр Василий Сталинның (Казанда вафат булган) улы. 13 яшендә ул бабасы исеменнән ваз кичеп, әнисе фамилиясенә күчкән.

Иң алдынгы шахтерлар һәлак булды

17 гыйнварда Воркутадагы "Центральная" шахтасында зур һәлакәт булды. 900 метр җир астында метан шартлавы аркасында 49 шахтер һәлакәткә очрады.

Дүртенче участок шахтеры (анда 27 шахтер һәлак булган) Фәрит Хәлимов әйтүенчә, лава астында 3 нче бригада шахтерлары афәткә юлыккан. Алар арасында 5 бала атасы Владимир Лисовский, 2 бала атасы Рәшит Шәрәфетдинов һ.б.бар. Алар иң тәҗрибәле, алдынгы шахтерлардан саналган. Бу авария – шахта тарихында (ул 1954 елдан эшли) иң зур корбаннар китергәне.

("Известия").

Аракыдан диңгез булыр иде

Волгоград шәһәрендәге лареклардан, кибетләрдән, тауар базаларыннан салым полициясе тарафыннан конфискацияләнгән аракы шәһәр администрациясен чын-чынлап кайгыга салды. Конфискацияләнгән ясалма аракының күләме миллион шешәдән артып киткән. Ул ялган аракыны нишләтергә белми аптырыйлар.

("Известия").

Һәйкәлгә хәер бирегез

Пятигорскида да акчага кытлык. Анда яшәүче Валентина Крылова дигән бер хатын акча эшләүнең гайре табигый юлын тапкан. Ул шәһәрнең үзәк урыннарына – кеше күп җыела торган җиргә чыгып... "Азатлык һәйкәле" роленә керә. Башында – тәкыя, кулында – факел, озын күлмәк итәге җиргәчә асылынып төшкән. Киеме, чәчләре, йөзе бронза төсенә буялган. "Һәйкәл" төбенә акча салыр өчен савыт куелган. Хатын фоторәсемгә төшерергә теләүчеләрдән дә акча ала. Җәен ул көн саен шәһәр буйлап йөри, хәзер – кышкы суыкларда сирәгрәк күренә.

("Бизнес Татарстана").

Терезага дүрт йөрәк

55 яшьлек испан хатыны Тереза Селива йөрәк авыруыннан интегә. Аны коткарыр өчен ашыгыч операция ясарга кирәк була. Хатынның күкрәген ярып, аңа икенче йөрәк куялар. Ләкин бу йөрәк нигәдер типми. Икенче йөрәк куеп карыйлар – бу юлы да тән тукымасы чит йөрәкне кабул итми. Өченче йөрәк китерәләр – монысы да уңышсыз. Дүртенче йөрәкне тапканчы, хатынга ясалма йөрәк куеп торалар. Һәм, ниһаять, дүртенче йөрәк китерелә. Операция уңышлы чыга – Тереза күкрәгендә йөрәк тибә башлый. Бераздан ул, савыгып, хастаханәдән өенә кайта.

("Книга сенсаций").

Яшенле малайлар

Малайзиядә Маомад һәм Шарил исемле игезәк малайларга хәтта әти-әниләре дә якын килергә курка. Аларның сәер үзенчәлеге бар: малайларга кагылган кешеләрне көтле электр тогы суга.

Һәрвакыт суфлерсыз эшләгән

Бөек урыс җырчысы һәм артисты якташыбыз Ф.Шаляпин опера театрында спектакльләрдә уйнаганда беркайчан да үз ролен өйрәнеп кенә калмаган – ул операны, аның барлык ялгыз җырлый торган, хор һәм оркестр партияләрен тулаем яттан белгән. Аның сәхнә буенча партнерлары, артист һичкайчан суфлер ярдәменнән файдаланмады, диләр. Мәсәлән, ул Мусоргскийның "Борис Годунов"ындагы ир һәм хатын-кыз партияләрен – Годунов, Шуйский, Марина Мнишек партияләрен яттан белгән.

("Познай себя").

В.ПЕСКОВ рәсеме ("ЛГ").

Куллары, аяклары, тешләре белән рәсем ясый

Рәссам-монументалист Ильяс Зариповның күргәзмәләре сәнгать сөючеләрне битараф калдырмый. Ул 3-4 секунд эчендә портретыңны ясап бирә ала. Рәссам куллары белән берьюлы ике рәсем ясый, куллары, аягы һәм тешләре белән берьюлы 4 рәсем ясап бирә. Хәтта күзен бәйләп тә рәсем ясый ала.

("Известия").

Ашказанында... кайчы ята

37 яшьлек Исидоро Карбера (Аргентина) елдан артык ашказанында кайчы йөрткән. Медицина кайчысын операция ясаганда хирурглар онытып калдырган була. Ул яңадан операция өстәленә яткан – ашказанындагы кайчыны алганнар.

40 ел снаряд йөрткән кеше

Бу хәл 1944 елда Симферопольдән 30 чакрым ераклыкта булган. Павел Гаврилин самолетын бәреп төшерәләр, ә очучы үзе авыр яралана. Госпитальдән чыккач кабат сугышта катнаша. Ул 244 сугышчан очыш ясап, дошманның 19 самолетын бәреп төшергән. Һәм 1984 елда аның эченнән... снаряд алыр өчен операция ясыйлар. Авиация снаряды очучының эчендә 40 ел буе йөри. 1944 елда, табиблар әйтүенчә, аны температура коткарган. Снаряд, кан юлларын яндырып, эчкә кан савудан коткарып калган.

("Книга сенсаций").

Президент оныгы

Катя – Президент Борис Ельцинның оныгы. Әнисе – Елена Ельцина, әтисе Валерий Окулов – "Аэрофлот" директоры. 17 яшь тулгач, Катя тән сакчыларыннан баш тарта, үзен бернинди сакчысыз калдыруны сорый, бабасы Б.Ельцин аның теләген канәгатьләндерә. Катя Мәскәү дәүләт университетының тарих факультетында укый. Ә аның туганнан туганы Англиядәге дәрәҗәле уку йортында гыйлем эсти. Катя Ельцина үзенең Мәскәүдә укуына бик канәгать. Ул үзенең булачак кияве белән бергә яшәү өчен өннән күчеп киткән.

("МК").

Татарстанлыларның кереме күпме?

1997 елның октябрендә республиканың эре һәм урта предприятиеләрендә эшләүчеләрнең уртача эш хакы 950,6 мең сум тәшкил итте. 1996 елның октябре белән чагыштырганда керем 1,2 мәртәбә, ә 1997 елның сентябре белән чагыштырганда 0,2 процентка арткан.

Татарстан дәүләт статистика комитеты мәгълүматларына караганда, иң түбән эш хакы алучылар – авыл хуҗалыгында, мәгариф, мәдәният һәм сәнгать, урман хуҗалыгы, сәүдә һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә эшләүчеләр.

Күрше регионнарда октябрьдә уртача эш хакының күләме болайрак: Башкортстанда – 896,7 мең сум, Мари Илендә – 531,1 мең сум, Чуашстанда – 556,3 мең сум, Удмуртиядә – 811,3 мең сум, Ульянда – 693,4 мең сум, Самарада – 1187 мең сум тәшкил итте.

("Киңәш").

ТЭ Татар энциклопедиясе битләреннән

АХУН Садри Сәләхетдин улы (1903-1988), сынчы, педагог, рәссам. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1949 елдан Татарстанның халык рәссамы, 1950 елдан РСФСРның сәнгать эшлеклесе. 1940-50 елларда Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе. 1937-51 елларда Казан сәнгать училищесында укыта, 1949 елдан скульптура бүлеген җитәкли. 1958 елда Казанда Л.Кербель, В.Писаревский белән берлектә Г.Тукай һәйкәлен иҗат итә. Хезмәтләре: "Ромен Роллан" (1938), "Композитор Салих Сәйдәшев", "Муса Җәлил" (1957). 1951 елдан Мәскәүдә яши. 1966-74 елларда Мәскәү технология институтында композиция кафедрасы мөдире.

АХУНҖАНОВ Галимҗан Хәкимҗан улы (1925 елда туган), тел галиме, филология фәннәре докторы (1974). 1989 елга кадәр Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. Татар теле фразеологиясе, лексикографиясе, лексикологиясе буенча хезмәтләр авторы.

АХУНҖАНОВ Илдус Габделгани улы (1930-1990), әдәбият тәнкыйтьчесе.

АХУНҖАНОВ Әнвәр Мәхмүт улы (1914-1986), тел галиме, филология фәннәре докторы (1967), профессор (1969). Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1984). 1945-52 елларда Казан педагогия институтында, 1955-59 елларда Тел, әдәбият, тарих институтында, 1960 елдан Казан университетында эшли. Тел белеме, икетеллелек, чагыштырма лексикология, контрастив грамматика буенча хезмәтләр авторы.

АХУНҖАНОВ Гарифҗан (Ахунов Гариф) Ахунҗан улы (1925), Татарстанның халык язучысы (1993). 1950 елда "Яшьлек яме" повесте. 1963 елда "Хәзинә" романы (татар һәм урыс телендә) дөнья күрә. Ул шулай ук "Хуҗалар" (1968), "Чиклəвек төше" (1975) романнары. "Ардуан батыр" (1982) повесте, 20 нче гасырның беренче яртысы татар тормышын тасвирлаган "Идел кызы" романы (1978-86) авторы. 4 томлык "Әсәрләре" (1981-84) дөнья күрде. М.Шолохов әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте, пьесалар яза. 1963-65, 1967-68 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе. 1971-74 тә "Казан утлары" журналының баш мөхәррире, 1974-84 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Югары Советы депутаты, СССР, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе (1975-84), 1973 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, 1995 елда Г.Исхакый исемендәге бүләк бирелә.

АШМАРИН Николай Иванович (1870-1933), тел галиме, төрки телләр белгече. 1929 елдан СССР Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы. 1895-99 елларда татар керәшен мәктәбендә укыта. 1920-31 елларда Казанның төрле уку йортларында һәм Көнчыгыш педагогия институтында эшли. Чуаш халкы тарихы, фольклоры, теле буенча хезмәтләр авторы.

АТЛАСОВ Гакыйл Билал улы (1884-1924), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. 1907-17 елларда Самара гөбернәсе Әбдери авылы мулласы, "Үрнәк" мәдрәсәсен ача. 1919-20 елларда 1 нче Идел татар-укчы бригадасында. 1927-32 елларда Татарстан китап палатасы директоры. 1937 елдан Әндиҗанда (Үзбәкстан) укыту эшендә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Дүшәмбе
2 ФЕВРАЛЬ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан" информацион программасы.
17.55 Балалар өчен: "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Каракитә академигы". З.Әзизов.
19.45 Яңалыклар.
20.00 Актуаль тема. Пенсия реформасы турында.
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "ПРИСТУПИТЬ К ЛИКВИДАЦИИ" (21.45 – Яңалыклар).
22.30 Һәркем өчен хоккей.

"ЭФИР"

6.00, 11.30, 14.15, 2.45 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 5.20 "Республика". Информацион-аналитик программа.
7.20 "Уян һәм җырла".
